М. В. Зәйнуллинның 2002 нче елда төзелгән грамматикасында исемнәрдә тартым формаларының төп өч төре булуы бәян ителә: исемнәргә кушымчалар кушылып ясалган төрне «морфологик төр»(*китаб-ым, китаб-ың, китаб-ы; алма-быҙ, алма-ғыҙ, алма-лары*); ия булучыны белдергән зат алмашлыгыннан һәм ия булынучыны белдергән тартым кушымчалы исемнән төзелгән төрне «морфологик-синтаксик төр» (*минең китаб-ым, һинең китаб-ың, уның китаб-ы; беҙҙең алма-быҙ, һеҙҙең алма-ғыҙ, уларҙың алма-лары*); ия булучыны белдергән зат алмашлыкларының иялек килеше кушымчалы хәлдә, ия булынучы предметны белдергән исемнең кушымчасыз хәлдә кулланылуыннан ясалган төрне «синтаксик төр» (*минең китап, һинең китап, беҙҙең китап, һеҙҙең китап*) дип атый [Зәйнуллин, б. 21].

Чуваш телендә тартымны белдерү юллары J. Krueger (1961), Л. П. Сергеев, Е. А. Андреева, В. И. Котлеев (2012) хезмәтләрендә аңлатыла. J. Krueger язганча, чуваш телендә тартымны (personal possession) белдерүче өч ысул бар [Krueger, б. 113, 116]. Беренче ысул – инглиз теленең «my, our, your...» сүзләренә туры килгән, иялек килешле зат алмашлыклары белән белдерү ысулы: *манӑн лаша* (минем ат), *санӑн лаша* (синең ат), *унӑн лаши* (аның аты), *пирӗн лаша* (безнең ат), *сирӗн лаша* (сезнең ат), *вӗсен лаши* (аларның аты) [Krueger, б. 113]. J. Krueger фикеренчә, тартым төшенчәсен белдерүнең әлеге ысулы чуваш телендә киң кулланыла. Галим башка төрки телләрдә очраган тагын бер ысулга игътибар юнәлтеп, ия булучының кем икәнен белдерү өчен, махсус кушымча куллану ысулын күрсәтә. Мәсәлән: *ывӑл-ӑм* (ул-ым), *ывӑл-у* (ул-ың), *ывӑл-ӗ* (ул-ы), *ывӑл-ӑмӑр* (ул-ыбыз), *ывӑл-ӑр* (ул-ыгыз), *ывӑл-ӗ* (ул-ы) [Krueger, б. 116]. Автор, предметнең кемнеке икәнен ачыклап әйтергә кирәк булганда, өстәге ике ысул бергә кулланыла дип аңлата. Бу ысул, башлыча, инглиз теленең «Our son did this, but their son did that.» җөмләсендәге кебек, аерым басым ясау өчен кулланыла: *манӑн ывӑл-ӑм* (минем ул-ым), *санӑн ывӑл-у* (синең ул-ың), *унӑн ывӑл-ӗ* (аның ул-ы), *пирӗн ывӑл-ӑмӑр* (безнең ул-ыбыз), *сирӗн ывӑл-ӑр* (сезнең ул-ыгыз), *вӗсен ывӑл-ӗ* (аларның ул-ы) [Krueger, б. 113, 116]. J. Kruegerның сүзләренчә, хәзерге чуваш телендә I һәм II зат күплектә аналитик конструкция еш кулланыла. Мәсәлән, *ывӑл-ӑмӑр* урынына *пирӗн ывӑл*, *ывӑл-ӑр* урынына *сирӗн ывӑл-у* кулланыла [Krueger,б. 118].

Л. П. Сергеев хезмәтендә предметның кайсы затка каравы түбәндәге ике ысул белән белдерелә дип аңлатыла:

1) исем алдында, кемнеке икәнен белдерүче сүзне, ягъни зат алмашлыкларын (*манӑн, пирӗн, санӑн, сирӗн, унӑн, вӗсен*) куллану (синтактик ысул). Мәсәлән: *манӑн ручка* (минем ручка), *пирӗн ручка* (безнең ручка), *сирӗн кӗнеке* (сезнең китап), *унӑн ручки* (аның ручкасы), *вӗсен кӗнеки* (аларның китабы);

2) предметның кемнеке икәнен морфологик ысул, ягъни махсус кушымчалар белән дә белдереп була. Мондый кушымчалар тартым кушымчалары (чув. камӑнлӑх аффиксӗсем) дип атала. Мәсәлән: *сӗтел-ӗм* (өстәл-ем), *сӗтел-ӳ* (өстәл-ең), *сӗтел-ӗ* (өстәл-е) [Сергеев, б. 266, 267].

Л. П. Сергеев аңлатуынча, I һәм II зат тартым кушымчалары хәзерге чуваш телендә сирәк кулланыла: предметның I затка каравын кушымчасыз, контекст белән белдерергә мөмкин. Мәсәлән: *куҫ курмасть* (күз күрми) үрнәгендә, күзнең I затка каравы контексттан аңлашыла. Шуңа бәйле рәвештә I зат тартым кушымчалары сөйләмдә сирәгрәк очрый дип аңлата галим [Сергеев, б. 270]. Предметның кемгә каравы катнаш ысул белән дә белдерелергә мөмкин булып (*санӑн (хӑвӑн) кӗнек-ӳ* (синең (үзеңнең) китаб-ың), *пирӗн (хамӑрӑн) учител-ӗмӗр* (безнең (үзебезнең) укытучы-быз)), мондый тезелмәләрнең матур әдәбиятта күбрәк очрап, сөйләм теленә бик үк характерлы булмавы искәртелә [Сергеев, б. 272]. III зат башка затлардан аермалы буларак, һәрвакыт тартым кушымчасын ала: *(унӑн) тетрач-ӗ* ((аның) дәфтәр-е), *(вӗсен) пӳрч-ӗ* ((аларның) йорт-ы), *(хӑйӗн) лаш-и* ((үзенең) ат-ы) [Сергеев, б. 272].

Күренгәнчә, татар, башкорт һәм чуваш грамматикаларында тартым конструкцияләре җентекләп тикшерелгән. Тюрколог галимнәр

тартымлы тезелмәләрнең, нигездә – язма телгә, тартымсыз тезелмәләрнең сөйләм теленә характерлы булуын дәлиллиләр. Теоретик тикшеренүләрдән күренгәнчә, тартым категориясе, аның асылы, кулланылышы, типлары төрки тел белемендә шактый өйрәнелгән дияргә була. Шулай да ачыкланып бетмәгән кайбер сораулар, әйтик, тартым категориясенең аерым структур типларына бәйле кулланылыш ешлыгы, кулланылыш парадигмасы, грамматик табигате, стилистик үзенчәлекләре бүгенге көндә тиешле дәрәҗәдә ачыкланып беткән дип әйтә алмыйбыз. Шуны истә тотып, әлеге хезмәттә төп максат итеп тартым кушымчасының төрки телләрдә, аерым алганда, татар, башкорт һәм чуваш телләрендә кулланылыш ешлыгын анализлау мәсьәләсе куелды. Әлеге фәнни мәкалә кысаларында татар, башкорт һәм чуваш телләрендә I яки II зат тартым формаларын тикшерү күздә тотыла. Тикшеренү объекты итеп татар, башкорт һәм чуваш телләренең иялек килешендәге I яки II зат алмашлыгы белән тартымлы яки тартымсыз исемнән торган сүзтезмәләр (тартым конструкцияләре) алынды. Тартым кушымчаларының кулланылу ешлыгын тикшерүдә статистик ысул, нәтиҗәләрне анализлауда чагыштырма һәм тасвирлама ысуллар файдаланылды. Тикшеренүдә түбәндәге онлайн корпуслардан файдаландык:

1) Татар теленең язма корпусы. Бу сайтта 356 миллионнан артык сүз теркәлгән [http://corpus.tatfolk.ru/index_tt.php].

2) Башҡорт шиғриәте корпусы. 1 миллионнан артык сүз теркәлгән. 500 меӊ чамасы шигъри юл, 101 шагыйрьнең 13 меңнән артык шигырен үз эченә ала [http://web-corpora.net/bashcorpus/search/].

3) Чӑваш чӗлхин икчӗлхеллӗ ҫӳпҫи (Двуязычный корпус чувашского языка). 1 миллионнан артык сүз теркәлгән. Башлыча газета-журнал мәкаләләрен һәм дини эчтәлекле язмаларны үз эченә ала [http://corpus.chv.su/].

Әлеге корпуслар нигезендә ясалган анализ нәтиҗәләре буенча татар, башкорт һәм чуваш телләрендәге I һәм II зат тартым кушымчаларының кулланылу ешлыгына бәйле гомуми тенденцияләр түбәндәгеләр:

1) «Татар теленең язма корпусы»ннан I һәм II зат алмашлыгына 250 шәр, барлыгы 1000 тартым конструкциясен туплап, тартымлы һәм тартымсыз конструкцияләрнең кулланылыш ешлыгы буенча шундый нәтиҗәләр алынды:

| | тартымсыз | тартымлы |
|---|---|---|
| I зат берлек | 91 (36.4%) | **159 (63.6%)** |
| I зат күплек | **209 (83.6%)** | 41 (16.4%) |
| II зат берлек | 51 (20.4%) | **199 (79.6%)** |
| II зат күплек | **134 (53.6%)** | 116 (46.4%) |

2) «Башҡорт шиғриәте корпусы»ннанI һәм II зат алмашлыгына 50 шәр, барлыгы 200 тартымлы тезелмәләрне туплап, кулланылыш ешлыгы буенча шундый нәтиҗәләр алынды:

| | тартымсыз | тартымлы |
|---|---|---|
| I зат берлек | 20 (40.0%) | **30 (64.0%)** |
| I зат күплек | **45 (90.0%)** | 5 (10.0%) |
| II зат берлек | 8 (16.0%) | **42 (84.0%)** |
| II зат күплек | **33 (66.0%)** | 17 (34.0%) |

3) «Чӑваш чӗлхин икчӗлхеллӗ ҫӳпҫи (Двуязычный корпус чувашского языка)» корпусыннан I һәм II зат алмашлыгына 50 шәр, барлыгы 200 тартым конструкциясен туплап, кулланылыш ешлыгы шундый нәтиҗәләрдән гыйбарәт булды:

| | тартымсыз | тартымлы |
|---|---|---|
| I зат берлек | **42 (84.0%)** | 8 (16.0%) |
| I зат күплек | **49 (98.0%)** | **1 (2.0%)** |
| II зат берлек | 13 (26.0%) | **37 (74.0%)** |
| II зат күплек | **31 (62.0%)** | **19 (38.0%)** |

Корпуслардан алынган материалларны анализлау нәтиҗәләреннән аңлашылганча, татар һәм башкорт телләрендә иялек килешендәге зат алмашлыгының төренә карап, ике форманың кулланылыш ешлыгында аерма күзәтелде. Ике телдә дә берлек сан зат алмашлыгы белән кулланылган конструкцияләрдә аналитик форма аналитик-синтетик формага караганда азрак очрады. Киресенчә, күплек сан зат алмашлыклы белән кулланылган конструкцияләрдә аналитик форма аналитик-синтетик формага караганда күбрәк теркәлде. Моның төп сәбәбен, күплек зат тартым кушымчаларының чагыштырмача озынрак булып, экономияләү аркылы ешрак кыскартылуга дучар булуы белән аңлатырга мөмкиндер. Ике затны үзара чагыштырганда, аналитик форма II затка караганда I затта активрак икәнлеге дә аңлашылды. Стильгә карап ике форманың кулланылу ешлыгында аермалар булса да, югарыда әйтелгән гомуми тенденцияләрдә зур аермалар күзәтелмәде. Безнеңчә, ике форманың кулланылыш ешлыгын грамматикаларда аңлатылган стиль

яки эмоциональлек белән генә билгеләп булмый. Ул зат алмашлыгының, тартым конструкциясенең һәм тартым конструкциясендәге исемнең төренә карап та үзгәрә дип әйтергә мөмкин. Күренгәнчә, өч телдә дә тартым кушымчаларының кулланылу ешлыгы, зат һәм санга карап аерылып тора һәм өч телдә дә I зат күплек сан тартым кушымчасы иң сирәк, ә II зат берлек сан тартым кушымчасы иң еш очрый. Өч телдә уртак тенденцияләр күзәтелүе игътибарга лаек.

Нәтиҗәләрдән чыгып, тартым кушымчаларының кулланылыш ешлыгына түбәндәге ике фактор тәэсир итә дип әйтергә мөмкин:

1) Зат алмашлыгы белдергән затның күплеге. Өч телдә дә II зат күплек сан алмашлыгы (тат. *сез*, баш. *һеҙ*, чув. *эсир*) берДәнбер затны гына белдерергә мөмкин. I зат күплек сан алмашлыгы (тат. *без*, баш. *беҙ*, чув. *эпир*) исә, һәрвакыт икедән күбрәк кешене белдерә. Шунлыктан, зат алмашлыгы белдергән зат күплеккә ия булса, тартым кушымчасының кулланылу ешлыгы сирәк булырга мөмкин. II зат күплек сан тартым кушымчасының кулланылу ешлыгы да берлек сан тартым кушымчаларына караганда сирәгрәк. Бу фактор исә чуваш теленә кагылмый. Чөнки чуваш телендә I зат берлек сан тартым кушымчасының кулланылу ешлыгы II зат күплек сан тартым кушымчасыннан сирәгрәк.

2) Тартым кушымчасының озынлыгы. Чагыштырмача озын тартым кушымчалары, экономия принцибыннан чыгып, ешрак төшеп калырга мөмкин. Татар һәм башкорт телләрендә күплек сан тартым кушымчалары (тат. *-(ы)быз/-(е)без, -(ы)гыз/-(е)гез*; баш. *-(ы)быҙ/-(е)беҙ, -(ы)ғыҙ/-(е)геҙ*) берлек сан тартым кушымчаларына (*-(ы)м/-(е)м, -(ы)ң/-(е)ң*) караганда озынрак. Чуваш телендә I зат күплек тартым кушымчасы (*-(ă)мăр/-(ĕ)мĕр*) башка тартым кушымчаларына (*-(ă)м/-(ĕ)м, -у/-ӳ, -(ă)р/-(ĕ)р*) караганда озынрак. Чуваш телендә кыска тартым кушымчалары арасында нигә II зат берлек сан тартым кушымчасы сирәк очрый дигән сорау хәл ителми кала.

Нәтиҗә ясап әйткәндә, өч телдә дә тартым кушымчаларының кулланылыш ешлыгы, зат һәм санга карап аерылып тора: өч телдә дә I зат күплек сан тартым кушымчасы иң сирәк, ә II зат берлек сан тартым кушымчасы иң еш очрый. Безнең карашка, моңа ике фактор тәэсир итә: 1) зат алмашлыгы белдергән затның күплеге; 2) тартым кушымчасының озынлыгы. Болардан тыш, башка сәбәпләр дә булырга мөмкин. Мондый сорауларны ачыклау һәм әлеге тенденциянең башка төрки телләрдә дә чагылышын тикшерү алдагы бурычыбыз булып тора.

**Әдәбият**

*Вәлиуллина З. М., Зиннәтуллина К. З., Сәгыйтов М. А.* Хәзерге татар әдәби теле морфологиясе. Казан: КДПИ, 1972. 206 б.

*Зәйнуллин М. В.* Хәҙерге башҡорт әҙәби теле: морфология. Өфө: БДУ, 2002. 388 б.

*Тумашева Д. Г.* Хәзерге татар әдәби теле: Морфология. Казан: Татарстан китап нәшрияты, 1978. 221 б.

*Хангилдин В. Н.* Татар теле грамматикасы. Казан: Татарстан китап нәшрияты, 1959. 642 б.

*Харисова Ч. М.* Хәзерге татар әдәби теле морфологиясеннән лекцияләр. Казан: Татар дәүләт гуманитар-педагогика университеты, 2010. 128 б.

*Хисамова Ф. М.* Татар теле морфологиясе. Казан: Мәгариф нәшрияты, 2006. 335 б.

*Дмитриев Н. К.* Грамматика башкирского языка. АН СССР. М., 1948. 276 с.

*Закиев М. З. и др.* Татарская грамматика. Т. II. Морфология. Казань: Академия наук Татарстана, 1993. 397 с.

*Юлдашев А. А.* Грамматика современного башкирского литературного языка. М.: Наука, 1981. 495 с.

*Сергеев Л. П., Андреева Е. А., Котлеев В. И.* Чăваш чĕлхи: чăваш филологи факультечĕн студенчĕсем валли хатĕрленĕ вĕренӳ кĕнеки. Шупашкар: Чăваш кĕнеке изд-ви, 2012. 431 с.

*HishiyamaY.* Possessive person markings in Tatar possessive noun phrases. Language, area and culture studies [25]. Tokyo: Tokyo University of Foreign Studies, 2019. 93-113 pp.

*Krueger J.* Chuvash Manual. Introduction, Grammar, Reader, and Vocabulary. Indiana University Publications, Uralic and Altaic Series 7.The Hague: Mouton, 1961.271pp.

**Чыганаклар**

Башҡорт шиғриәте корпусы. Режим доступа: http://web-corpora.net/bashcorpus/search/. (Дата обращения: 05.09.2019)

Татар теленең язма корпусы. Режим доступа: http://corpus.tatfolk.ru/index_tt.php. (Дата обращения: 05.09.2019)

Чăваш чĕлхин икчĕлхеллĕ çӳпçи. Режим доступа: http://corpus.chv.su/. (Дата обращения: 05.09.2019)

# ЧАСТОТНОСТЬ ИСПОЛЬЗОВАНИЯ АФФИКСОВ ПРИНАДЛЕЖНОСТИ 1 И 2 ЛИЦА В ТАТАРСКОМ, БАШКИРСКОМ И ЧУВАШСКОМ ЯЗЫКАХ

**Хисияма Юто**,
Япония, 183-8534, Токио ш., Асахи-тё, Футю-си, 3-11-1,
boltwatts@gmail.com.

**Гузель Амировна Набиуллина,**
Казанский федеральный университет,
Россия, 420008, г. Казань, ул. Кремлевская, д. 18,
guzelnab2@yandex.ru.

Многие тюркские языки имеют категорию принадлежности. Однако, как указывается в тюркологических исследованиях, в некоторых тюркских языках, включая татарский, башкирский и чувашский, аффикс принадлежности необязателен, если конструкция принадлежности включает местоимение I или II лица: *минем дәфтәр (ем), синең дәфтәр (ең), безнең дәфтәр (ебез), сезнең дәфтәр (егез)*.

Целью нашего исследования является определение частотности употребления категории принадлежности на материале татарского, башкирского и чувашского языков. В работе доказывается, что не только в татарском, но и в башкирском, и чувашском языках аффиксы принадлежности варьируются в зависимости от лица и числа. Аффикс принадлежности I лица множественного числа встречается чаще всего, а аффикс принадлежности II лица единственного числа имеет самую низкую частотность. На наш взгляд, на это влияют два фактора: 1) обозначение личным местоимением более одного человека, 2) длина аффикса принадлежности.

**Ключевые слова:** татарский язык, башкирский язык, чувашский язык, категория принадлежности, аффикс принадлежности.

DOI: 10.26907/2311-2042-2019-13-2-18-26

# SEMANTIC SYNCRETISM OF CONSTRUCTIONS EXPRESSING CIRCUMSTANTIAL RELATIONS IN TATAR AND OTHER TURKIC LANGUAGES

**Leniza Gazinurovna Khabibullina**,
G. Ibragimov Institute of Language, Literature and Art,
RT Academy of Sciences,
12 Karl Marx Str., Kazan, 420111, Russian Federation,
valievalg@mail.ru.

**Daniya Abuzarovna Salimova,**
Elabuga Institute of Kazan Federal University,
89 Kazanskaya Str., Elabuga, 423604, Russian Federation,
daniya.salimova@mail.ru.

The study of circumstantial relations, reflecting the interdependence of reality phenomena, in Tatar and other Turkic languages, is mainly reduced to the analysis of individual private varieties. At the same time, the combination, the secret representation in one syntactic construction of two or more meanings, often remains out of sight of researchers and requires a multidimensional scientific description. The presented article, based on the material of Tatar and other Turkic languages, explores how the meanings of purpose and reason, condition and time are interwoven, which allows defining the nature of intermediate semantic communications.

**Key words**: Tatar language, Turkic languages, circumstantial relations, semantic syncretism, cause and effect, purpose, condition, time.

The study of semantic relations between syntactic formations in related Turkic languages is of scientific interest in terms of identifying similarities and differences of linguistic means used to express particular relationships and to observe the representation of one semantic concept in different languages.

The purpose of the article is to identify the semantic syncretism of constructions, denoting the existing relations in Tatar and other Turkic languages (in particular, purpose and cause-effect, condition and time). To solve this problem, we used the methods of linguistic description, transformation, and semantic analysis.

The data were obtained from works of fiction, small genres of Turkic folklore, and colloquial speech.

The research was carried out in the structural and semantic aspects and on the basis of the theory of synchronous transition (syncretism), developed by V. V. Babaytseva [Babaitseva]. The theory is based on the philosophical views of M. Foucault, J. Holton, N. da Costa, N. Vasiliev, N. Bor, L. Zadeh, etc. and logically continues the thoughts of L. V. Shcherba: along with the names of the basic concepts there are additional shades characteristic of other concepts [Druzhinina].

Syncretic constructions have a mutual combination of different types of semantic relations, with the syncretism of features in different proportions.

Circumstantial relations are characterized by a wide-semantic variation. In linguistics, their logical and semantic types are defined: space, time, cause-effect, purpose, condition, and inverse condition. As for the syncretism of the cause-effect and purpose relationships, cause is a matter that creates another phenomenon called ‘effect’. In the context of time, the reason is always ahead of the effect. In purpose relationships, one situation is a potential outcome of the other. At the same time, in one of these situations, the stimulus is reported and the predicted result is presented, and in the other there is a case leading to the expected result.

“At the initial stages of the thinking development, there is a mutual combination of the meanings of cause and purpose” [Maslieva, p.26]. The ancient Greek philosopher Aristotle (384-322 BC) identified four different causes of reality, including the cause of purpose [Radugin, p. 60]. Thus, purpose is seen as a kind of cause.

According to some linguists, purpose is a concept that can be explained, and reason is inexplicable. “Purpose is explained through cause; on the other hand, when describing causal vocabulary, we

cannot but refer to the situation of purpose" [Boguslavskaia, Levontina, p. 69].

Indeed, the concept of purpose includes the meaning of cause. In the presence of purpose relations, the reason for the subject process performance is the achievement of the expected result. Thus, the concept of purpose is directly related to the desires and aims of the subject.

The difficulty in separating purpose and cause-and-effect relations in Tatar and other Turkic languages is primarily due to the use of the same means in the constructions expressing them.

In Turkic languages, the adverbial of purpose / adverbial clause of purpose and adverbial modifier of cause / causal clause can subordinate the principal part / principal clause with the help of the postposition *өчен* or *дип*. For example: tat. . *Егет тә, кыз да тырышлыклары **өчен** уңыш бәйрәмендә бүләкләнәләр* (G. Mukhametshin); *Без бит монда хушлашыр **өчен** килдек* (R. Zaidulla).

In both sentences there is the postposition *өчен,* which connects the subordinator and the principal part, and establishes certain semantic relations between them (*тырышлыклары өчен бүләкләнәләр* and *хушлашыр өчен килдек*). In the first example, a young man and a girl are awarded for diligence, that is, the award is the result of their efforts, perseverance is the reason for the award (cause-effect relationship is expressed). The second sentence has a specific purpose of coming (came to say goodbye), the action aimed at the future, it is formally expressed (adverbial of purpose is the verb in the future tense *хушлаш**ыр***), in this case, there are purpose relations between the components.

The purpose always refers to another action, which is the means of its realization in another period of time. In the presence of cause-effect relationships, they happen simultaneously, despite the fact that cause is performed before effect: a temporal sequence of events.

In the following Tatar example: (1) *Җир белән Күк сугыша **дип,*** (2) *йөрәгем яргаланды* (R. Haris) the subordinate clause (1) is connected with the principal clause (2) with the help of the word *дип.* Between the components of the complex sentence there is a causal relationship: the heart of the lyrical hero causes tension between the Heaven and the Earth.

In these examples the subordinate clauses, which connect the principal clause by means of the word *дип* and the imperative mood verb form are final clauses because the processes, identified in the second sentence, achieve the purposes identified in the first one.

The meaning of purpose, as opposed to cause-effects, is closely related to the semantics of desire. The form of imperative mood denotes the meaning of desire. For example: azerb. *Вәли јолдашы илә көрүш**сүн дејә** ахшам онлара кетди*; tat. *Балалар ач булма**сын дип**, сату өчен икмәк пешерә, прокатка машина алып кием тегә, бәйләү бәйли* (A. Bayanov); uzb. *Вақт ўтма**син деб**, болтни устахонада тайёрлатдим.*

The ways of expressing causal relationships are the forms of the adverbial participle. With the help of the adverbial participle, additional working environment is expressed. The meaning of purpose can manifest itself through the adverbial participle form.

As can be seen from the analysis of examples, when presenting cause-effect relations the adverbial participle forms, in most cases, indicate motives for the execution of the process and emotional and mental state of the subject. For example: tat. *Баласын тартып алуларыннан курк**ып**, күкрәгенә ныграк кысты* (M. Khuzin); *Албуга уңайсызлан**ып** кып-кызыл булды* (N. Fattah); *Хаксызлыкны күр**еп** ярсыйм, шашам*, *Матурлыкны күр**еп** тезләнәм* (R. Valeev).

As we can see, these sentences express reasons, which have involuntarily led to the result. The forced result may depend on the physiological state of the person. For example: *Тән өше**п**-туң**ып** калтырана* (N. Gimatdinova).

Thus, the above example expresses the state of the subject and the cause of this state.

If there is a purpose relation, the process takes place with a specific purpose, voluntarily, the specific intention of the subject is expressed. For example: tat. *Әнкәй, бәлеш пешерергә җыен**ып**, мичкә ягып җибәрде* (R.Valeev).

In this case, lexical semantics plays a certain role in conveying the meaning of purpose. It is in the verb *җыенырга* (to be going to) that a sense of intention and purpose are expressed.

Purpose can be expressed by postposition *белән*: *эш белән килү*. With this postposition, the cause-effect is specified. As a rule, the reason for the action or the state of the subject is emphasized by means of the postposition *белән*. For example: tat. *Яшьлеге **белән** беркатлы Равилә аларның кулларыннан товарны тартып диярлек ала* (F. Yarullin); *Хаҗиәхмәт үзе килеп керде, кызулыгы **белән** Фатихка сугып җибәрде* (G. Galiev); Turkmen. *Диймек, сен яравсызлык **билен** Ростовда сакланыпсыңда.*

Thus, to separate the purpose and cause-effect relations it is important to define the semantic content of the sentence.

In the case of conditional relations, the subordinate part expresses the condition necessary in the process execution, which is expressed in the principal part. In this respect, they are close to the cause-effect relations, the components of conditional constructions can be considered the cause and effect. Unlike cause, condition is always pointing to alleged events. In other words, condition relations combine the processes that are assumed, that could be performed.

According to viewers, cause-effect and condition-effect relationships are different. According to some linguists, the semantic relationships between condition and result should be seen as causal, that is, cause-effect relations. "The fulfillment of condition automatically leads to the appearance of result, except for the cases when the will of the speaker is expressed. If the narrator knows about the objective regularity, his message returns to the listener [Tipologiia uslovnyh konstruktsii, p. 28]. In conditional constructs, condition and result are defined as possible or impossible.

In Turkic languages, conditional relations in all styles are often expressed in the form of condition, which is the main indicator of the meaning of condition. The form of this verb cannot be the predicate of the principal sentence; it is always the predicate or its part in the subordinate clause. For example: Azerb. *Ишләр тамам јохланма**са**, мән әл чәкән дејиләм*; карач.-балк. *Джылкъы бирден суу ич**се**, тирмен суу азайыр* (a proverb); Tat. *Моң бас**са** күңелне, Җыр белән ачарбыз* (Kh. Tufan); Turkmen: *Гурт агза**саң**, гурт гелер* (a proverb).

In Tatar and other Turkic languages, the synthetic subordinate clause of condition can be connected to the principal clause with an interrogative particle or the words *икән* and *исә*. For example: tat. *Сүз бирергә ашыкма, бирдең**ме** инде – карышма, ди мәкаль* (M. Khasanov); karch.-balk. *Джангур джауарыкъ **эсе**, балчыкъ болур* (a proverb); тат. *Башың яшь **икән** – күп эш алма* (a proverb).

Synthetic subordinate clauses of time can be connected to the principal clause with an interrogative particle: Azerb. *Һава јахшылашды**мы**, ону евдә сахламаг олмур*; karch.-balk. *Декабрь айы жетди**ми**, къыш башланды*

In constructions with a verb of condition there can be the implicit meaning of cause-effect, oppositeness and inverse condition relations. Even in ancient Turkic sources, the ancient form of condition *-сар/-сäр* is used to refer to other types of subordinate clauses (for example, time and cause). *Taydyn jynaq(qa)* ***körsär*** *m(ä)n tör tä ärklig qan olurur.* [Issledovaniia po sravnitel'noi grammatike, p. 215].

The Tatar form *-ганда/-гәндә* is the main indicator of expressing temporal relations, with the help of which a conditional meaning can be established between related words. For example: ***Әйткәндә*** *сүзеңчә эшлә, әйтмә**гәндә** уеңча эшлә* (a proverb) *Газ исе сиз**гәндә**, 04 телефоны буенча хәбәр итегез.*

It is easy to change sentences without breaking their logical meaning: *Әйт**сәң**, сүзеңчә эшлә, әйтмә**сәң**, уеңча эшлә; Газ исе сиз**сә**гез, 04 телефоны буенча хәбәр итегез.*

The form *-ганда* is commonly known to express conditional meanings: *Бис барба**ганда** кем барар?*; bashk. *Теләк менән дәртле йөрәк бул**ғанда**, бөтәһен дә эшләргә мөмкин*; kaz. *Сен маған кел**генде**, театрға бірге баратын едік*; үзб. *Раҳим бизга кел**ганда** кинога борар эдик.*

The analysis of these examples shows that the form *-ганда* allows expressing the relations, arising in the section of values of time and condition.

It should be noted that when expressing the meaning of condition, both temporal facts and repeated, constantly executed events are reported.

When comparing the form *-ганда* with the form *-са,* the components lose their focus on time. For example: tat. *Гаиләдә татулык бул**ганда**, эшләр уңай бара → Гаиләдә татулык бул**са**, эшләр уңай бара.*

In Tatar, adverbial participles, ending with *-гач/-гәч* that are usually used in constructions expressing time, can sometimes be used as conditional adverbial modifiers: *Телә**гәч** сынасыннар* (R. Minnullin)

Sometimes, adverbial participles ending with *-п* can have a conditional meaning. For example: Kirg. *Жалгыз урун**уп**, турмушту көңтөрө албайсың* (a proverb). It means, if you are alone, you cannot change your life. In this example, you can see the cause and effect: you cannot change your life, because you are alone.

When expressing a systematic or periodic repeated connection of two phenomena, there is a mixture of the condition and time semantics: Kum *Бир зат этмеге эсине тюш**се**, ол аны гъакъында йолну мастерине барып тилей*; Tat. *Матур парлар күр**сәм** – куанам* (A. Malikov); *Кит**сә** дә җырлый, кайт**са** да җырлый бу* (S. Suleimanova).

The abstract character of component term relations in conditional constructions is usually peculiar to paroemias and generalized expressions. For example: Alt. *Ат киштезе таныжар, кижи эрмектешсе таныжар* (a proverb); Karach.-balk. *Джангур джауса джерге джауар* (a proverb); kyrg. *Жылуу сөйлөсө, жылан ийинден чыгат* (a proverb); tat. *Гаилә үзара хөрмәт нигезенә корылса, бәхетле була!* (F. Yakhin).

As can be seen from the examples, the forms of present or future tenses are used in paroemias. At the same time, the phrase itself is not connected with time, it refers to general regularity and ordinary phenomena.

The rare use of present tense forms in the past in paroemias is explained by the fact that the past, as a rule, is associated with certain phenomena, specific realities. Past tense forms have the property of individualization, but paroemias tend to generalization. Therefore, past tense forms are not often found in paroemias. For example: Kum. *Яшыртгъын айт**дым** – билмединг, гёрюне айт**дым** – сюймединг* (a proverb).

When predicates of compound sentences express the action without reference to some specific time or some permanent phenomenon, there is syncretism of meanings of time and condition. Most often in such constructions, time conjunctions are used, and the subordinate clause has a generalized meaning. For example: gag. ***Ачан** бирлик йок достларда, ишлӓр гитмӓз хич орада* (a proverb).

Therefore, the most common type of combining circumstantial relations in Tatar and other Turkic languages is the syncretism of cause-effect and time meanings. Both purpose and conditional relations are genetically connected to the cause-effect category.

Circumstantial relations of time serve as a background for relations of cause and effect that are directly linked to the sequence of events.

Usually, the main difference between nominally similar relations of cause-effect and purpose is the activity/passivity of the subject. Purpose refers to the future, and in order to make it a reality, it requires some deliberate, purposeful action.

Conditional relations in combination with time relations form specific condition-time constructions. This type of constructions does not specify whether these events happen simultaneously or successively, because it mainly focuses on their interdependency, rather than on their timing.

In Tatar and other Turkic languages, the main problem with identifying different circumstantial relations stems from the fact that the same nominal indicators can be used in several meanings.

As we can see from the comparative analysis of meaning and circumstantial relations in Tatar and other Turkic languages, they do not always have the necessary indicators to identify their category, the process of transition semantics often happens without any nominal devices. Thus, it is important to consider the interrelation of form and meaning. The analysis of the linguistic data shows that secret meanings and the emergence of synthesized semantics are caused by the need to present complex meaningful information.

**Abbreviations**

Azerb. – Azerbaijan
Alt. - Altai
Bashk. – Bashkir
Gag. – Gagauz
Kaz. – Kazakh
Karachi.- balk. - Karachay-Balkar
Kum. – Kumyk
Kirg. – Kirghiz
Tat. – Tatar
Turkmen – Turkmen
Uzb. – Uzbek

**References**


Babaitseva, V. V. (2000). *Iavleniia perehodnosti v grammatike russkovo iazyka* [The Phenomenon of Transition in the Grammar of the Russian Language]. 640 p. Moscow, Drofa. (In Russian)

Boguslavskaia, O. Yu., Levontina, I. B. (2004). *Smysly 'prithina' i 'tsel'' v estestvennom iazyke* [Meanings 'Reason' and 'Purpose' in Natural Language]. Voprosy iazykoznaniia. No. 2, pp. 68–88. (In Russian)

Druzhinina, S. I. (2008). *Sinkretizm v sisteme slozhnopodthinennyh predlozheniy* [Syncretism in the System of Complex Sentences]. 435 p. Orel, Orel State University. (In Russian)

*Issledovaniia po sravnitel'noi grammatike tiurkskih iazykov. Ch. III. Sintaksis* (1961) [Studies of Comparative Grammar of Turkic Languages. Part. III. Syntax]. Pod obshh. red. N. K. Dmitrieva, N. A. Baskakova, E. I. Ubrjatovoi. 232 p. Moscow, Izd-vo AN SSSR. (In Russian)

Maslieva, O. V. (1980). *Stanovlenie kategorii prithinnosti (na materiale istorii iazyka)* [The Formation of the Category of Causality (based on the history of language)]. Pod red. M. G. Makarova. 105 p. Leningrad, Nauka. (In Russian)

Radugin, A. A. (2004). *Filosofiia* [Philosophy]. 336 p. Moscow, Tsentr. (In Russian)

*Tipologiia uslovnyh konstruktsii* (1998) [Typology of Conditional Constructions]. Otv. red. V. S. Hrakovskii. 583 p. St. Petersburg, Nauka. (In Russian)

# ТАТАР ҺӘМ БАШКА ТӨРКИ ТЕЛЛӘРДӘ ХӘЛ МӨНӘСӘБӘТЛӘРЕН БЕЛДЕРӘ ТОРГАН КОНСТРУКЦИЯЛӘРНЕҢ МӘГЪНӘ СИНКРЕТИКЛЫГЫ

**Лениза Газинуровна Хәбибуллина,**
ТР ФАнеӊ Г. Ибраһимов исемендәге Тел, әдәбият һәм сәнгать институты,
Россия, 420111, Казан ш., Карл Маркс ур., 12 нче йорт,
valievalg@mail.ru.

**Дания Әбүзәровна Сәлимова,**
Казан федераль университетының Алабуга институты,
Россия, 423604, Алабуга ш., Казан ур., 89 нчы йорт,
daniya.salimova@mail.ru.

Татар һәм башка төрки телләрдә реаль чынбарлык күренешләренең үзара бәйлелеген чагылдыручы хәл мөнәсәбәтләрен өйрәнү башлыча аларның аерым бер төрен анализлауга кайтып кала. Шул ук вакытта бер синтаксик конструкциядә ике һәм аннан да күбрәк мәгънә керешүе, синкретиклыгы еш кына тикшерүчеләр игътибарыннан читтә кала һәм фәнни тасвирлауны таләп итә. Әлеге мәкаләдә татар һәм башка төрки телләр материалында максат һәм сәбәп-нәтиҗә, шарт һәм вакыт мәгънәләренең бәйләнеш характеры билгеләнә, бу исә ике мәгънә арасында торган мөнәсәбәтләрнең асылын ачыкларга мөмкинлек бирә.

**Төп төшенчәләр:** татар теле, төрки телләр, хәл мөнәсәбәтләре, мәгънә синкретиклыгы, сәбәп-нәтиҗә, максат, шарт, вакыт.

Тугандаш төрки телләрдә синтаксик берәмлекләр арасындагы мәгънәви бәйләнешләрне өйрәнү теге яки бу мөнәсәбәт белдерүдә катнаша торган тел чараларының охшаш һәм аермалы якларын ачыклау, асылында бер үк семантик төшенчә яткан категорияләрнең төрле телләрдә бирелешен күзәтү ягыннан фәнни кызыксыну тудыра.

Мәкаләнең максаты – татар һәм башка төрки телләрдә хәл мөнәсәбәтләрен (аерым алганда максат һәм сәбәп-нәтиҗә, шарт һәм вакыт) белдерә торган конструкцияләрнең мәгънә синкретиклыгын ачыклау. Әлеге мәсьәләне чишү өчен, лингвистик тасвирлау, трансформацион һәм семантик анализ методлары кулланылды.

Фактик материал матур әдәбият әсәрләреннән, төрки фольклорның кече жанрларыннан һәм сөйләм теленнән алынды.

Фәнни тикшеренү эше структур-семантик аспектта, аеруча В. В. Бабайцева тарафыннан системалы рәвештә эшләнгән синхрон күчеш (синкретиклык) теориясенә [Бабайцева] таянып үткәрелде. Әлеге теория М. Фуко, Дж. Холтон, Н. да Коста, Н. Васильев, Н. Бор, Л. Заде һ. б. философик карашларына нигезләнә һәм логик яктан Л.В. Щербаның төп төшенчәләр атамалары белән беррәттән башка төшенчәләргә хас булган өстәмә төсмерләр дә барлыгы хакындагы фикерләрен дәвам итә [Дружинина].

Синкретик конструкцияләрдә төрле тип мәгънә мөнәсәбәтләренең үзара керешүе күзәтелә, шул ук вакытта билгеләр синкретиклыгы, кагыйдә буларак, төрле пропорцияләрдә була.

Хәл мөнәсәбәтләренә киң семантик вариантлылык хас. Тел белемендә аларның түбәндәге логик-мәгънәви төрләре билгеләнгән: пространство, вакыт, сәбәп-нәтиҗә, максат, шарт һәм кире шарт. Сәбәп-нәтиҗә һәм максат мөнәсәбәтләренең синкретиклыгына килгәндә, сәбәп – нәтиҗә дип аталган башка күренешне барлыкка китерүче эш-гамәл. Вакыт ягыннан сәбәп һәрвакыт нәтиҗәдән алда башкарыла. Максат мөнәсәбәтләрендә исә бер ситуация икенчесенең потенциаль нәтиҗәсе буларак күзаллана. Шул ук вакытта бу ситуацияләрнең берсендә стимул турында хәбәр ителә һәм фараз ителүче нәтиҗә белдерелә, ә икенчесендә – көтелгән нәтиҗәгә китерүче эш-гамәл атала.

«Фикерләү үсешенең башлангыч этапларында сәбәп һәм максат мәгънәләренең үзара керешүе күзәтелә» [Маслиева, б. 26]. Борынгы грек философы Аристотель (б. э. к. 384–322 еллар) чынбарлыкның дүрт төрле

сәбәбен, шул исәптән максат сәбәбен аерып күрсәтә [Радугин, б. 60]. Шулай итеп, максат сәбәпнең бер төре буларак карала.

Кайбер телче-галимнәр фикеренчә, максат – аңлатып була торган, ә сәбәп – аңлатып булмый торган төшенчә. «Максат сәбәп аркылы аңлатыла, әмма, икенче яктан караганда, сәбәп лексикасын тасвирлаган вакытта, без максат итү ситуациясенә мөрәҗәгать итми кала алмыйбыз» [Богуславская, Левонтина, б. 69].

Чыннан да, максат төшенчәсенә сәбәп мәгънәсе дә керә. Максат мөнәсәбәте булганда, субъектның процессларны башкару сәбәбе – көтелгән нәтиҗәгә ирешү. Шулай итеп, максат төшенчәсе субъектның теләк-омтылышлары белән турыдан-туры бәйләнгән.

Татар һәм башка төрки телләрдә максат һәм сәбәп-нәтиҗә мөнәсәбәтләрен аерудагы кыенлык беренче чиратта аларны белдерүче конструкцияләрдә бер үк бәйләүче чаралар куллану белән бәйле.

Төрки телләрдә максат хәле/иярчен максат җөмлә, сәбәп хәле/иярчен сәбәп җөмлә кебек үк, баш кисәккә/баш җөмләгә *өчен* бәйлеге, *дип* сүзе ярдәмендә иярә ала. Мәсәлән: тат. *Егет тә, кыз да тырышлыклары* ***өчен*** *уңыш бәйрәмендә бүләкләнәләр* (Г. Мөхәммәтшин); *Без бит монда хушлашыр* ***өчен*** *килдек* (Р. Зәйдулла).

Ике җөмләдә дә иярчен һәм баш компонентларны үзара бәйләүче һәм алар арасында билгеле бер мәгънә мөнәсәбәтләре урнаштыручы *өчен* бәйлеге бар (*тырышлыклары өчен бүләкләнәләр* һәм *хушлашыр өчен килдек*). Беренче мисалда егет белән кызны тырышлыклары өчен бүләкliләр, ягъни бүләкләнү – аларның тырышлыгы нәтиҗәсе, тырышлык – бүләкләнү сәбәбе (сәбәп-нәтиҗә мөнәсәбәте белдерелә). Икенче җөмләдә килүнең конкрет максаты атала (*хушлашыр өчен килдек*), гамәл киләчәккә юнәлдерелгән, бу хәтта формаль яктан белдерелгән (максат хәле – киләчәк заман формалы фигыль: *хушлаш**ыр***), бу очракта компонентлар арасында максат мөнәсәбәте урнаша.

Максат һәрвакыт аны тормышка ашыру өчен чара булучы эш-хәлгә карата башка вакыт яссылыгына карый. Сәбәп-нәтиҗә мөнәсәбәте булганда, сәбәп нәтиҗәдән алда үтәлүгә, ягъни вакыйгаларның вакыт ягыннан эзлеклелегенә карамастан, алар бер заман яссылыгында ята.

Тат. (1) *Җир белән Күк сугыша* ***дип****,* (2) *йөрәгем яргаланды* (Р. Харис) мисалында иярчен җөмлә (1) баш җөмлә (2) белән *дип* сүзе ярдәмендә бәйләнгән. Кушма җөмлә компонентлары арасында сәбәп-нәтиҗә мөнәсәбәте урнаша: лирик геройның йөрәге яргалануның сәбәбе – Җир белән Күк сугышуы.

Түбәндәге мисалларда баш җөмләгә *дип* сүзе һәм хәбәрнең боеру наклонениесе формасы ярдәмендә ияргән иярчен җөмләләр – максат җөмләләр, чөнки икенче хәбәрлек үзәкләрдә аталган процесслар, беренчеләрендә әйтелгән максатларга ирешү өчен, махсус башкарыла.

Максат мәгънәсе, сәбәп-нәтиҗәдән аермалы буларак, теләк семантикасы белән тыгыз бәйләнгән. Боеру наклонениесе формасы теләк мәгънәсен белдерә. Мәсәлән: әзерб. *Вәли јолдашы илә көрүш**сүн дејә*** *ахшам онлара кетди*; тат. *Балалар ач була**сын дип**, сату өчен икмәк пешерә, прокатка машина алып кием тегә, бәйләү бәйли* (Ә. Баянов); үзб. *Вақт ўтма**син деб**, болтни устахонада тайёрлатдим.*

Хәл фигыль формалары да сәбәп-нәтиҗә мөнәсәбәтен белдерүнең бер чарасы булып торалар. Хәл фигыль ярдәмендә өстәмә эш-хәлдә булган сәбәп белдерелә. Максат мәгънәсе дә хәл фигыль формалары аша күрсәтелә ала.

Мисалларны анализлаудан күренгәнчә, сәбәп-нәтиҗәне белдергәндә, хәл фигыль формалары күпчелек очракта теге яки бу процессның үтәлү мотивларына, эш-гамәл башкаручының эмоциональ-психик халәте, хис-кичерешләренә ишарәли. Мәсәлән: тат. *Баласын тартып алуларыннан курк**ып**, күкрәгенә ныграк кысты* (М. Хуҗин); *Албуга уңайсызлан**ып** кып-кызыл булды* (Н. Фәттах); *Хаксызлыкны күр**еп** ярсыйм, шашам*, *Матурлыкны күр**еп** тезләнәм* (Р. Вәлиев).

Күргәнебезчә, әлеге җөмләләрдә ихтыярсыз нәтиҗәгә китергән сәбәпләр белдерелә. Ихтыярсыз нәтиҗә кешенең физиологик халәтенә бәйле була ала. Мәсәлән: *Тән өше**п**-туң**ып** калтырана* (Н. Гыйматдинова).

Шулай итеп, югарыда каралган мисалларда субъектның хәл-торышы һәм әлеге халәтнең сәбәбе белдерелә.

Максат мөнәсәбәте булганда, процесс билгеле бер максат белән, ихтыяри башкарыла, субъектның конкрет нияте чагыла. Мәсәлән: тат. *Әнкәй, бәлеш пешерергә җыен**ып**, мичкә ягып җибәрде* (Р. Вәлиев).

Әлеге очракта максат мәгънәсен белдерүдә билгеле бер рольне лексик семантика башкара.

*Җыенырга* фигылендә үк ният, максат мәгънәләре бар.

Максат мәгънәсе *белән* бәйлеге ярдәмендә белдерелә ала: *эш белән килү*. Шушы бәйлек белән сәбәп-нәтиҗә дә күрсәтелә. Кагыйдә буларак, *белән* бәйлеге ярдәмендә процессның яки субъектның халәтенең сәбәбе буларак аңа хас сыйфат ассызыклана. Мәсәлән: тат. *Яшьлеге **белән** беркатлы Равилә аларның кулларыннан товарны тартып диярлек ала* (Ф. Яруллин); *Хаҗиәхмәт үзе килеп керде, кызулыгы **белән** Фатихка сугып җибәрде* (Г. Галиев); төрекм. *Диймек, сен яравсызлык **билен** Ростовда сакланыпсыңда.*

Шулай итеп, максат һәм сәбәп-нәтиҗә мөнәсәбәтләрен аеру өчен, җөмләнең мәгънәви эчтәлегенә мөрәҗәгать итү мөһим.

Шарт мөнәсәбәтләре вакытында иярчен кисәк баш кисәктә белдерелгән процессның үтәлеше өчен кирәк булган шартны белдерә. Бу яктан алар сәбәп-нәтиҗә мөнәсәбәтләренә якын, шарт конструкциясенең компонентлары нигез һәм нәтиҗә буларак карала ала. Сәбәптән аермалы буларак, шарт һәрвакыт фараз ителгән вакыйгаларга күрсәтә. Икенче төрле әйткәндә, шарт мөнәсәбәтләре фаразланган, үтәлүе мөмкин булган процессларны берләштерә.

Сәбәп-нәтиҗә һәм шарт-нәтиҗә мөнәсәбәтләренә карата телчеләрнең фикерләре бердәй түгел. Кайбер лингвистлар әйтүенчә, шарт һәм нәтиҗә арасындагы семантик бәйләнешне каузаль, ягъни сәбәп-нәтиҗә бәйләнеше дип санарга кирәк. «Шартның үтәлүе, сөйләүченең ихтыярыннан тыш, автоматик рәвештә нәтиҗәнең барлыкка килүенә китерә. Сөйләүченең роле, объектив закончалык булуны белеп, аның турында тыңлаучыга хәбәр итүгә кайтып кала» [Типология условных конструкций, б. 28]. Шарт конструкцияләрендә шарт һәм нәтиҗә мөмкин яки мөмкин түгел буларак билгеләнә.

Төрки телләрдә шарт мөнәсәбәтләре барлык стильләрдә дә шарт мәгънәсенең төп күрсәткече булган шарт фигыль формасы белән аеруча еш белдерелә. Әлеге фигыль формасы баш җөмләнең хәбәре була алмый, һәрвакыт иярчен җөмлә хәбәре составында була. Мәсәлән: әзерб. *Ишләр тамам јохланма**са**, мән әл чәкән дејиләм*; карач.-балк. *Джылкъы бирден суу ич**се**, тирмен суу азайыр* (Мәкаль); тат. *Моң бас**са** күңелне, Җыр белән ачарбыз* (Х. Туфан); төрекм. *Гурт агза**саң**, гурт гелер* (Мәкаль).

Татар һәм башка төрки телләрдә синтетик иярчен шарт җөмлә баш җөмләгә сорау кисәкчәсе, *икән, исә* сүзләре ярдәмендә иярә ала. Мәсәлән: тат. *Сүз бирергә ашыкма, бирдең**ме** инде – карышма, ди мәкаль* (М. Хәсәнов); карач.-балк. *Джангур джауарыкъ **эсе**, балчыкъ болур* (Мәкаль); тат. *Башың яшь **икән** – күп эш алма* (Мәкаль).

Синтетик иярчен вакыт җөмлә дә баш җөмләгә сорау кисәкчәсе ярдәмендә иярә ала: әзерб. *Һава јахшылашды**мы**, ону евдә сахламаг олмур*; карач.-балк. *Декабрь айы жетди**ми**, къыш башланды.*

Шарт фигыль формалы конструкцияләрдә имплицит рәвештә сәбәп-нәтиҗә, каршы куюу һәм кире шарт мәгънәләре була ала. Борынгы төрки чыганакларда ук борынгы шарт формасы *-сар/-сäр* башка төр иярчен җөмләләрне (мәсәлән, вакыт, сәбәп) белдерү өчен кулланыла: *Taydyn jynaq(qa)* ***körsär*** *m(ä)n tör tä ärklig qan olurur.* 'Мин өскә карагач, алгы урында Эрклигхан утыруын күрдем' [Исследования по сравнительной грамматике тюркских языков, б. 215].

Татар телендә *-ганда/-гәндә* формасы вакыт мөнәсәбәтләрен белдерүнең төп күрсәткече булуга карамастан, аның ярдәмендә бәйләнгән сүзләр арасында шарт мәгънәсе дә урнаша ала. Мәсәлән: *Әйт**кәндә** сүзеңчә эшлә, әйтмә**гәндә** уеңча эшлә* (Мәкаль); *Газ исе сиз**гәндә**, 04 телефоны буенча хәбәр итегез.*

Җөмләләрне, логик мәгънәне бозмыйча, бик җиңел үзгәртеп була: *Әйт**сәң**, сүзеңчә эшлә, әйтмә**сәң**, уеңча эшлә; Газ исе сиз**сәгез**, 04 телефоны буенча хәбәр итегез.*

*-Ганда* формасының шарт мәгънәсен алуны гомумтөрки күренеш дияргә була: алт. *Бис барба**ганда** кем барар?*; башк. *Теләк менән дәртле йөрәк бул**ганда**, бөтәһен дә эшләргә мөмкин*; каз. *Сен маған кел**генде**, театрға бірге баратын едік*; үзб. *Раҳим бизга кел**ганда** кинога борар эдик.*

Мисалларны анализлаудан күренгәнчә, *-ганда* формасы вакыт һәм шарт мәгънәләре киселешендә барлыкка килүче мөнәсәбәтләрне белдерергә ярдәм итә.

Шуны да искәртергә кирәк: шарт мәгънәсе белдерелгәндә, бер генә вакыт факты түгел, ә кабатланучы, һәрвакыт башкарылучы вакыйгалар турында хәбәр ителә.

*-Ганда* формасын *-са* формасына алыштырганда, компонентлар арасындагы вакытка юнәлгәнлек югала. Мәсәлән: тат. *Гаиләдә татулык бул**ганда**, эшләр уңай бара → Гаиләдә татулык бул**са**, эшләр уңай бара.*

Татар телендә гадәттә вакыт мәгънәсен белдерүче конструкцияләрдә кулланылучы *-гач/-гәч* формалы хәл фигыль сирәк очракларда шарт мөнәсәбәтен белдерә: *Теләгә**ч** сынасыннар* (Р. Миңнуллин).

Кайвакыт *-п* формалы хәл фигыльле конструкцияләрдә дә шарт мәгънәсе күзәтелә. Мәсәлән: кырг. *Жалгыз уруну**п**, турмушту көңтөрө албайсың* (Мәкаль). Ягъни ялгыз булсаң, тормышны үзгәртә алмыйсың. Әлеге мисалда шулай ук сәбәп-нәтиҗә мәгънәсе дә сизелә: тормышны үзгәртә алмыйсың, чөнки син ялгыз.

Ике күренешнең даими яки периодик рәвештә кабатлана торган бәйләнеше белдерелгәндә, шарт һәм вакыт семантикасының үзара керешүе күзәтелә: ком. *Бир зат этмеге эсине туьш**се**, ол аны гъакъында йолну мастерине барып тилей*; тат. *Матур парлар күр**сәм** – куанам* (Ә. Маликов); *Кит**сә** дә җырлый, кайт**са** да җырлый бу* (С. Сөләйманова).

Шарт конструкциясе компонентлары мөнәсәбәтләренең вакытка карата абстракт характеры, гадәттә, паремияләр һәм гомумиләштерелгән әйтелмәләргә хас. Мәсәлән: алт. *Ат киштезе таныжар, кижи эрмектешсе таныжар* (Мәкаль); карач.-балк. *Джангур джауса джерге джауар* (Мәкаль); кырг. *Жылуу сөйлөсө, жылан ийинден чыгат* (Мәкаль); тат. *Гаилә үзара хөрмәт нигезенә корылса, бәхетле була!* (Ф. Яхин).

Мисаллардан күренгәнчә, паремияләрдә хәзерге яки киләчәк заман формалары кулланыла. Шул ук вакытта фраза үзе вакытка бәйле түгел, гомуми закончалыкка һәм гадәти күренешләргә ишарәли.

Паремияләрдә үткән заман формаларының бик сирәк кулланылуын үткән заманның, кагыйдә буларак, билгеле бер күренешләр, конкрет чынбарлык белән бәйләнгәнлеге белән аңлатырга була. Үткән заман формалары индивидуальләштерү үзенчәлегенә ия, ә паремияләргә гомумиләштерү хас. Шуңа күрә дә паремияләрдә үткән заман формалары еш очрамый. Мәсәлән: ком. *Яшыртгъын айт**дым** – билмединг, гёрюне айт**дым** – сюймединг* (Мәкаль).

Кушма җөмләнең хәбәрләре билгеле бер вакытка мөнәсәбәтсез эш-хәлне яки даими күренешне белдергәндә, вакыт һәм шарт мәгънәләренең синкретиклыгы күзәтелә. Мондый конструкцияләрдә еш кына вакыт белдерүче теркәгечләр кулланыла, иярчен җөмлә гомумиләшкән мәгънәгә ия була. Мәсәлән: гаг. ***Ачан*** *бирлик йок достларда, ишлäр гитмäз хич орада* (Мәкаль).

Шулай итеп, татар һәм башка төрки телләрдә хәл мөнәсәбәтләренең үзара керешү төрләре арасында иң киң таралганы булып сәбәп-нәтиҗә һәм вакыт мәгънәләре синкретиклыгы тора. Максат мөнәсәбәтләре дә, шарт мөнәсәбәтләре дә генетик яктан сәбәп-нәтиҗә категориясе белән бәйләнгән.

Вакыт мөнәсәбәтләре турыдан-туры вакыйгалар эзлеклелегенә бәйле булган сәбәп-нәтиҗә мөнәсәбәтләре өчен фон ролен башкара.

Еш кына формаль яктан аерылмаган сәбәп-нәтиҗә һәм максат мөнәсәбәтләренең төп аерымлыгы – субъектның активлыгы/пассивлыгында. Максат киләчәккә юнәлдерелә, аның тормышка ашырылуы нинди дә булса аңлы, максатчан эшчәнлек таләп итә.

Шарт мөнәсәбәтләре, вакыт мөнәсәбәтләре белән керешеп, шарт һәм вакыт мәгънәләре арасында торучы үзенчәлекле конструкция барлыкка китерә. Мондый төр конструкцияләргә вакыйгаларның бер үк вакытта яки эзлекле башкарылу мәгънәсен төгәл белдермәү хас, чөнки бу очракта төп мәгънәви нагрузка процессларның вакытка мөнәсәбәтенә түгел, ә бер-берсенә бәйлелегенә төшә.

Татар һәм башка төрки телләрдә төрле мәгънә мөнәсәбәтләрен аерудагы кыенлыклар беренче чиратта бер үк формаль күрсәткечләрнең (бәйләүче чараларның) берничә мәгънә белдерүдә кулланылуы белән бәйле.

Мәгънәви бәйләнешләрне чагыштырма планда тикшерүдән күренгәнчә, татар һәм башка төрки телләрдә теге яки бу конструкцияләрне билгеле бер мөнәсәбәтләргә кертеп карарга мөмкинлек бирүче махсус күрсәткечләр һәрвакыт булмый, бер семантикадан икенчесенә күчү процессы еш кына формаль чаралар ярдәмендә структур яктан күрсәтелми, синтаксик берәмлекләрнең структур-семантик төзелешен өйрәнгәндә, форма һәм эчтәлекнең үзара бәйләнешен исәптә тотарга кирәк. Тел материалын анализлаудан күренгәнчә, синкретик мәгънәләр, синтезланган семантика барлыкка килү катлаулы эчтәлекле информация тапшыру ихтыяҗы белән билгеләнә.

**Кыскартылмалар**

әзерб. – әзербайҗан
алт. – алтай

башк. – башкорт
гаг. – гагауз
каз. – казах
карач.-балк. – карачай-балкар
ком. – комык
кырг. – кыргыз
тат. – татар
төрекм. – төрекмән
үзб. – үзбәк

**Әдәбият**

*Бабайцева В. В.* Явления переходности в грамматике русского языка. М.: Дрофа, 2000. 640 с.

*Богуславская О. Ю., Левонтина И. Б.* Смыслы ‘причина’ и ‘цель’ в естественном языке // Вопросы языкознания. 2004. № 2. С. 68–88.

*Дружинина С. И.* Синкретизм в системе сложноподчиненных предложений. Орел: изд-во Орел ГАУ, 2008. 435 с.

Исследования по сравнительной грамматике тюркских языков. Ч. III. Синтаксис / под общ. ред. Н. К. Дмитриева, Н. А. Баскакова, Е. И. Убрятовой. М.: изд-во АН СССР, 1961. 232 с.

*Маслиева О. В.* Становление категории причинности (на материале истории языка) / под ред. М. Г. Макарова. Л.: Наука, 1980. 105 с.

*Радугин А. А.* Философия. М.: Центр, 2004. 336 с.

Типология условных конструкций / отв. ред. В. С. Храковский. СПб.: Наука, 1998. 583 с.

# СМЫСЛОВОЙ СИНКРЕТИЗМ КОНСТРУКЦИЙ, ВЫРАЖАЮЩИХ ОБСТОЯТЕЛЬСТВЕННЫЕ ОТНОШЕНИЯ, В ТАТАРСКОМ И ДРУГИХ ТЮРКСКИХ ЯЗЫКАХ

**Лениза Газинуровна Хабибуллина**,
Институт языка, литературы и искусства им. Г. Ибрагимова Академии наук РТ,
Россия, 420111, г. Казань, ул. Карла Маркса, д. 12,
valievalg@mail.ru.

**Дания Абузаровна Салимова,**
Елабужский институт Казанского федерального университета,
Kurban, R. (2014). *Stalin dəvere həm korbannary* [Stalin Era and Its Victims]. Pp. 90–98. Bez Ideldən, Uraldan . (In Tatar)

Kurban, R. (2014). Tatar ədəbiiatynda tarihi romannar [Historical Novels in Tatar Literature]. Bez Ideldən, Uraldan. Pp. 195–215. Istanbul. (In Tatar)

Kurban, R. (2014). *Tatar ədəbiiatinyң bөek iməne Əmir khan Eniki (1909 - 2000)* [Amir Khan Eniki - the

Great Faith of Tatar Literature (1909–2000)].Bez Ideldən, Uraldan. Pp. 140–151. (In Tatar)

Kurban, R. (2014). *Tatar zyialysy Kaium Nasyiriny iskə alganda* [Tatar Intellectuals in Memory of Kayum Nasyri]. Bez Ideldən, Uraldan. Pp. 34 –54. Istanbul. (In Tatar)

Kurban, R. (2019). *Tatar shigir dənyasynyң armas-talmas kərəshchese Nəҗibə Safina* [Naziba Safina, the Restless Fighter in the World of Poetry]. Өнҗә Ватан. 27 May. Pp. 9–10. (In Tatar)

Kurban, R. (2014). *Tuuynyң 150 elynda Tatars ədəbiiatinyң filosofe shagyire Dərdmənd* [150 Years since the Birth of Derdemend, a Poet-philosopher of Tatar Literature]. Bez Ideldдел, Uraldan. Pp. 65–80. (In Tatar)

Kurban, R. (2019). *Tuuynyң 160 elda Dərdməndneң tormysh iuly həm iҗaty* [Life and Work of Derdemend: On 160 Years of His Birth]. Tөrek dənyasy Tarih, mədəniiat zhurnaly. No. 390, pp. 52–59. (In Tatar)

Kurban, R. (2014). *Ylүeneң 90 elda Dərdmənd* [90 Years of Derdemend's Death]. Bez Ideldən, Uraldan. Pp. 81–90. (In Tatar)

Memish, S. (2012). *Zəlfət shigyr'lərenə analiz (keresh, tekstnyң bibliografik kyrsətkeche)[*The Analysis of the poet Zolfet's poems (Introduction, Text, Concordance)]. Basylyp chykmagan magistrlyk dissertatsiyase, Ege universitety Iҗtimagyy fənnər instituty. İzmir. (In Tatar)

Mirza, M. (2009). *Adəm balasy: shigyrlər. Tatarcha, ruscha, tərekçə, inglizche* [A Human Child: Poems in Tatar, Russian, Turkish, English]. Тәрҗ. C. Zarif I F. Kutlu. 448 p. Kazan, Margarif. (In Tatar)

Muhammedi, R. (1993). *Sirat kypere* [Sirat Bridge]. Sultan Galiev, Тәрҗ. M. Онер. Төркия Бөтендөнья нәшрият фонды. No. 109, Istanbul. (In Tatar)

Muhammedi, R. (1996). *Rossia demokratiiase* [Russian Democracy]. Тəгж. M. Oner. Məstəkyl Basmalar. (In Tatar)

Oner, M. (1990). *Gabdulla Tukai shigyrləre* [Abdullah Tukay's Poems,] Basylyp chykmagan magistrlyk dissertatsiyase. Universitet Dokuz Eylul. Iҗtimagyy fənnər instituty. İzmir. (In Tatar)

Oner, M. (2005). *Tatar ikeyullyklary* [Tatar Couplets]. Kum Saati Basmalara, İstanbul. (In Tatar)

Ozchoban, Yu. (2008). *Ibrahim Səlakhovnaң "Kolyma hikəyaləre" həm "Kykçətau dalalarynda" romanları (keresh - tekst - syzlek həm bibliografik kyrsətmə)* [İbrahim Salahov's novels "Kolyma Stories" and "In the Steppes of Kukchetau" (Introduction-Text-Dictionary and Concordance)]. Basylyp chykmagan magistrlyk dissertatsiyase, İstanbul universitety, Iҗtimagyy fənnər instituty, Balikesir. (In Tatar)

Ozkan, F. (1994). *Gabdulla Tukai shigyrləre, tekstuny analizlau - tərҗemə itү* [Gabdullah Tukay's Poems, Analysis-Text-Translation]. Turkiya mədəniyat fənni-tikshereнү institutes nəshriyat. Ankara. (In Tatar)

Ozmen, O. (2006). *Galimҗan Ibrahimovnyң "Kazakh kyzy" (keresh - textnyң bibliografik kyrsətməse)* [The Vocabulary of the Novel "Kazakh Daughter" by Galimҗan Ibrahimov (Introduction-Text-Concordance)]. Basylyp chykmagan magistrlyk dissertatsiyase, Ege universitety Iҗtimagyy fənnər instituty. Izmir. (In Tatar)

Polat, U. (2011). *Sibgat Khəkim shigyrləre* [Sibgat Hekim's Poems (Introduction-Text-Concordance)]. Basylyp chykmagan magistrlyk dissertatsiyase, Ege universitety Iҗtimagyy fənnər instituty. Izmir. (In Tatar)

Salahov, İ. (2013). *Kolyma khikəyaləre* [Kolyma Prisoners]. Tatar intelligentsiyaseneң sərgendəge istəlekləre. Тəгж. Y. Ozchoban. Kon'ia, Komen nəshriyaty (In Tatar)

Shahin, E. (1999). *Tatar җyrlary җyyentygy (keresh – tekstnyң bibliografik kyrsətkeche)*[A Collection of Tatar Songs (Introduction – Text – Translation - Concordance)].Tərkiya tele assotsiatsiyase nəshriyaty. Ankara. (In Tatar)

Shirin, H. (1998). *Khəsən Tufan shigyrləre, keresh - syzlek* [Hesen Tufan's Poems, IntroductionText-Dictionary]. Basylyp chykmagan magistrlyk dissertatsiyase, Ege universitety Iҗtimagyy fənnər instituty. Izmir. (In Tatar)

*Sessiz Kurai* (2013) [Silent Kuray]. Тəгж. A. Akbash, F. Kutlu. 190 p. Ankara, "Bəngү" nəshr. (In Turkish)

Topchu, H. (2009). *Rezaetdin bin Fəkhretdinneң "Əkhməd Midkhət əfənde" khezmətenə analiz* [The Analysis of Rızaeddin bin Fahreddin's Story "Ahmed Midhat Efendi"]. Basylyp chykmagan magistrlyk dissertatsiyase, Gazi universitety, Iҗtimagyy fənnər instituty. Ankara. (In Tatar)

Tukai, G. (2014). *Kaitu: shigyr'lər* [The Return: Poems]. Tərek telenə tərҗ. B. Orukh Aslan, Y. Ozchoban. No. 117. Kon'ia. (In Tatar)

Tukay, G. (2016). *Şiirler* [Poems]. Тəгж. A. Akbash, F. Kutlu. 224 p. Ankara, "Bəngү" nəshr. (In Turkish).

Turhan, A. (2006). *Tatar – tərek tele. Rəzil Vəliiev – Tragediia* [Tatar as a Turk Language. Rəzil Veliev – Tragedy (Analysis-Text-Dictionary)]. Basylyp chykmagan magistrlyk dissertatsiyase, Firat universitety, Iҗtimagyy fənnər instituty. Elazig. (In Tatar)

*Türk Klasikleri Serisi* [Turkish Classics Series]. Zambak Yayınları, İzmir. (In Turkish)

Uslu, A. (2004). *"Tatar ədəbiatynda zamancha romannar həm əkiiatlər (XIX qasyr ahyry XX gasyr bashi)"* ["Modern Novels and Fairy Tales in Tatar Literature (end of the 19th century - beginning of the 20th century)". Basylyp chykmagan doctorlyk dissertatsiiase. (In Tatar)

*Vasiyet* (2012) [The Will]. Тəгж. F. Kutlu, һ. Ərsoy-Nadir, T. Arslan. 111 p. Istanbul, "Zambak" nəshr. (In Turkish)

Vəliev, R. (2007). *Mavi Hüzün* [Blue Sorrow]. R. Vəliev. Zəңgər sagysh. Tr. by F. Kutlu, һ. Tashkyn. 144 p. Istanbul, "Da" nəshr. (In Turkish)

Zaidulla, R. (2016). *Beyaz Hırkalı İhtiyar* [An Old Man in a White Cardigan]. R.Zaidulla. Ak Yapanchaly kart. Тəгж. F. Kutlu. 111 p. Ankara, "Bəngү" nəshr. (In Turkish)

Zaripova-Çetin, Ç. A. (2016). *İbrahimov'un Eserlerinde Tatar, Başkurt ve Kazak Türklerinin Kültürel Değerleri* [Cultural Values of Tatar, Bashkir and Kazakh Turks in Ibrahimov's Works]. 369 p. Ankara, Bengü Yayınları. (In Turkish)

Zaripova-Çetin, Ç. A. (2017). *İbrahimov'un Kazak Kızı Adlı Romanında Kazak Türklerinin İyiyecek-İçecekleri ve Sofra Adabı* [Good-drinks and Table Manners of Kazakh Turks in Ibrahimov's Novel "The Kazakh Girl"]. Velikaya step'. II. Forum gumanitarnykh nauk. 2 kniga, pp. 235–244. Astana. (In Turkish)

Zaripova-Çetin, Ç. (2016). *Kazan Tatar: Manilerinde Kadınların Talihsiz Kaderi* [Kazan Tatar: The Unfortunate Fate of Women]. Atatürk Üniversitesi Türkiyat Araştırmaları Enstitüsü Dergisi (TAED) Journal of Turkish Research İnstitute. (57), pp. 1619–1636. (In Turkish)

Zaripova-Çetin, Ç. Ö. Beşirov, A. (2011). *Şamov ve M. Mehdiyev'in Eserlerinde Tatar Türklerinin Milli Değerleri* [M. Shamov and National Values of Tatar Turks in Mehdiyev's Works]. VI. Uluslararası Büyük Türk Dili Kurultayı Bildirileri (25–28 Eylül , 2011, Erzurum). Pp. 251–261. Ankara. (In Turkish)

Zaripova-Çetin, Ç. (2008). *Şimalde Şark Gülleri Yetiştiren Şair Redif Gataş* [Redif Gataş, the Poet Who Grew Oriental Roses]. Kardeş Kalemler, Sayı 22, Ekim Pp. 64–72. (In Turkish)

Zaripova-Çetin, Ç. (2009). *Tatar Folklore ve Halk Edebiyatında Kayın Ağacı* [The Beech Tree in Tatar Folk Literature]. Turkish Studies International Periodical for the Languages, Literature and History of Turkish or Turkic. Pp. 583–601. (In Turkish)

Zaripova-Çetin, Ç. (2007). *Tatar Halk Destanı "İdegey" de Geçiş Dönemleri* [Transitional Periods in the Tatar Folk Epic "Idegey"]. Karadeniz Araştırmaları (Balkan, Kafkas, Doğu Avrupa ve Anadolu İncelemeleri) Dergisi. Kara M, N-15, Güz. Pp. 125–149. (In Turkish)

Zaripova-Çetin, Ç. (2011). *Tatar Şairi Abdullah Tukay ın Şiirlerinde Kuran Motifleri* [Quranic Motifs in the Poems of the Tatar Poet Abdullah Tukay]. Kardeş Kalemler, Nisan, No. 52, pp. 40–45. (In Turkish)

Zaripova-Çetin, Ç. (2009). *Tatar Türklerinin Gelenek ve Görenekleri* [Traditions and Customs of Tatar Turks]. 160 p. Ankara, Karadeniz Dergisi Yayınları. (In Turkish)

Zaripova-Çetin Ç. (2019). *Tatar Yazar Fevziye Beyremova'nın Edebi Kişiliği ve "Cengiz Aytmatov'un Tatar Annesi" Adlı Kitabı Üzerine* [On the Literary Personality of Tatar Writer Fevziye Beyremova and Her Book "The Tatar Mother of Genghis Aytmatov"]. Kardeş Kalemler, N- 149 (Mayıs). Pp. 64–72. (In Turkish)

Zaripova-Çetin, Ç. (2009). *Tatar Yazarı Mirgazıyan Yunus'un Seyahatnamelerinde* [Tatar Writer Mirgazıyan Yunus's Travelogues In Istanbul]. I. Uluslar arası Türk Edebiyatında İstanbul Sempozyumu (03-05 Nisan 2008). Bildirileri. Pp. 261–271. İstanbul. (In Turkish)

Zaripova-Çetin, Ç. (2007). *Vatan Özlemi Konulu Tatar Manileri* [Tatars Are Homesick]. ULuslararası Türk Medeniyetinde Sözlü Kültür Geleneği Sempozyum Bildirileri. Maniler. Pp. 212–220. İzmir, Sistem Serigrafi ve Matbaacılık. (In Turkish)

Zaripova-Çetin, Ç. (2017). Vefatının 80. Yılında Saygıyla Anıyoruz: Alimcan İbrahimov (1887–1938) [He died 80 Years Ago. This Year We Respectfully Commemorate: Galimjan Ibrahimov (1887–1938)]. Kardeş Kalemler, Şubat. Pp. 79–86. (In Turkish)

Zaripova-Çetin, Ç. (2018). *Alimcan İbrahimov un Almaçuar Adlı Eserinde Tatarların Milli Bayramı Sabantuy* [Tatars' National Day of Sabantuy in Galimjan Ibrahimov's "Almaçuar"]. Uluslararası Türk Kültürü Sempozyumu ve Karma Türk Sanatları Sergisi. Makedonya-Üsküp. Pp. 58–66. Ankara. (In Turkish)

# ТӨРКИЯДӘ ТАТАР ӘДӘБИЯТЫ: ТАНЫЛУ ЮЛЛАРЫ ҺӘМ ӨЙРӘНЕЛҮ ЮНӘЛЕШЛӘРЕ

**Бирсел Оруҗ Аслан**,
Балыкесир университеты,
Төркия, 10145, Балыкесир ш., Бигадич юлы, 17 нче йорт,
rezeda_raf@mail.ru.

**Резеда Рафаил кызы Хәйретдинова**,
Казан федераль университеты,
Россия, 420008, Казан ш., Кремль ур., 18 нче йорт,
rezeda_raf@mail.ru.

**Йусуф Озчобан**,
Балыкесир университеты,
Төркия, 10145, Балыкесир ш., Бигадич юлы, 17 нче йорт,
rezeda_raf@mail.ru.

**Айсылу Хөсәен кызы Садекова**,
ТР ФАнең Г.Ибраһимов исем. Тел, әдәбият һәм сәнгать институты,
Россия, 420008, Казан ш., К.Маркс урамы, 12 нче йорт,
rezeda_raf@mail.ru.

Мәкаләдә Төркиядә татар әдәбиятын таныту юлларына, аның өйрәнелү юнәлешләре һәм дәрәҗәсенә күзәтү ясала. Гыйльми эзләнүләрнең фәнни проблемаларына, темаларына игътибар ителә. Бу рухи милли хәзинәне кардәш халыклар арасында танытуга һәм пропагандалауга зур өлеш керткән галимнәр, зыялылар катламы кебек мәсьәләләр ачыклана. Төрек әдәбият белемендә татар сүз сәнгатенә багышланган фәнни тикшеренүләрнең сыйфаты һәм саны турында мәгълүматлар да бирелә. Шул ук вакытта киләчәктә бу юнәлештә эзләнүләрнең перспективалары ачыкланып, Төркиядә татар әдәбиятының үсеш юллары билгеләнә.

**Төп төшенчәләр**: татар әдәбияты, Төркия, әдәбият белеме, әдәби бәйләнешләр, тәрҗемә, үсеш.

Татар һәм төрек халыкларының милли бердәйлекләренең төп күрсәткечләреннән берсе булган телләр якынлыгы, рух һәм дин уртаклыгы ике арадагы әдәби һәм мәдәни багланышларның тотрыклылыгын һәм дәвамчанлыгын тәэмин итәләр. Төрле иҗтимагый-социаль һәм мәдәни шартларда яшәүләренә карамастан, бу ике милләт бер-берсенең мәдәнияте һәм сүз сәнгате белән кызыксына, ул гына түгел милли әдәбияттагы идея-эстетик кыйммәтләре белән бер-берсен баета. Ике арадагы тәүге бәйләнешләр 1552 елда Явыз Иван тарафыннан Казан ханлыгы алынганнан соң, Төркиягә качып, аннан кире кайткан халыкка һәм хаҗ кылган татар руханиларына нисбәт ителә [Барган, Гилазов, 2014, с. 73], [Bargan, 2015]. Төрек җәмгыятендә татарча укый-яза белү дәрәҗәсе элек-электән югары була. Урта гасырларда Анадолу һәм Идел-Урал буе халыклары арасында рухи һәм мәдәни бәйләнешләр ныгый төшә. Анадолуда язылган китаплар Идел-Урал төбәгендә яратып укыла һәм, киресенчә, татар китаплары Анадолуда яратып кабул ителә һәм югары бәяләнә. XX гасыр башында Рәсәйдәге инкыйлаб вакытында революцион идеяләргә әверелгән татар зыялыларының бер катлам фәлсәфи һәм иҗтимагый идеяләре Анодолуга үтеп керә.

Шәрык әдәбияты йогынтысында үскән татар сүз сәнгате, төрек әдәбияты кебек үк, XIX гасырның икенче яртысында Гареб мәдәниятенә йөз белән борыла һәм идея эчтәлеге һәм сәнгати эшләнеше ягыннан яңара башлый. Яңа татар прозасы формалашып, романнар һәм хикәяләр язылудан тыш, ирекле формадагы шигърият үрнәкләре дә иҗат ителә. Мәгърифәтчелек чоры татар әдәбиятына төрек әдәбиятының йогынтысы шактый көчле була.

Билгеле булганча, Закир Рәмиев, Фәтих Кәрими, Галиәсгар Камал, Шәриф Камал кебек татар язучылары, татар тормышын яңарту өчен,

төрек мәдәниятендәге һәм әдәбиятындагы казанышларны үзләштерү, дөньяви белемнәр алу максаты белән, Төркиягә киләләр, ягъни аларга төрек әдәбияты белән танышуның киң мөмкинлекләре ачыла. Энциклопедик гыйлемгә ия булган мәгърифәтче галим, әдип, тарихчы, язучы, казый Ризаэтдин Фәхретдин дә төрек әдәбиятын, аның күренекле шәхесләрен, фикер ияләрен җентекләп өйрәнә. Төркиянең мәшһүр әдибе, галим, философ, матбагачы, һәм җәмәгать эшлеклесе Әхмәт Мидхәт Әфәнде үлгәннән соң, аның хакында монографик хезмәт яза [Фәхретдин, 1913].

XIX гасыр ахыры – XX гасыр башларында аеруча көчәеп киткән бу процесс мәгълүм сәбәпләр аркасында совет чорында сүлпәнәеп кала. 1985 еллардагы үзгәртеп кору сәясәте кардәш-тугандаш халыклар арасында әдәби-мәдәни бәйләнешләрнең яңадан торгызылуына һәм ныгуына юллар ача. 1989–1990 елларда төрки халыклар бәйсезлек яулап алалар һәм үз республикаларын төзиләр. Автоном республика булмыйча, Россиянең состав өлешен генә тәшкил иткән Татарстан да Төркия белән мөнәсәбәтләрен яңарта. Ике як та икътисади һәм мәдәни юнәлештәге хезмәттәшлеген тормышка ашыра башлый.

Шул уңайдан Төркиядә татар теле һәм әдәбиятына карата кызыксыну арта һәм бу өлкәдә аерым тикшеренүләргә юл ачыла. Гыйльми эзләнүләрнең зур өлеше тарих һәм язучы иҗаты белән синтезда тикшерелгән тел өлкәсенә карый. Әмма алар кулъязма хокукындагы фәнни эшләр калыбында язылу сәбәпле, киң аудиторияне колачлый алмыйча, гыйльми эшләр үзәгендә яисә университетлар архивында калалар. Шушы шартларны истә тотып, мәкаләдә Төркиядә татар әдәбиятының таралу һәм өйрәнелү дәрәҗәсенә күзәтү ясау һәм аны бәяләү максат ителә, билгеле бер дәрәҗәдә тел белеме өлкәсендәге хезмәтләргә дә игътибар ителә.

XXI гасыр башында төрекләрне татар халкының сүз сәнгате казанышлары белән таныштыру төрле формаларда булып, төрле катлам зыялылар тарафыннан алып барыла. Тәрҗемә башка халыкларның әдәби һәм мәдәни үсеше, рухи дәрәҗәсе белән танышуда, тел-ләгать һәм әхлак алмашуда иң үтемле чараларның берсе булып тора. Ул телләре һәм диннәре уртак булмаган халыклар арасында да эчке һәм тышкы рухи элемтәләр урнаштыруга һәм бәйләнешләрне ныгытуга юллар ача. XX гасыр башында төрки-тугандаш халыклар арасында рухи һәм мәдәни багланышларны көчәйтү мәсьәләсе дәүләт югарылыгында алып барыла башлады. Татар әдәбияты классикларының, хәзерге заман язучыларының әсәрләренең төрекчәгә тәрҗемә ителеп, аерым китап рәвешендә дөнья күрүе шуның ачык чагылышы булып тора. 2005 еллардан башлап татар әдәбияты әсәрләре төрек теленә тәрҗемә ителеп, Төркиядә дөнья күрә башлады. Бу мәсьәлә әдәбият галиме Ф. Сәйфулинаның А. Вәлиева белән берлектә язылган фәнни хезмәтендә бик җентекле тикшерелә [Сәйфулина, Вәлиева, 2017].

Шунысы куанычлы: татар язучыларының дөнья сүз хәзинәсендә урын алырлык әдәби әсәрләренең тирән эчтәлеге, югары сәнгати эшләнеше төрек иҗат әһелләрен битараф калдырмый. Бу рухи байлыкны үз туган халкына җиткерү максаты белән, төрек зыялыларының бер төркеме, татар телен махсус өйрәнеп, милли әдәбиятның матур үрнәкләрен төрек теленә тәрҗемә итү белән шөгыльләнә башлады: мәсәлән, М. Онәр, Ф. Кутлу һ. б.

Төрек Бөтендөнья тикшеренү фонды Р. Мөхәммәдиевнең 1993 елда Мостафа Онер тарафыннан тәрҗемә ителгән «Сират күпере» әсәрен бастырып чыгарды [Мөхәммәдиев, 1993]. Китапта М. Солтангалиевнең тормышы һәм татар халкының бәйсезлеге өчен көрәше сурәтләнә. Моннан тыш М. Онер язучының 1990–1995 елларда парламент язмаларына нигезләнеп язылган «Рус демократиясе» дигән публицистик хезмәтен тәрҗемә итә [Мөхәммәдиев, 1996]. 1996 елда «Ituken publications» нәшрияты ярдәме белән нәшер ителгән китапта Р. Мөхәммәдиев 1989–1995 еллар аралыгында Россиядәге демократияләш-терү процессын тасвирлап бирә.

Төрек укучысын татар әдәбияты белән таныштыруда башта кече эпик жанрларга мөрәҗәгать ителә. Аларны туплаган «Vasiyet» («Васыять») җыентыгы 2005, 2006 һәм 2012 елларда «Замбак» нәшриятында басылды [Vasiyet, 2012]. Китапка тупланган әсәрләрне Фатих Кутлу, Хәмза Эрсой, Надир Тамәр Арсланнар татарчага тәрҗемә итүчеләр булып тора. Җыентыкка татар хикәяләренең иң матур үрнәкләре кертелгән: Ә. Еники («Әйтелмәгән васыять», «Матурлык»), Ш. Камал («Буранда», «Уяну»), Ф. Әмирхан («Бер харәбәдә», «Сәмигулла абзый»), Г. Ибраһимов («Табигать балалары»), М. Әмир («Мөстәкыйм карт йокысы»), Ф. Хөсни («Сөйләнмәгән хикәя»), М. Юныс («Безнең өй өянкеләр астында иде»).

2007 елда Р. Вәлиев әсәрләре, Фатих Кутлу, Харун Тосун тарафыннан татарчалаштырылып, Төркиянең «Da» нәшриятында «Mavi hüzün» («Зәңгәр сагыш») исемендә дөнья күрде [Mavi Hüzün, 2007].

Тәрҗемәчеләр татар әдәбиятының барлык чорларына да мөрәҗәгать итеп, төрек укучыларына милли сүз сәнгатендәге тематик киңлек, жанр төрлелеге һәм әдәби бәйләнеш хакында яңадан-яңа мәгълүмат бирәләр. Ч. Зарипова-Четин Х. Йылмаз белән берлектә, мәсәлән, иҗатында гомумкешелек кыйммәтләрдән тыш иҗтимагый-милли тематика кызыл җеп булып сузылган Г. Исхакый әсәрләрен [Ishaki, 2009], Ф. Кутлу белән хезмәттәшлектә татар шигъриятендә газәл, робагый жанрлары традицияләрен торгызган лирик шагыйрь Р. Гаташ поэзиясен [Гаташ, 2011. Робагыйлар...], [Гаташ, 2011. На вечном пути...] һәм М. Мирза [Мирза, 2009] әсәрләрен төрекчәгә тәрҗемә итә.

Ф. Сәйфулина үз мәкаләсендә, бу юнәлештәге эшчәнлеге югары бәяләнеп, Татарстан Язучылар берлеге әгъзасы буларак кабул ителгән тәрҗемәче һәм филолог Фатих Кутлуга киң туктала: «Ф. Кутлу тәрҗемәсендә „Fildişi Çakı (Tatar çocuk hikayeleri)“ („Балалар өчен язылган татар хикәяләре“) [Fildişi Çakı, 2013], „Sessiz Kuray“ („Тавышсыз курай“) [Sessiz Kuray, 2013] исемле повесть һәм хикәяләр җыентыгы „Бәнгү“ нәшриятында басылып чыкты. Аның тарафыннан Р. Батулла экиятләре [Cengâver Alp’in Kahramanlıkları, 2013], балалар өчен „Altın Sincap“ („Алтын тиен“) [Altın Sincap, 2014] хикәяләр җынтыгы тәрҗемә ителеп төрек укучыларына барып иреште» [Сәйфулина, Вәлиева, 2017; 54 б.]. Соңгысында Н. Думави, А. Алиш, Г. Рәхим, Д. Аппакова, Л. Ихсанова, Ф. Вәлиев, Ф. Әмирхан һ. б. язучыларның әсәрләре урын алган. Аның тырышлыгы белән Р. Зәйдулланың «Ак япанчалы карт» әсәре дә Төркия укучыларына барып ирешә [Зәйдулла, 2016]. Буыннан-буынга күчкән гомумкешелек кыйммәтләрне һәм традицияләрне саклаган татар язучыларының аерым хикәяләре Төркия Мәгариф министрлыгы тарафыннан мәктәп укучылары мәҗбүри укырга тиешле дип расланган йөз китап арасында кертелә. Мәсәлән, Ә. Еникинең «Әйтелмәгән васыять» һәм «Матурлык» хикәяләре шундыйлардан.

Ф. Сәйфулина карашынча, Ф. Кутлуны татар әдәбиятын төрек теленә тәрҗемәче буларак таныткан хезмәтләреннән берсе – Габдулла Тукай шигърияте. Моңа кадәр татар халык шагыйренең бу күләмдә төрек теленә әле тәрҗемә ителгәне булмый. Ф. Кутлу каләмдәше А. Акбаш бәй белән бу җаваплы эшне 10 ай дәвамында башкаралар. Милли шагыйребезнең 130 еллык юбилее уңаеннан 130 әсәре шагыйрь һәм язучы Р.Зәйдулла ярдәме белән сайлана [Сәйфулина, Вәлиева, 2017; 55 б.].

Фатих Кутлу, тәрҗемәчелек эшендә әдәби осталыгы һәм тәҗрибәсе арта барган саен, катлаулырак әсәрләргә алына. Ул Төркиядә Аяз Гыйләҗев иҗатын танытуга да зур өлеш кертә. Тәрҗемәченең язучы белән беренче тапкыр танышуы аның әсәре аша булып, әлеге хакта ул китапның кереш өлешендә бәян итә. Аның тарафыннан А. Гыйләҗевнең «Өч аршын җир» («Bir avuç toprak») [Ğıylecev A. Bir Avuç Toprak, 2008; 2011], «Җомга көн, кич белән...» («Cuma günü, akşam...») [Ğıylecev A. Cuma günü, akşam…, 2013] тәрҗемә ителә.

Мәгълүм булганча, бу әсәрләре А. Гыйләҗевне сәнгать-әдәбият өлкәсендә бик зур дәрәҗәле премия булып саналган «Габдулла Тукай исемендәге премия»гә лаек булган язучы итеп таныта. Аяз Гыйләҗев – үзенең әсәрләре аша бәхетле тормыш тудырырга омтылган, И. В. Сталин чорының идеологиясенә каршы чыкканы өчен җәзага хөкем ителгән олы әдип. Авторның әсәрләрен татарчадан төрек теленә тәрҗемә итеп, Котлу аның изге теләгән гамәлгә ашыра. 2012 елда Котлу Ауразия язучылар берлегендә «Өч аршин җир» өчен «Иң яхшы тәрҗемә ителгән роман» премиясенә лаек була. Шул рәвешле, Аяз Гыйләҗев әсәрләре төрек аудиториясендә дә үз укучысын тапты һәм галимнәр тарафыннан фәнни әйләнешкә кертелде. Әлбәттә, әлеге юнәлештәге хәрәкәтнең башында Ф. Кутлуның тәрҗемә өлкәсендәге уңышлы эшчәнлеге тора. Нәкъ аның тәрҗемәләре аша татар язучысы әсәрләре төрекчә яңгыраш алды. Фатих Котлуның 2013 елда иң соңгы тәрҗемә әсәрләренең берсе – хәзерге татар әдәбияты сайланма әсәрләрен туплаган «Тавышсыз курай» китабы басылып чыга [Sessiz Kuray, 2013].

«Ф. Кутлуның тәрҗемәче буларак игътибарын татар әдәбиятының төрле әдәби-тарихи чорлары кызыксындыра, – дип языла мәкаләдә. – Ул тәрҗемә иткән әсәрләр арасында XX гасыр башы татар поэзиясе һәм прозасы (Г. Тукай, Г. Ибраһимов, Ф. Әмирхан, Ш. Камал), Бөек Ватан сугышы еллары татар прозасы (А. Алиш), XX гасырның икенче яртысы прозасы һәм поэзиясе (Ф. Хөсни,

А. Гыйләҗев, Р. Вәлиев), бүгенге татар әдәбияты (Р. Батулла, Р. Зәйдулла) үрнәкләре дә бар» [Сәйфулина, Вәлиева, 2017; 55 б.].

2014 елның маенда «Кайту» исемендәге Г. Тукай шигырьләре җыентыгы, Бирсел Оруҗ Аслан һәм Йусуф Озчобан тарафыннан тәрҗемә ителеп, «Komen Publications» нәшриятында дөнья күрә [Тукай, 2014]. Тәрҗемәләр Тукайның вафатыннан соң төрле чор әдипләренең шагыйрьгә багышланган әсәрләрен туплаган «Мин Тукайга киләм» китабыннан алынган. Әлеге китапның оригиналь версиясен Гөлзада Бәйрәмова төзи һәм 1996 елда нәшер итә.

Күренекле әдипләрнең һәм шагыйрьләрнең иҗат җимешләрен төрек теленә тәрҗемә итү әдәби җәмәгатьчелекне, китап сөючеләрне татар әдәбияты һәм рухи хәзинәсе белән танытуның бер юлы, беренче баскычы булып тора. Сонгы елларда төрек әдәбияты белемендә татар әдәбиятын өйрәнү юнәлешендә дә җитди адымнар ясалды. Татар әдәбиятын тикшерүгә алынып, җитди казанышларга ирешкән галимнәр катламы кызыклы тәэсир калдыра. Беренчедән шунысы куанычлы: татар әдәбиятының байлыгын тойган төрек галимнәре татар телен махсус өйрәнеп, милли әдәбиятның төрле чорларын һәм әдәби проблемаларын тикшерүгә алыналар.

Төркия Җөмһүрияте Истанбул университеты Гуманитар фәннәр институтындагы төрек теле һәм әдәбияты факультетының әдәбият галиме Хөсәен Барган әлеге юнәлештә уңышлы эшләп килә. Ул Татарстан Республикасына килеп, аның китапханәләрендә, архивларында төрле чыганакларны, әдәби материалларны җентекле өйрәнеп, бай материал туплый. Х.Барган башта татар әдәбиты хакында проблемалы мәкаләләр авторы буларак танылса, яңадан ул монографик хезмәт язуга алына. Галимнең фәнни эзләнүләре нәтиҗәсендә «Җәдит чоры төрек әдәбиятының Идел-Урал өлкәсендәге татар әдәбиятына йогынтысы(1860-1917 еллар)» дип аталган фәнни хезмәте языла [Bargan, 2015]. Галим татар әдәбиятының 1860–1917 елларына мөрәҗәгать итеп, милли сүз сәнгатенең яңарышына китергән социаль һәм мәдәни шартларын барлый. Ике гасыр чигендә рухи һәм иҗтимагый мәдәни бәйләнешләр контекстында төрек мәдәнияте һәм әдәбиятының татар әдәбиятына уңай йогынтысын ассызыклый. Шушы уңайдан татар фәлсәфәчеләре, иҗтимагый фикер иярләре, дини рефрматорлары һәм шулай ук язучылардан һәм шагыйрьләрдән З. Рәмиев, Ф. Кәрими, Ш. Камал, Г. Камал, Г. Тукай шәхесләренә туктала. Аларның тормыш юлларын һәм әдәби дөньяларын яңа мәгълүматлар белән баета.

«Габдулла Тукай шигырьләре (анализ – тәрҗемәләр)» исемендәге китап Фатма Озкан тарафыннан 1994 елда бастырыла [Озкан, 1994]. Бу хезмәт Гази университетының Социаль фәннәр институтында Озканның докторлык диссертациясенә нигезләнеп эшләнә. Диссертация түбәндәге өлешләрдән тора: кереш өлеше, казан төркиләре, Габдулла Тукайның тормышы һәм әдәби әсәрләре. Беренче бүлектә Габдулла Тукай шигырьләренә эчтәлекле тасвирлама ясала, икенчесе шагыйрь поэзиясенә стиль һәм форма ягыннан анализ ясауга багышлана. Тукай һәм аның иҗатына багышланган әлеге хезмәт иң тулы тикшеренүләрнең берсе булып тора. Тукай, фани дөньяда нибары 27 ел яшәвенә карамастан, татар шигъриятенең бөек остасы булып санала. Ул – татар төркиләренең күренекле шагыйре.

«Татар җырлары җыентыгы (кереш – текст – тәрҗемә – күрсәткеч)» дигән хезмәт Эрдал Шаһин тарафыннан 1999 елда басыла [Шаһин, 1999]. Китапның исемендәге фәнни проблемага язылган магистрлык диссертациясе нигезендә барлыкка килгән бу хезмәт 1997 елда Мәрмәрә университетының Төрек тикшеренүләре институтында нәшер итүгә әзерләнә. Төп мәгълүматны үз эченә алган кереш өч өлешкә бүленә. Текстларның тәрҗемәләре тикшеренүнең зур өлешен тәшкил итә. Транскрипцияләре һәм төрек теленә тәрҗемәләре бирелгән озын халык җырлары, кыска халык җырлары, литераль җырлар өч төрле исем астында тәкъдим ителә. Йомгаклау сүзлек белән беррәттән урнаштырыла.

Дөнья сүз сәнгатенең, шул исәптән татар әдәбиятының барлыкка килүендә нигез ролен үтәгән халык авыз иҗаты, аның җәүһәрләре белән төрек укучыларын таныштыру юнәлешендә дә ныклы адымнар ясала. 2005 елда төрекчә грамоталылыкның (укый-яза белүнең. – *асс. авторныкы*) кыпчак төркеме буенча үз хезмәтләре белән танылган Мостафа Онәрнең «Татар икеюллыклары» дигән фәнни хезмәте дөнья күрә [Онер, 2005]. Анда латинчага транскрипция ясалып һәм төрек теленә тәрҗемә ителгән 500 җыр урнаштырылган. Алар фольклорчы Н. Илбарисның «Кыска

җырлар» (дүртьюллы колоритлы халык рифмалары) китабындагы 5630 җыр арасыннан сайлап алынган. Галимнең татар җырлары турындагы әлеге хезмәте бу өлкәдәге иң зур тикшеренүләрнең берсе булып санала. М. Онер хезмәтенең башында кыскача анализ ясалган икеюллык текстларны да урнаштыра. Китап ахырында транскрипция һәм тәрҗемә ясалган җырлар, аерым бүлекчә төсендә сүзлек бирелә.

С. Качалин тәрҗемә иткән казан татарлары җырлары беренче тапкыр 1914–1918 еллардагы сугыш вакытында әсирләрдән ишетелгән була һәм алар Игнаци Кунос тарафыннан язып алына [Казан татарлары куплетлары, 2013]. Бу җыентыкны Жужа Какук бастырып чыгаруга әзерләгән була. Өч телгә, ягъни татар, төрек, венгр телләренә тәрҗемә ителгән икеюллыкларны үз эченә алган әлеге кулъязма 212 биттән тора. Барлык материал 635 шигырьне үз эченә ала һәм язмаларның зур өлеше тикшеренүнең ахырына урнаштырылган.

XX–XXI гасыр чикләрендә мәгълүм сәбәпләр аркасында Төркиягә төрле катлам татар зыялылары күченеп китеп, анда татар диаспорасын барлыкка китерде. Алар арасында татар гыйльми академик мәктәбендә тәрбияләнгән татар әдәбияты, тел белеме һәм тарих галимнәре дә бар. Карс шәһәрендәге Кавказ университетының табигать-гуманитар фәннәре факультеты төрки телләр һәм әдәбиятлары кафедрасы доценты Чулпан Зарипова-Четин гыйльми эшчәнлегенең активлыгы белән аерылып тора. Аның фәнни эшчәнлегендә XX гасыр башы язучылары һәм совет чоры әдипләре өйрәнү объекты булып тора. Шул вакытта галимә игътибарын халык авыз иҗатына, аеруча, милли гореф-гадәтләрне, традицияләрне тикшерүгә игътибарын көчәйтте. «Tatar Türklerinin Gelenek ve Görenekleri» дигән монографик хезмәте төрек укучыларын татар халкының йолалары һәм традицияләре белән таныштыра [Zaripova-Çetin, 2009]. «İbrahimov'un Eserlerinde Tatar, Başkurt ve Kazak Türklerinin Kültürel Değerleri» китабында XX гасыр башының күренекле язучысы Г. Ибраһимов әсәрләрендә татар, башкорт, казахларның рухи кыйммәтләренең чагылышы өйрәнелә [Zaripova-Çetin, 2009].

Ч. Зарипова-Четиннең гыйльми эшчәнлегенең аерым нәтиҗәләре фәнни журнал сәхифәләрендә урын ала. Алар арасында халык авыз сәнгате әсәрләрен [Zaripova-Çetin, 2007], татар халкының гореф-гадәтләрен, этнографик хосусиятләрен яктырткан мәкаләләреннән тыш [Zaripova-Çetin, 2009], «Идегәй» дастанын [Zaripova-Çetin, 2007], шәркый традицияләр ноктасыннан Р. Гаташ шигъриятен [Zaripova-Çetin, 2008], М. Юныс юлъязмаларын [Zaripova-Çetin, 2009] шәрехләгәннәре дә бар.

Мәгълүм булганча, Төркиянең һәр Югары мәктәбе социаль-гуманитар юнәлешләр буенча язылган хезмәтләрне бастыру өчен үз журналын чыгара. «Türklük Bilimi Araştırmaları Dergisi», «Türk Dünyası Dil ve Edebiyat Dergisi», «Kardaş Edebiyatlar Dergisi», «Milli Folklor Dergisi», «Fırat Üniversitesi Sosyal Bilimler Dergisi», «Türkoloji Araştırmaları Dergisi», «Atatürk Üniversitesi Türkiyat Araştırmaları Dergis», «TÜRKSOY Türk Dünyası Kültür, Sanat, Bilim, Haber ve Araştırma Dergisi», «Çukurova Üniversitesi Sosyal Bilimler Enstitüsü Dergisi», «İstanbul Üniversitesi Edebiyat Fakültesi Dergisi» һ.б.лар. Аларда татар теленә, әдәбиятына, фольклорына, тарихына караган күпсанлы теоретик, проблемалы һәм күзәтү мәкаләләре басыла. Р. Яруллина-Йылдырым, Э. Шаһин, А. Камалиева һ.б.ларның хезмәтләре югарыда искә алынган журналларда басылган.

Р. Курбан да фәнни эшчәнлегенең активлыгы һәм нәтиҗәлелеге белән аерылып тора. Аның язмалары тематик яктан татар әдәбиятының төрле әдәби-тарихи чорларының күренекле язучыларын һәм шагыйрьләрен иңли: Каюм Насыйри [Курбан, 2014, Татар зыялысы...], Дәрдемәнд [Курбан, 2014, Тууының 150 елында...], Ә. Еники [Курбан, 2014, Татар әдәбиятының...], Ф. Яруллин [Курбан, 2017], М. Мәһдиев [Курбан, 2015], Н. Сафина [Курбан, 2019] һ.б.лар.

Төркия Җөмһүриятенең университетларында төрек филологиясе, фольклористикасы тармакларыннан галимнәр әзерләү мәсьәләсе бик җитди куелган. Югары мәктәпләрнең чыгарылыш укучылары аны тәмамлаганда, диплом эшләре, магистратураны бетергәндә исә, магистрлык диссертациясен язалар. Гыйльми хезмәтләр үзәгенә тәкъдим ителгән барлык диссертацияләр һәм темалар аның веб-сайтында хронологик тәртиптә бирелә. Фәнни эзләнү эшләренең темалары татар әдәбияты, тел һәм тюркология гыйлемнәренең төрле тармакларына, фольклористикага карый.

М. Онәрнең татар халкының бөек шагыйре Тукай шигъри дөньясын тикшергән «Габдулла Тукай шигырьләре» диссертациясе Докуз Эйлул университетының Гуманитар фәннәр институтында 1990 елда язып тәмамлана [Онәр, 1990] Кызганычка каршы, Диссертацияләр һәм

диплом эшләре үзәге мәгълүматлар базасында әлеге диссертациягә кагылышлы бернинди мәгълүмат та сакланмаган.

Хәтидже Ширин Хәсән Туфанга (Текст – сүзлек) багышланган диссертациясен 1998 елда тәмамлый [Ширин, 1998]. Татар әдәбиятының бөек шагыйрьләреннән берсе булган Х. Туфан үзенең туган иленә багышланган лирик шигырьләрен иҗат итә. Шул әсәрләре аркасында ул, милләтчелектә һәм коммунистик революциягә каршы төркем оештыруда гаепләнеп, үлем җәзасына хөкем ителә, суд карары чыгу белән үк, ул сөргенгә җибәрелә. Ширин үзенең диссертациясен өч өлешкә бүлә. Кереш өлешендә Х. Туфанның тормыш юлы, шагыйрьнең иҗтимагый һәм әдәби түгәрәкләр белән бәйләнеше турында белешмә бирелә, төп игътибарны исә диссертант шагыйрь поэтик теленең үзенчәлегенә юнәлтә. Диссертациянең икенче өлешендә автор Туфанның «Сайланма әсәрләре»нең 1 һәм 2 томлыкларының төрек теленә транскрипциясен бирә. Ахыргы бүлектә тексттан сайлап алынган сүзлек һәм йомгаклау өлеше урын ала.

2000 елда Гөксел Акча тарафыннан «Тылсымлы экиятләр (тылсымлы хәлләр) текстларындагы татар теленең морфологик яктан тасвирламасын бәяләү» дигән темага дүрт бүлектән торган (кереш, анализ, текст һәм тәрҗемә) магистрлык диссертациясе яклана [Акча, 2000]. Әкиятләрнең төрле төрләре турындагы гомуми мәгълүмат кереш өлешендә бәян ителә. Тылсымлы экиятләрнең морфологик тасвирламасы анализ бүлегендә урын ала. Текст бүлегендә мисаллар, ә тәрҗемә бүлегендә аларның төрек теленә тәрҗемәсе бирелә. Тылсымлы экият текстларының унҗиде төрле тибы барлыгы әйтелә һәм татар экиятләре үрнәкләре белән дәлилләнә. Хезмәттәге барлык текстларны төрек теленә Акча шәхсән үзе тәрҗемә иткән.

«Хайваннар турындагы экиятләр текстларында татар авазлары эволюциясе үзенчәлекләре» дигән темага хезмәтне Хури Дурсун 2001 елда яза [Дурсун, 2001]. Әкият текстлары нигезендә татар-төрек авазлары үзенчәлекләрен ачыклау тикшеренүнең төп максаты булып тора. Диссертация дүрт өлештән тора: кереш, анализ, текстлар, тәрҗемә. Кереш өлешеннән соң килә торган анализ бүлегендә авазлар тасвирламасын ачыклау өчен китерелгән мисаллар урын ала, алар борынгы һәм хәзерге төрек телләре белән тәңгәл куеп карала. Төп өлештә 33 экият текстына транскрипция ясала. Тәрҗемә бүлегендә исә әлеге 33 экиятнең төрек теленә тәрҗемәсе бирелә.

2004 елда фәннәр докторы профессор Явуз Акпынар җитәкчелегендә Айшән Услу «Татар әдәбиятында заманча романнар һәм экиятләр (XIX гасыр ахыры – XX гасыр башы)» дигән темага докторлык диссертациясен язып тәмамлый [Услу, 2004]. Анда татар әдәбиятының «алтын чоры» турында мәгълүмат бирелә, бу дәвердә милли сүз сәнгатенең торышы, яңарышның социаль һәм мәдәни шартлары төрки-татар бәйләнешләре контекстында бәян ителә. Әлеге хезмәт бу әсәрләрнең иҗтимагый һәм милли әһәмиятенә басым ясап, аларны укырга теләүчеләрдә кызыксыну уята.

«Шәфкать» романы (транскрипция – тәрҗемә – текст грамматикасы – сүзлек) дигән темага язылган диссертацион тикшеренү эше 2004 елда Гөлсемин Кап тарафыннан языла [Кап, 2004]. Хәзерге татар әдәби теле турында киң мәгълүмат бирә торган әсәрнең авторы – Мәдинә Маликова. Аңлашыла булса кирәк, эчтәлек белән форманың диалектик бәйләнеше төрек галимнәренә романның идеясе, күтәрелгән проблемалар һәм аларның сәнгати хәл ителеше турында да мәгълүмат бирә. Тикшеренү өч өлештән тора: тел үзенчәлекләрен өйрәнү, транскрипция һәм текстның төрек теленә тәрҗемәсе. Диссертация ахырында сүзлек бирелә. Тикшеренү аваз төзелешен һәм морфологик үзенчәлекләрне өйрәнүгә багышлана. Текстның транскрипциясе һәм төрек теленә тәрҗемәсе параллель рәвештә бирелә. Диссертация ахырында кириллицага нигезләнеп язылган төп текст нөсхәсен табарга мөмкин.

2006 елда Сельда Арслан «Рәмзи Вәлиев – трагедия (анализ – текст – сүзлек)» дигән темага диссертация язып тәмамлый [Арслан, 2006]. Төрек теленә тәрҗемә ителгән «Трагедия» романында, татар төрекләре кичергән кыенлыкларга карамастан, аларның милләтпәрвәрләр тарафыннан яклау табулары турында сүз бара. Гомумән алганда, әсәр Казан төрекләренең советлар чорында кичергән рухи фаҗигасен тасвирлый. Романда татар зыялыларының, бигрәк тә дворян гаиләләренең Сталин тарафыннан эзәрлекләнүләргә дучар ителүе күрсәтелә. Хезмәтнең темасы – татар фонетикасы, морфологиясе һәм сүз ясалышы. Диссертация ахырында текст транскрипциясе, шулай ук сүзлек тә бирелгән.

2006 елда Озлем Озмен «Галимҗан Ибраһимовның „Казакъ кызы“ романының лексикасы (кереш – текст – күрсәткеч)» дигән темага диссертация яклый [Озмен, 2006]. Өйрәнү-тикшеренү объекты итеп исеме төрек дөньясы мәгарифе тарихында танылган һәм Идел-Урал төбәгенең билгеле язучысы Галимҗан Ибраһимовның «Казакъ кызы» романы алына. Әдип бөтен төрек дөньясында, иң беренче чиратта, популяр автор буларак билгеле. Тикшеренү предметы булып Галимҗан Ибраһимов романының теле тора. «Казакъ кызы» әсәреннән алынган текстлар гарәп алфавитында язылган. Диссертация дүрт өлештән торып, беренче өлештә XX гасыр башы татар әдәбиятына тарихи һәм мәдәни характеристика, шулай ук авторның тормыш юлы һәм иҗаты турында белешмә бирелә, язучының киңкырлы гыйльми эшчәнлеге белән бәйле хезмәтләре белән танышырга мөмкин. Икенче өлешне романнан алынган татар һәм төрек телләрендәге текстлар тәшкил итә. Өченче өлештә «Каталог» дигән исем астында бирелгән сүзлек, махсус тупланган төп сүзләр һәм еш кулланылган сүзләр исемлеге урын алган. Йомгаклауда тикшеренүдә ирешелгән фәнни казанышларга гомумиләштерүләр һәм нәтиҗәләр ясала.

«Гаяз Исхакыйның „Ике йөз елдан соң инкыйраз“ һәм „Зиндан“ исемле ике әсәренең лексикасы (текст – кереш – күрсәткеч)» (Төркия, 2006) дигән диссертацион эзләнүләрнең авторы – Ариф Гөлсун [Гөлсун, 2006]. Идел-Урал милли-азатлык хәрәкәтенең әйдәп баручысы, журналист һәм язучы Гаяз Исхакый бөтен гомерен татар халкының бәхете өчен көрәшкә багышлый, барлык тормыш авырлыкларын үз җилкәсендә татый һәм үз идеалыннан ваз кичми. Хезмәтнең тикшерү объекты булып торган әсәрләр язучының 1910 елга кадәрге иҗатына карый. Аларның лексикасын ачыклаганда, автор ике повестьның идея эчтәлегенә һәм эчке төзелешенә дә игътибар итә. Диссертация биш өлештән тора. Керештә Гаяз Исхакыйның гомер юлы, тормышыннан алынган аерым вакыйгалар турында сүз бара. Төп өлештә ике повестьның латиницадагы варианты һәм төрек теленә тәрҗемәләре бирелә, аларның язылу тарихлары сөйләнелә. Хезмәтнең алдагы өлешендә әсәрләр лексикасының күрсәткечле сүзлеген табарга мөмкин. Тикшеренүнең белешмә бүлеген Гөлсун дүрт өлешкә бүлеп карый: ялгызлык исемнәр, еш кулланылыштагы сүзләр, цитаталар, өстәмә күрсәткеч. Диссертациянең йомгаклау өлешендә күзәтүләргә нәтиҗәләр ясала.

2006 елда Фатма Эриш Сойтурк «Мәҗит Гафури иҗаты (кереш – текст – күрсәткеч)» дигән темага диссертация яза [Эриш Сойтурк, 2006]. Әлеге хезмәт, 1880 елда Уфа шәһәрендә туып, XX гасырның башында иҗат итә башлаган татар һәм башкорт халкының танылган шагыйрьләреннән берсе Мәҗит Гафурига, аның әдәби шәхесен һәм язу стиле үзенчәлекләрен өйрәнүгә багышлана. Габдулла Тукайның дәвамчысы булган Мәҗит Гафури үзенең күркәм шигырьләрендә татар һәм башкорт әдәбиятының классик һәм халык шигърияте үрнәкләрен тудыра. Тикшеренү 1909–1918 еллар аралыгында гарәп хәрефләре белән язылган Гафуриның 6 шигырьләр җыентыгына нигезләнеп башкарыла. Диссертация дүрт өлештән тора. Кереш өлешендә XX гасыр башы татар әдәбиятының үзенчәлекләре һәм шагыйрьнең бу чорда тоткан урыны турында бәян ителә. Диссертациянең төп өлеше гарәп алфавитында язылган, транскрипцияләре һәм тәрҗемәләре бирелгән һәм төп нөсхәгә туры килә торган (аутентик) шигырь текстларын үз эченә ала. Күрсәткеч өлешендә сүзлек, ялгызлык исемнәр, цитаталар һәм еш кулланылган сүзләр исемлеге тәкъдим ителгән.

Ринат Мөхәммәдиевнең “Кенәри – читлек кошы” романында сыйфатларның һәм фигыльләрнең роле һәм тәрҗемәсе, татар-төрек телен өйрәнүнең үзенчәлекләре” дигән хезмәтне Әйхан Косе 2007 елда яза [Косе, 2007]. Әдәбият белеме һәм тел гыйлеме синтезында эшләнгән эзләнү эшендә романның теле тикшерелә, бигрәк тә сыйфатлар һәм фигыльләрне өйрәнүгә игътибар ителә. Бу тикшеренүдә, күләме зур булу аркасында, моңа кадәр тәрҗемә ителмәгән әсәрнең төрек теленә тәрҗемәсе бирелә. Диссертация ике өлештән тора: беренче өлештә, автор турында белешмә, казан төрки татарларының әдәбияты турында гомуми мәгълүмат урнаштырыла, ә аннан татар тел белеме турында сүз алып барылып, әдәби әсәрнең теле анализлана, андагы сыйфат һәм фигыльләр аерып алынып этрафлы тикшерелә. Әдәби әсәрнең тәрҗемәсе тикшеренүнең икенче өлешендә бирелә. Роман утыз тугыз бүлектән тора. Диссертацион хезмәттә композицион өлешләр аерым урын алып торалар.

2008 елда Ведат Карталҗык «Шәриф Камалның „Акчарлаклар“ һәм „Таң атканда“ әсәрләренең телен тикшерү (кереш – анализ – текст – күрсәткеч)» дигән темага кандидатлык диссертациясен яклый [Карталҗык, 2008]. Керештә XIX–XX йөз чикләре татар әдәбиятының торышына күзәтү ясала, шулай ук монда Шәриф Камалның тормыш һәм иҗат юлына да урын бирелә. Беренче бүлектә тикшеренү объекты булган текстларның төрле үзенчәлекләре тикшерелә, ә икенчесендә әсәрләргә җентекле грамматик анализ ясала. Диссертациянең өченче өлешендә язучы әсәрләренең төрек теленә тәрҗемәсе тәкъдим ителә. Дүрт өлештән торган алдагы бүлектә аерым сүзләр, кулланылган исемнәр, цитаталар исемлеге һәм аеруча еш кулланылган сүзләр күрсәткече белән танышырга мөмкин. Йомгаклауда күзәтүләргә нәтиҗәләр грамматик берәмлекләрнең һәм әсәрләр теленең статистик мәгълүматлары белән баетылып бирелә.

2008 елда Йусуф Озчобан Ибраһим Сәлаховның «Колыма хикәяләре» һәм «Күкчәтау далаларында» (кереш – текст – сүзлек – күрсәткеч) романнарын тикшерүгә багышланган диссертациясен тәмамлый [Озчобан, 2008]. Ибраһим Сәлахов – XX йөздә иҗат иткән күренекле татар язучысы. Ул – Сталин шәхес культы елларында нахакка хөкем ителгән татар зыялыларының берсе. Тикшеренүдә И. Сәлаховны үзенчәлекле язучы буларак таныткан «Күкчәтау далаларында» һәм «Колыма хикәяләре» романнары анализлана. Бу ике әсәрне төрекчәгә тәрҗемә иткәндә, диссертант язучының стилен дә, әсәр телен дә саклап калырга тырышкан. Хезмәт ике романның да җентекле анализын үз эченә ала.

Хәерниса Топчуның магистрлык диссертациясе «Ризаэтдин бин Фәхретдиннең „Әхмәт Мидхәт Әфәнде“ хезмәтен анализлау» дип атала [Топчу, 2009]. Тикшеренү эше кереш, текст һәм анализ өлешләреннән тора. Әсәрнең төрек теленә тәрҗемәсе төп өлештә урын ала. Төркиядә авторның танылмаган булуын искә алып, тикшеренүче аның тормыш сукмаклары һәм әдәби эшчәнлеге турындагы җентекле мәгълүматны аналитик өлештә бирә. Текстларның кыскача йомгагы (резюме) анализ өлешенә кертелгән. Биредә шулай ук әсәрнең теле һәм стиле дә тикшерелә. Хезмәтнең стркутурасын анализ, йомгаклау һәм кулланылган әдәбият исемлеге билгели.

Татар халык авыз иҗаты буенча «Татар әкиятләрен тикшерү» дигән темага Мостафа Гөлтекин тарафыннан тагын бер тикшеренү эше башкарыла [Гөлтекин, 2010]. Хезмәттә татар әкиятләренең форма, төзелеш, эчтәлек һәм вазифа проблемалары өйрәнелә. Беренче бүлектә тикшеренүче татарлар һәм әкиятләр турында гомуми белешмә урнаштырып, татар әкиятләренең төрек дөньясында тоткан урынына басым ясый; диссертациянең икенче өлешендә бу жанрда сурәтләнгән вакыйгалар характеры турында белешмә урнаштырыла; өченче өлештә төзелеш мотивы тикшерелә. Дүртенчесендә татар әкиятләрендә кулланыла торган күренешләр тасвирлана. Йомгак, кулланылган әдәбият һәм алфавит тәртибендә бирелгән күрсәткеч текстларның төрек теленә тәрҗемәсе белән бергә хезмәтнең ахыргы өлешендә урнаштырыла.

2010 елда Өмәр Кучук Мәхмәтоглы Муса Яруллаһ Бигиевнең «Диваны Хафиз» әсәрендәге лексик терминнарны тикшерү” дип исемләнгән тикшеренү эшен төгәлли [Кучук Мәхмәтоглы, 2010]. Гыйльми хезмәттә «Диваны Хафиз» әсәрендә Бигиев тарафыннан кулланылган лексика үзенчәлекләре тикшерү предметын билгели. Күзәтүләр Казан төрки әдәбияты белән Госман төрки әдәбияты арасында охшашлык барлыгын ачык күрсәтә. Шуна күрә Казанда басылып чыккан әлеге әсәр Истанбулда да укылган һәм югары бәягә лаек булган. Диссертациянең кереш өлешендә Муса Яруллаһ һәм аның иҗаты турында гомуми мәгълүмат бирелә. Хезмәтнең беренче өлешендә тексттагы гарәп әлифбасы латиница белән алмаштырыла. Диссертациянең икенче өлешендә татарча язылган текст төрек теленә тәрҗемә ителә. Өченче бүлектә «Диваны Хафиз» китабының лексикасы госман төрек теле лексикасы белән чагыштырма планда карала.

Ширин Аксой – «Татар авторы Гариф Ахуновның „Тормыш юлы“ романының телен тикшерү (кереш – текст – күрсәткеч)» дигән диссертациянең авторы [Аксой, 2011]. Күренекле язучы һәм дәүләт эшлеклесе Гариф Ахунов, халык бәхете өчен хезмәт итеп, укучыларны изге эшләргә рухландыра. Роман үзәгендә сурәтләнгән идеаль ир-ат явызлык һәм гаделсезлек белән көрәшә. Тикшеренү эшен Аксой дүрт төп өлешкә бүлә: кереш, текст, күрсәткеч һәм йомгак. Диссертациядә авторның әдәби шәхес булуына басым ясалып, аның тормыш юлы тасвирлана һәм шушы уңайдан XX гасыр татар әдәбиятына гомуми күзәтү ясала. Алга таба текстның теле тикшерелә.

Әсәрнең транскрипциясе һәм төрек теленә тәрҗемәсе төп өлештә бирелә. Тексттагы һәр сүзне алфавит тәртибендә бирелгән күрсәткечтә табарга мөмкин. Йомгаклау өлешендә роман тел-стиль үзенчәлекләрен күзәтүләргә нәтиҗәләр урнаштырылган.

«Сибгать Хәким шигырьләре (кереш – текст – күрсәткеч)» фәнни-тикшеренү эшен Улку Полат 2011 елда яза [Полат, 2011]. Әлеге зур күләмле хезмәт 1449 биттән тора. Керештә шагыйрь турындагы мәгълүматтан соң, 1905 елдагы хәлләр һәм татар әдәбиятының торышы турында бәян ителә. Алга таба С.Хәким биографиясе һәм ул иҗат иткән чордагы әдәби юнәлеш белән таныштырыла. Шунда ук шигырьләр каталогы һәм исемлеге бирелә. Тикшеренүнең төп өлешендә татарча аутентик, ягъни төп нөсхәгә туры килә торган шигырьләрләрдән алынган мисаллар һәм аларның төрек теленә тәрҗемәсе урнаштырыла. Күрсәткеч өлешендә шигырьләрдә кулланылган сүзләрнең аңлатмасы һәм аларның урнашуы турында җентекле мәгълүмат бирелә. Диссертация йомгак өлеше белән тәмамлана.

«Шагыйрь Зөлфәт шигырьләренә анализ (кереш – текст – күрсәткеч)» хезмәтенең авторы – Сәхәр Мемиш [Мемиш, 2012]. Диссертация биш өлешкә бүленгән: кереш, төп өлеш, глоссарий, йомгак һәм кулланылган әдәбият. Төп өлеш белән үрелеп барган кереш Зөлфәтнең тормышы һәм аның шигъриятенең теле һәм тематикасы турындагы мәгълүматны үз эченә ала. Эзләнү авторы Зөлфәтнең «Ике урман арасы» дигән җыентыгыннан алынган шигырьләрен тәкъдим итә. Диссертация ахырында шигырьләрнең төрек теленә тәрҗемәләре урнаштырылган. Глоссарий шагыйрь поэтик телендәге сүзләрне үз эченә ала.

2013 елда Серафим Каракылыч Агы «Галиәсгар Камалның театр әсәрләрендә тел һәм стиль» темасына докторлык диссертациясе яклый [Каракылыч Агы, 2013]. Әлеге тикшеренү эше татар әдәбиятындагы зур дәрәҗәле драматург, татар театрына нигез салучы Галиәсгар Камалны шәхес буларак ачуны һәм аның әсәрләренең тел һәм стиль тасвирламаларын тикшерүне максат итә. Диссертация кереш, Галиәсгар Камалның тормышы һәм иҗаты, анализ, йомгак, кулланылган әдәбият, сүзлек, текстларны үз эченә алган кушымталардан тора. Кереш өлешендә театр турында гомуми белешмә бирелгәннән соң, автор тәрбияләнгән әдәби һәм мәдәни мохит тасвирлана. Галиәсгар Камалның тормыш һәм иҗат юлы баштагы өлештә бирелә. Диссертациянең икенче өлешендә автор пьесаларындагы тел һәм стиль үзенчәлекләренә анализ ясала: дөрес язылыш үзенчәлекләре, сүзләрне сайлап алу, җөмләләр төзү алымнары өйрәнелә. Югарыда китерелгән һәр бүлекчәдә автор тарафыннан сүзләрнең кулланылыш үзенчәлекләре һәм аерымлыкларына игътибар юнәлтелә. Йомгаклауда текстларны аңлау мөмкинлеген киңәйткән анализ нәтиҗәләре бирелә, шифр белән тамгаланган текстлар һәм аларның тәрҗемәләре төп өлештә урын ала, ә диссертация ахырында сүзлек бар. Төрек теленә тәрҗемә ителгән текстлар Г. Камалның егермеләп драмасыннан алынган.

«Татар авторы Тәлгат Галиуллинның „Тәүбә“ романының телен анализлау (кереш – текст – күрсәткеч)» дигән хезмәт Эрман Әйдоганнар тарафыннан 2013 елда языла [Әйдоганнар, 2013]. Тикшеренү эше татар язучысы һәм публицисты Т. Галиуллинның 1997 елда басылган «Тәүбә» романына нигезләнеп башкарыла. Фәнни эшнең төзелешен кереш, текст (төп өлеш) һәм сүзлек билгели. Кереш Т. Галиуллинны әдәби шәхес буларак ачкан белешмәне, аның тормышы һәм әдәби әсәрләренә кагылышлы гомуми мәгълүматны үз эченә ала. Төп өлештә романның латинчага күчерелгән һәм төрек теленә тәрҗемә ителгән текстлары урнаштырылган. Роман теленең грамматик күрсәткечләре аерым структур катлам буларак тәкъдим ителгән.

Тикшеренүләргә нәтиҗә ясап, шуларны әйтергә мөмкин: көнбатыш әдәбиятларының басымы, таралыш даирәсе көчле булуга карамастан, Төркиядә татар нәфис сәнгате белән кызыксыну арта. Төрек укучыларын, әдәби җәмәгатьчелеген татар әдәбиятының кыйммәтле сәхифәләреннән булган Г. Тукай, Ф. Әмирхан, Г. Ибраһимов, Ш. Камал, Ә. Еники кебек татар классиклары, шулай ук хәзерге чор язучылары Р. Гаташ, Р. Вәлиев, М. Галиев, Г. Гыйльманов, Р. Зәйдулла һәм башкалар иҗаты кызыксындыра. Тәрҗемәләр арасында XX гасыр кешесенең катлаулы рухи дөньясын, милли сыйфатларын, авыл кешесенең бай, кызганыча каршы югалып бара торган рухи һәм мәдәни байлыгын тасвирлаган А. Гыйләҗевнең «Өч аршын җир» («Bir avuç toprak») һәм «Җомга көн, кич белән...» («Cuma günü, akşam...») әсәрләре аеруча үзенчәлекле урын тота.

Төркиядә татар әдәбияты, аның бай тарихы, милли үзенчәлекләре белән таныштыруда, бу кыйммәтле мирасны пропагандалауда төрле катлам әдәбият һәм тел галимнәре, тюркологлар тарафыннан алып барылган тикшеренүләр һәм эзләнүләр дә мөмтаз урын алып тора. Язма әдәбиятның нигезендә яткан татар халык авыз иҗаты, аның жанрлары һәм хосусиятләре белән төрек әдәби җәмәгатьчелеген таныштыру юнәлешендә ныклы адымнар ясала. Бу уңайдан аеруча җырлар, әкиятләр, дастанннар, аларның жанрлар системасын ачыклауга багышланган кызыклы күзәтүләр бар. Шулай ук язучылар тел-стиль үзенчәлекләре өйрәнелгән гыйльми хезмәтләрдә татар әдәбияты, аның аерым әдәби-тарихи чорлары, күренекле әдипләрнең тормыш юлы, иҗат хосусиятләре, образлы-сурәтләү үзенчәлекләре белән таныштырыла.

Киләчәктә Төркиядә Кәрим Тинчурин, Фатих Кәрим, Фатих Әмирхан, Мөхәммәт Мәһдиев, Кави Нәҗми, Саҗидә Сөләйманова кебек XX йөзнең танылган авторларының әсәрләрен, шулай ук дөнья әдәбиятының башка классикларын укуны дәвам итәрләр, бу тармакта гыйльми эзләнүләрнең тематикасы, офыгы киңәер дип ышанасы килә. Һәм алар, үз нәүбәтендә, ике кардәш-тугандаш халыклар арасындагы рухи, әдәби-мәдәни һәм гыйльми бәйләнешне көчәйтүгә хезмәт итәрләр дигән ышанычны ныгыта.

**Әдәбият**

*Аксой Ш.* Татар авторы Гариф Ахуновның «Тормыш юлы» романын анализлау (кереш – текстның библиографик күрсәткече). Басылып чыкмаган магистрлык диссертациясе, Эге университеты, Иҗтимагый фәннәр институты. Измир, 2011. (төрек телендә).

*Акча Г.* Тылсымлы әкиятләр (Тылсымлы хикәяләр) Текстларда татар морфологик характеристикаларны бәяләү. Басылып чыкмаган магистрлык диссертациясе, Гази университеты, Иҗтимагый фәннәр институты. Әнкара, 2000. (төрек телендә).

*Арслан С.* Рәмзи Вәлиев – трагедия (анализ – текст – сүзлек). Басылып чыкмаган татар-төрек диссертациясе, 2006. (төрек телендә).

*Әйдоганнар Э.* Татар авторы Тәлгат Галиуллинның «Тәүбә» романын анализлау (кереш – текстның библиографик күрсәткече). Басылмаган магистрлык диссертациясе, Эге университеты, Иҗтимагый фәннәр институты. Измир, 2013. (төрек телендә).

*Барган Х., Гилазов Т. Ш.* Ахмед Мидхат и тюрки Идель-Урала // TATARICA. 2014. № 1 (2). С. 62–80.

*Батулла Р.* Cengâver Alp'in Kahramanlıkları. Р. Батулла. Алып батыр маҗаралары / тәрҗ. Ф. Кутлу. Анкара: «Бәнгү» нәшр., 2013. 178 б. (төрек телендә).

Gilyazhev, T. Sh. (2017). *Mirkhaidar Faizi dramaturgiiase* [Mirkhaydar Faizi's Dramaturdy]. Pp. 5–48. Kazan, Tatar. kit. nashr. (In Tatar)

Ignatev, R. P. (1868). *Drevnie zdaniia v Trotsom uezde Orenburgskoi gubernii* [Ancient Buildings in the Trotsky District of the Orenburg Province]. Orenburgskie gubernskie vedomosti. No. 21. (In Russian)

Iskandarov, R. Sh. (2009). *Orenburgskie Tatary: istorico-entsiclopedicheskii ocherk* [Orenburg Tatars: A Historical and Encyclopedic Essay]. 271 p. Kazan, Tatar. kn. Izdat. (In Russian)

*Iskəndər həm Bəshir Rəmievlər* (1995) [Iskander and Bashir Ramievs] Төз. M. Rəhimkulova. Orenburg, Iana vakyt. (In Tatar)

Karimev, F. (1928). *Dərdemənd (1859-1921)* [Derdemend (1859–1921)]. Derdmend eserlere. Төз. I. Rəmi. Pp. 8–18. Kazan, Ianalif. (In Tatar)

Khabutdinova, M. M. (2005). *Klad Derdemenda* [Derdemend's Treasure]. Idel. No. 9, pp. 57–59. (In Russian)

Khabutdinova, M. M. (2006). *Tvorchestvo Derdemenda v aspekte dialoga kultur (na primere analiza stikhotvoreniia "Karab" ("The Ship") (1908))* [Derdemend's Works in Terms of a Dialogue among Cultures (based on the analysis of his poem "The Ship" (1908))]. Dialog kultur: russko-tatrskie vzaimosviazi. Materialy istoriko-filologicheskogo seminara Vserossiiskoi nauchno-prakticheskoi konferentsii "Slavianskaia kultura: istiki, traditsii, vzaimodeistvie" 7 Kirrilo-Mefodievskikh chtenii. Vypusk 2. Moskva-Iaroslavl', Remder, pp. 86–92. (In Russian)

Khalit, G. (1986). *Dərdemənd* [Derdemend]. Tatar edebiiaty tarikhy. Alty томda: 20 gasyr bashy. Pp. 194–214. Kazan, Tatar.kit.nashr. (In Tatar)

Khisamov, N. (1989). *Dərdemənd: tormyshy hem izhaty turynda ocherk* [Derdemend: An Essay on His Life and Works]. Kazan utlaty. 312. Pp. 165–175. (In Tatar).

Khamidullin, L. (2009). *Kichke shefek* [Evening Dawn]. Documental povest, esse, ocherklar. 255 p. Kazan, Tatar.kit.nashr. (In Tatar)

*Orenburgskaia guberniia. Spisok naselennykh mest po svedeniyam 1866 goda* (1871) [The Orenburg Province. The List of Settlements According to the Information of 1866]. Sost. i izd. Tsentr. Stat. com. M-va vnutr. del; obrab. V. Zverinskim. St. Petersburg izd-vo tsentr. stat. com. m-va vnutr. del, 108 p. (In Russian)

*Orenburgskii listok*. [The Orenburg Paper]. Orenburg 1887. September 18. (In Russian)

[1] In addition to the works presented in the References, we used the records of the bulletin "Orsk Tatars", published in Orsk in 2009-2013, and Internet articles related to the history of the region.

*Orsk: Fotoalbom* (1995) [Orsk: A Photo Album]. Lit. tekst: V.Lavrik; Fotoil.: V. Tikhomorov, V. Scherbakov; Pod obsch.red. V. Scherbakova. 107 p. , il.; 24 sm. Moscow. (In Russian)

Popov, S. A. *Rukopis* [A Manuscript]. OIKM, inv. No. 29/115a. (In Russian)

Popov, S. A. (1982). *Tainy piatimarov: ocherki po drevnei I srednevekovoi istorii Orenburgskikh stepei* [Secrets of the Pyatimars: Essays on the Ancient and Medieval History of the Orenburg Steppes]. Red. N. T. Struzdyumov, E. V. Novskii. 2 izd., ispr. i dop. 246 p. Cheliabinsk, Yuzh.-Ural. kn. izd-vo. (In Russian)

*Ramievlar* (1995) [The Ramievs]. Toz. M. Rakhimkulova. 96 p. Orenburg, Iana Vakyt. (In Tatar)

*Ramievlar* (1999) [The Ramievs]. Toz. M. Rakhimkulova. Orenburg, Iana Vakyt. (In Tatar)

*Rizaetdin bin Fakhretdin* (1998). 250 p. Orenburg. (In Tatar)

*ORSK // ru.wikipedia.org* 2019–2019. URL: https://ru.wikipedia.org/?oldid=103782319 (accessed: 05.09.2019)

Rychkov, P. I. (2001). *Istoriia Orenburgskaia* [Orenburg History]. Ufa, TsEI UNTs RAN, 201 p. (In Russian)

Rychkov, P. I. (1999). *Topografiia Orenburgskoi gubernii* [The Orenburg Province Topography]. Komm. I. V. Kuchumova, F. A. Dhakurovoi]. 439 p. Ufa. (In Russian)

Saiapova, A. M. (2014). *Derdemend i filosofiia ekzistentsializma* [Derdemend and Existentialism Phylosophy]. TATARICA. No. 2(3), pp. 68–84. (In Russian)

Saiapova, A. M. (1997). *Poezia Dardmenda i simvolizm* [Derdemend's Poetry and Symbolizm]. 210 p. Kazan, Kazanskii ped. un-t. (In Russian)

Shakurov, F. (2002). *Razvitie istoricheskikh znanii u Tatar do Fevralia 1917 goda* [Develpoment of Historical Knowledge in Tatars till February 1917]. 128 p. Kazan, izd-vo Kazan. un-ta. (In Russian)

Smirnov, K. F. (1975). *Sarmaty na Ileke* [The Sarmats on the Ilek]. 176 p. Moscow, Nauka. (In Tatar)

Sobolevskaya, O. V. (2003). *Biografiia* [Biography]. Literaturnaia entsiklopediia termonov i poniatii [gl. red. i sost. A. N. Nikoliukin]. Pp. 90–91. Moscow, NPK "Intelvak". (In Russian)

*Tatary v Orengurgskom krae* (1997) [Tatars in the Orenburg Region]. 228 p. Orenburg, izd-vo "Dimur". (In Russian)

Valetdinov, R. (2010). *Orsk Tatarlary* [Orsk Tatars]. May, No. 5. (In Tatar)

Zagidullina, D. F. (2006). *Donia surate uzgaru: 20 ioz bashy Tatar edebiiatynda felsefi eserlar* [Chaning the Image of World: Philosophic Works in Tatar Literature in the Early 20th Century]. Monografia. 191 p. Kazan, Magarif. (In Tatar)

---

# ЗАТЛЫ ШАГЫЙРЬ ДӘРДЕМӘНД: ОРСК ЧОРЫ ТОРМЫШЫ, ЯҢА ФАКТЛАРҺӘМ УЙЛАНУЛАР (ТУУЫНА 160 ЕЛ ТУЛУ МӨНӘСӘБӘТЕ БЕЛӘН)

**Фәүзия Әүхәди кызы Бәйрәмова,**
Татарстан Язучылар берлеге,
Россия, 420015, Казан ш., Мөштәри ур., 14 нче йорт,
ittifak@yandex.ru.

Мәкаләдә татар халкының күренекле шагыйре, милләтпәрвәр, алтын приискалар хуҗасы Дәрдемәнднең (Закир Рәмиевнең) Орск чоры тормышы өйрәнү объекты булып тора. Татар әдәбият белемендә шагыйрьнең фәнни биографиясе нигездә эшләнсә дә, Ф. Кәрими, Р. Фәхреддин, М. Гайнуллин, М. Рәхимкулова, Л. Хәмидуллин һәм дә Орск төбәген өйрәнүче Т. Г. Черкас хезмәтләренә таянып, Дәрдемәнднең Орск чоры яңа фактлар белән тулыландырыла, аерым мәсьәләләргә карашлар яңартыла. Бу шәһәрдә З. Рәмиевнең үсмер чагы һәм яшьлеге үтеп, аның киңкырлы, затлы шәхес буларак формалашуы ассызыклана. Орск төбәгенең татар галәмендә талантлы һәм оригинал шагыйрь буларак танылу алган һәм Россия алтын чыгару санагатендә мөһим роль уйнаган Дәрдемәнднең мәдәни һәм сәяси тормышына сизелерлек йогынты ясавы күрсәтелә. 1917 елгы Октябрь борылышыннан соң, гомеренең соңгы елларында шагыйрьнең Орск шәһәре белән бәйләнеше ачыла.

**Төп төшенчәләр:** татар поэзиясе, шагыйрь, алтынчы, биография, Орск шәһәре, Дәрдемәнд.

Соңгы елларда әдәбият белемендә иҗат кешесенең дөнья масштабында яки үз халкының мәдәнияте, әдәбияты тарихындагы һәм иҗтимагый-сәяси тормышындагы кыйммәтен билгеләү өчен, биография жанрына еш мөрәҗәгать ителә башлады. Биография «кешенең индивидуаль биографик тәҗрибәсендәге иҗтимагый мәгънәле

эшчәнлегенең тамырларын эзләүгә һәм ачыклауга юнәлгән шәхси тормыш тарихын әдәби яки гыйльми аңлатуны күздә тота» [Соболевская, с. 90]. Дәрдемәнд[1] (Закир Рәмиев, 1859–1921) шигърияте әдәби-эстетик үзенчәлекләре белән генә түгел, ә иҗтимагый хәле белән дә татар тарихында ялгыз урында тора. Иҗатында, татар поэзиясенең күпгасырлык традицияләренә нигезләнеп, аны яңартып кына калмыйча, дөнья масштабына чыгарган шагыйрь рухи мирасының өйрәнелү тарихы гаҗәеп бай. Әдәбиятчы галимнәр Дәрдемәнд шигъриятендә шәрык һәм гареб мәдәниятләренә хас әдәби-эстетик һәм фәлсәфи концепцияләр һәм системалар гәүдәләнешен билгелиләр [Халит, 1986], [Хисамов, 1989], [Заһидуллина, 2006], [Саяпова, 1997], [Хабутдинова, 2005], [Хабутдинова, 2006], [Саяпова, 2014], [Фридерих, 2014], [Гилазов, 2014] һ.б.лар. Татар әдәбият фәнендә Дәрдемәнднең фәнни биографиясе нигездә төзелгән, әмма аның тормыш юлындагы аерым чорларны яңа фактлар белән тулыландыру, моңа кадәр күләгәдә кала килгән вакыйгаларны ачыклау һәм кайбер мәсьәләләр хакында бәя-хөкемнәрне үзгәртү сорала. Мәкаләдә шагыйрьнең Орск чоры тормышы шушы ноктадан тикшерелә.

Дәрдемәнднең бай һәм катлаулы тормышында Орск төбәге аерым урын тота. Бу шәһәр белән шагыйрь гомер юлының төрле баскычлары үзара бәйләнгән. Биредә аның шәхси тормыш фактлары гына түгел, ә татар халкының иҗтимагый үсешен һәм рухи-мәдәни яңарышын тәэмин иткән вакыйгалар бер-берсе белән тоташа. Фәнни хезмәтләрдә Орск чоры аның соңгы еллары һәм үлеме белән генә бәйләнә, ә бит бу шәһәрдә шагыйрьнең үсмерчагы һәм яшьлеге дә үтә! Дәрдемәнднең биографиясе, кызганычка каршы, хронологик тәртиптә, елын-елга салып төзелмәгән, шуңа күрә аның фәнни биографиясен төзү өчен төрле чыганакларга мөрәҗәгать итәргә туры килә. Мәгълүм булганча, Дәрдемәнд 1859 елда Көньяк Уралда урнашкан Җиргән авылында туа, аннан аңа өч яшь вакытта гаиләләре Юлык авылына күченә. Булачак шагыйрь Дәрдемәнд – Мөхәммәдзакир Рәмиев, үзеннән 2 яшькә олы абыйсы Мөхәммәдшакир белән башта Юлык авылы мәдрәсәсендә башлангыч белем ала һәм аннан соң укуларын Орскида дәвам итәләр.

«Алар үскәндә Юлыкта башлангыч (ибтидаи) мәктәп кенә була, – дип яза Л. Хәмидуллин. – Шуннан соң алар ике кыш Орск шәһәрендә укыйлар» [Дәрдмәнд, 2003; 75 б., 94 б.]. Мәкаләдә абыйлы-энеле Рәмиевләрнең Орскида укыган еллары төгәл күрсәтелмәгән, мантыйк буенча, ул 1870 елларның башына туры килә, үсмер малайларга ул чакта 12–13 яшь була. Бу хактагы аерым фактлар Ризаэддин Фәхреддин хезмәтендә ачыклана: «Шакир әфәнде ибтидаи тәхсыйлен (башлангыч белемне. – *Ф. Б.*) Йулык карьясендә (авылында. – *Ф. Б.*) кылып, Орски шәһәрендә дамелла Гариф Мәгази мәдрәсәсендә вә андан соң Сакмар елгасы буендагы Муллакай авылында Габдулла бине Сәед хозурында булган. 1874 елда укудан туктаган» [Фәхреддин, 2010; 422–423 б.]. Димәк, Закир һәм Шакир Рәмиевләр Орскида дамелла Гариф Мәгази мәдрәсәсендә белем алалар.

Оренбург-Орск төбәге татар зыялыларының тормыш сукмакларын, әдәби һәм мәдәни эшчәнлекләрен җентекле тикшереп, аларны яңа фактлар белән баеткан Л. Хәмидуллинның фәнни эшчәнлегендә Рәмиевлар буынының да яңа яклары ачыла. Ул Дәрдемәнднең Орск чоры хакында болай дип яза: «Муллакай мәдрәсәсен тәмамлагач, Рәмиевләр кабат Орскида яши, белем үзләштерүне дәвам иттерәләр. Закир моннан Төркиягә китә һәм ике ел чамасы Истанбулда яшәгәннән соң, 1881 елда шунда әйләнеп кайта» [Дәрдмәнд, 2003; 94 б.]. Тексттан аңлашылганча, Муллакай мәдрәсәсен тәмамлагач та (ул 1874 елда була), абыйлы-энеле Рәмиевләр 1875–1880 елларда Орскида яшәүләрен һәм белем үзләштерүләрен дәвам итәләр. Бу вакытта 16–20 яшьләрдә булган Закирнең үсмер һәм яшьлек чоры Орск шәһәрендә үткән, Истанбул чоры кыска булу сәбәпле, ул шушында шәхес буларак та формалашкан дигән нәтиҗә ясарга мөмкин.

Дәрдемәнд Орскины беренче мәртәбә күргәндә, биредә мәчет һәм мәдрәсәләр була, 2 меңнән артык мөселман яши, шәһәрдә урысларның да чиркәүләре, мәктәп-гимназияләре, почта, хастаханә, судлар, полицияләре эшләп тора, таможнясы, гаскәриләре була. Татар байлары шәһәрдәге төп капиталны үз кулларында тоталар, тирә-яктагы сахра-далаларда алтын табылгач, бу приискаларга хуҗа булып, дөнья белән сәүдә

[1] 1985 елларга кадәр нәшер ителгән хезмәтләрдә *Дәрдмәнд* язылышы фәнни куланылышта була. Соңгы елларда *Дәрдемәнд* варианты файдаланыла башлады. Мәкаләдә үзгәртеп коруларга кадәр чыккан хезмәтләр хакында сүз барганда, алардан алынган цитаталарда *Дәрдмәнд* язылышы сакланды.

итәләр. Безнең карашыбызча, З. Рәмиевнең Төркиягә укырга китүендә дә шушы бай татарларның тәэсире һәм ярдәме булган.

Игътибар итик: 1881 елны Төркиядән кайткач, Дәрдемәнд Юлыкта түгел, ә Орскида яши башлый, ягъни Рәмиевләрнең бу шәһәрдә үз йортлары булган. Ш. Рәмиевнең дә 1900 елга кадәр гаиләсе белән биредә яшәве мәгълүм. Бу факт Р. Фәхреддин язмаларында да, төбәк тарихын өйрәнүчеләр тарафыннан да раслана: «В Орске в конце 19 века проживала семья золотопромышленников Рамиевых – им принадлежали прииски в Орском уезде» [Черкас, 2003]. Л. Хәмидуллин Закирның Орск чоры тормышындагы түбәндәге әһәмиятле вакыйганы искәртә: «Чит илдән кайткач, Закир берникадәр вакыт Орскида яши. Сәүдә эшләре белән шөгыльләнә, җәй айларын, гадәттәгечә, алтын приискалары бистәләрендә уздыра. Төркиядән кайтуының икенче елында ул Орскиның зур сәүдәгәре Мостафа Муса улы Борнаев кызы Мәхүбҗамалга (1861–1943) өйләнә» [Дәрдмәнд, 2003; 95 б.].

Ырынбурның танылган мәгърифәтчесе Мәдинә Рәхимкулова нәшер иткән китапларда Мәхүбҗамалның 1864 елда тууы һәм Татар Каргалысыннан булуы күрсәтелә [Рәмиевләр, 1999; 27 б.]. Дәрдемәнднең балдызы Әсма Рәхмәтуллина-Ибраһимованың истәлекләрендә дә шагыйрьнең өйләнүе языла: «Езни (җизни) Туганым абыстайны 16 яшендә ала. Бик яшьли Туганым абыстайны алып, үзе укыта, тәрбия бирә» [Рәмиевләр, 1999; 180–181 б.].

Дәрдемәнднең кайнатасы Мостафа Борнаев Орскиның иң зур байларыннан исәпләнеп, төбәктә сәүдә эшләрен киң җәелдерә, ярты шәһәр аның туган-тумачаларыннан тора. Ул, әлбәттә, үзенең кызын кулында зур малы, капиталы булган, алтын приискалары хуҗасы Мөхәммәдсадыйк Рәмиевнең улына биргән. Л. Хәмидуллинның язуынча, ул беренче алтын приискасын 1869 елда, аннан соң «көчен дә, малын да жәлләмичә», ел саен берничә алтын «учагы» сатып алган: «Тарихи рәсми язмаларга караганда, М. Рәмиев үз гомерендә егермедән артык приискага ия булган. Алар арасында Хәнифә Дашкова исеменә язылганы да, яшүсмер Шакир белән Закир „хуҗа“ булып исәпләнгәннәре дә байтак. 1869 елда унике яшьлек Шакир, 1871 елда Закир милек хуҗалары булып теркәлгәннәр» [Дәрдмәнд, 2003; 114 б.]. Шулай итеп, 23 яшендә Орскиның иң зур бае Мостафа Борнаев кызына өйләнгәндә, Закир Рәмиев үзе дә «алтынчы кияү» була; аның өстенә Төркиядә укып кайтып, анда төрек-француз телләрен үзләштергән, русчага үзлегеннән дәресләр алган, татарчасы гаять камил булган, гарәпчә һәм фарсычага мәдрәсәдә өйрәнгән затлы егетләрдән санала. Мәгълүматларга караганда, ул Орскидагы яшьлек чорында иҗат белән дә шөгыльләнә башлый. «Төркиядән кайткач, Закир әдәби иҗат эше белән шөгыльләнә, шигырьләр яза, төрек, француз телләреннән хикәяләр, хәтта бер роман да тәрҗемә итеп карый» [Дәрдмәнд, 2003; 106 б.].

Дәрдемәнд һәм аның гаиләсенең 1885 елдан соңгы тормышлары Ырынбурда дәвам итә, әмма ул Орскины да ташлап бетерми, һәр җәйне бу тирәдәге алтын приискаларында эшләп үткәрә, кайнатасы Мостафа Борнаев йортында да еш кунак була. XX гасыр башын Закир Рәмиев-Дәрдемәнд Ырынбурда каршылый, ул анда «Вакыт» газетасына (1906) һәм «Шура» журналына (1908) нигез сала, аларны үз акчасына нәшер итә, Ризаэддин Фәхреддинне Уфадан чакыртып китереп, шушы юнәлештә бергәләп эшли башлыйлар. Дәрдемәнд белән Р. Фәхреддиннең бу чордагы уртак эшчәнлеге милләтебезгә бәяләп бетергесез бай рухи мирас калдыра...

Шунысы гаҗәп: бу чорда Ырынбур гына түгел, Орск та милли һәм дини яктан зур күтәрелеш кичерә. 1907 елның 12 июлендә биредә бишенче мәчет ачыла, 1908 елда шәһәрдә тарихта беренче тапкыр мөселман китапханәсе үзенең ишекләрен ача. «В 1914 году в Орском уезде насчитывались 178 мусульманских школ при 213 учителях» [Черкас, 2003]. Орск төбәгендә генә дә, Ырынбурны һәм ул тирәләрдәге татар авылларын кертмичә, татарларның ике йөзгә якын мәктәп-мәдрәсәләре һәм ике йөздән артык мөгаллимнәре булган.

1911 елда Орскида татар үзешчән театры барлыкка килә, монда Мирхәйдәр Фәйзинең дә зур өлеше барлыгын әйтеп үтәргә кирәк. Дәрдемәндтән 30 яшькә яшьрәк драматургның гомере һәм иҗаты Орск төбәге белән бәйле. Ул биредән ерак булмаган Күкшел авылында 1891 елда туа, 1902–1904 елларда Орскида мәдрәсәдә укый, аннан белемен Ырынбурның «Хөсәения» мәдрәсәсендә дәвам итә, ләкин авыру сәбәпле аны тәмамлый алмый [Гыйлаҗев, 2017; 6 б.]. 1909 елда ул «Ике Хәсән» дип аталган беренче пьесасын яза, аны Орскида татар үзешчәннәре белән сәхнәдә уйныйлар. Шуннан соң М. Фәйзи бер-бер

артлы Ырынбур һәм Казан матбагасы битләрендә дөнья күргән драма әсәрләре, шигырьләр, хикәяләр яза башлый. Язучының 1912–1913 елларда хәтта ике җыентыгы да басылып чыга.

Билгеле булганча, М. Фәйзинең әтисе Мостафа Ырынбур байлары Хөсәеновларның Күкшел авылындагы утарларында идарәче була, шул ук вакытта аларның Орскида да үз өйләре булганлыгы билгеле. «Многие орчане знают имя Мирхайдара Файзи (1891–1928 г.г.). Он родился и вырос в многодетной семье мещанина Файзуллина Мустафы, дом которого находился на ул. Пугачева, 60. Юный Мирхайдар не только писал стихи, рассказы, пьесы, но и ставил спектакли созданной им татарской любительской труппой в 1909–1917 гг.» [Черкас, 2003].

М. Фәйзи бу төбәктә үзенең үлемсез әсәрләрен – «Галиябану» (1916), «Асылъяр» (1920), «Ак калфак» (1922) драмаларын яза. Дәрдемәнд шигърияте һәм Мирхәйдәр Фәйзи драматургиясе бары тик шушы моңлы һәм шанлы кыпчак далаларында, мәгърур Урал тауларында, серле Җаек һәм Сакмар су буйларында гына туа ала. Безнең карашыбызча, үзеннән күпкә яшь булса да, Дәрдемәнд драматургның үзен дә, иҗатын да белгән, хәерхак та булган.

1917 елның 27 декабрендә Ырынбурның «Нур» театрында куелганнан соң, «Галиябану» Орскиның «Дом общественного собрания» сәхнәсендә уйнала. Шунысын да әйтергә кирәк: шәһәрнең бу үзешчән татар театрыннан талантлы артистлар үсеп чыга. «В 1909–1917 гг. участниками упомянутой труппы были Исмагил Музафаров, Гариф Галиакберов, Х. Губайдуллин, Абдулла Амиров, Хабибулла Садыйков, Баттал Шагидуллин, Гибадулла Хасанов, Файзуллин Мирхайдар (Файзи), Камил Салимзянов и другие» [Черкас, 2003]. Ә Орскиның танылган бае Нигъмәтҗан Нигъмәтуллиннар гаиләсендә 1907 елда булачак зур артистка, Марсель Сәлимҗановның әнисе Галия Нигъмәтуллина туа. М. Сәлимҗановның әтисе, ТАССРның халык артисты Хәким Сәлимҗанов та 1903 елны Орскида туа, соңыннан М. Сәлимҗанов театр коллективы белән Орскига килеп, әти-әнисенең туган-торган нигезләрен күреп китә. Танылган композитор, скрипкачы Заһид Хәбибуллин да 1910 елда Орскида туган.

1917 елгы Октябрь борылышы милли зыялылар тормышына, шул исәптән Дәрдемәндкә дә зур йогынты ясый. 1918 елда шагыйрь, эре «алтынчы» Ырынбурдан Орскига күчә. Аңа бу адымны ясарга нәрсә мәҗбүр иткән? 1921 елда Дәрдемәнд Орскида нидән үлгән – ачлыктанмы, тифтәнме? Бу сорауларга җавап эзләгәндә, кулыбызда, гомумән, матбугатта моңа кагылышлы материалның бик аз булуын әйтеп үтәргә кирәк. Билгеле булганча, Ырынбурга Совет власте 1918 елның гыйнварында гына килеп җитә, ә аңа кадәр Зәки Вәлиди биредә «мөстәкыйль Башкорт мохтарияте» игълан итеп өлгергән була. Ырынбур төбәгенә казахлар да (ул вакытта кыргызлар дип аталган) дәгъва кыла һәм үз автономияләрен төзи, ә чынлыкта шәһәр белән атаман Дутов һәм аның казаклары идарә итә. Большевиклар хакимияткә килү белән, «Вакыт» газетасын һәм «Шура» журналын яптыралар, Дәрдемәнд аларның биналарын совет вәкилләренә үз куллары белән тапшырырга мәҗбүр була. Нәшриятсыз, газета-журналсыз калган, большевикларның асылларын тиз аңлап алган Дәрдемәнд һәм Риза Фәхреддин, 1918 елның февралендә берсе – Орскига, икенчесе – Уфага күчеп китәләр, бу вакытлыча китүләре мәңгелеккә була. Дәрдемәнднең моннан ун ел элек, 1908 елның башында язылып, «ил, халык, дәүләт язмышына иҗтимагый авырлыклар тәэсир итү фикере алгы урынга чыккан» [Заһидуллина, 2006; 70 б.] шигырь юллары кышкы дала буйлап аларны озата бара...

| | |
|---|---|
| Шаулый диңгез...<br>Җил өрәдер...<br>Җилкәнен киргән<br>кораб!<br>Төн вә көндез<br>Ул йөрәдер:<br>Юл бара ят ил карап... | Чыкты җилләр,<br>Купты тулкын –<br>Ил корабын җил сөрә<br>Кайсы юллар,<br>Нинди упкын<br>Тарта безне җан<br>сорап?!.<br>[Дәрдмәнд, 2003; 25 б.] |

Шагыйрь җаны әүлиядәй сизгер, ул ил өстенә килгән бу афәтнең әле озак, бик озак дәвам итәсен белә. Кара болыт булып милләт өстенә ябырылган бу фаҗигане туктата алмасын да сизә ул... Ул үз дөньясына китә, кызыл кан булып илне басып барган кызыл террордан качып, вакытлыча булса да, далаларына-тауларына китә. Бу чордагы хәлләрне өйрәнгәннән соң, миндә, «Дәрдемәнд, Ырынбурдан большевиклар диктатурасы белән ризалашмыйча, шуңа эчке нәфрәт һәм протест йөзеннән киткән икән» дигән фикер туды. Ул чорда, Ырынбурда байларга карата рәхимсез

террор сәясәте алып барылып, аларны судсызнисез юк иткәннәр.

1956–60 елларда Орскида яшәгән һәм эшләгән, аннан соң да бередә берничә тапкыр булган, Дәрдемәнд турында хезмәтләр язып, китаплар чыгарган язучы Л. Хәмидуллин шагыйрьнең Ырынбурдан китүендә башкарак сәбәпләр дә күрә. «Балалар язмышыннан кала приискалардагы хәл-әхвәлләр дә борчый Закир Рәмиевне. Бу буталчык заманда анда ни хәлләр икән? Прииск җиһазларын ватып, җимереп бетермәгәннәрме? Алтын бөртекләре сакланган таш келәтләр ышанычлы куллардамы? ... Орскига китешли шушы уйлар да борчыгандыр Дәрдмәндне. Шуңа күрә дә инде, гадәттәгечә юл төшүен көтмичә, Орскига кышын китәргә булганнардыр. Орск – приискалардагы хуҗалыкларны берләштереп торучы үзәк. Җай чыкса, аннан приискаларга да барып килергә мөмкин булачак. Бәлки шул тирәдә сугышып йөргән балаларның да хәлен белеп булыр. Рәмиевләр эш йөрткән Орск банкалары ни хәлдә икән?» [Хәмидуллин, 2009; б. 75–76]. Дәрдемәнднең Орскига китүенә болар да сәбәпче булырга мөмкин, чөнки зур хуҗалыкны, дала буйлап сибелгән дистәләгән алтын базларын, алтын сакланган келәтләрне алай гына ташлап калдырып булмый.

Төбәк тарихын өйрәнүчеләр язганча, Дәрдемәндләр гаиләсе Орскида төрле урыннарда – хатынының туганнарында да, арендалаган аерым йортта да яши, шәһәр өчен аклар һәм кызыллар арасында каты сугышлар барганда, авылларга, утарларына да китеп торалар. Гомумән, Дәрдемәнд гомеренең бу соңгы чоры тыныч булмый: шушы 3–4 елга революцияләр дә, гражданнар сугышы да, ачлыгы да туры килә, моның өстенә, буй җиткән балаларының тифтән үлүләре дә килеп өстәлә.

Дәрдемәнд күңеленә тынычлык эзләп, гаиләсен ил өстенә килгән афәтләрдән саклап калу теләге белән Орскига кайтса да, ул иминлекне бередә дә таба алмый. Җәйгә таба бередә шәһәр өчен каты сугышлар башланып, ул айлар буе камалышта кала, әле аклар, әле кызыллар кулына күчә: бер ел эчендә дүрт тапкыр хакимият алышына. «В 1918–1919 годах, в период гражданской войны, город выдержал трёхмесячную осаду, затем четырежды захватывался воюющими сторонами» [Орск]. Дәрдемәнднең гаиләсенә дә кайгы артыннан кайгы килә. Балдызы Әсма Рәхмәтуллина-Ибраһимованың хатирәләреннән күренгәнчә, шагыйрьнең Морад исемле улын аклар мобилизовать итеп сугышка алалар, ә Җәгъфәрне – кызыллар. Бу сугышларда Морад тифтән үлә, Җәгъфәр бер кулсыз кала. 1919 елның көзендә олы уллары Искәндәрнең авырлы хатыны Шәрифзадә тифтән үлә, бер яшьлек оныклары Бәшир Дәрдемәндләр кулында кала. (Соңыннан бу ятим бала – Бәшир Рәмиев дөньякүләм танылган галим, СССРда беренче ЭВМ-комьютерларны уйлап табучы, техник фәннәр докторы, Дәүләт премиясе лауреаты исеменә ия була).

Үзе дә ул елларда Орскида яшәгән Әсма Рәхмәтуллина-Ибраһимованың истәлекләреннән күренгәнчә, шәһәргә кызыллар керә башлагач, Ырынбур һәм Орск байлары акларга ияреп кача башлыйлар. Димәк, Ырынбурдан Орскига бер Дәрдемәнд гаиләсе генә түгел, башка байлар да кызыллардан качып килгән, кызыллар Орскига килеп җиткәч, күпчелек татар байлары, акларга ияреп, бу шәһәрдән дә качкан. Ә Дәрдемәнд калган... «Илен яраткан, милләте белән калган» кебек олы төшенчәләрне бераз читкәрәк куеп, тормышның ачы чынбарлыгына да игътибар итик. Мондый шартларда, Дәрдемәнд кебек алтмышка җиткән олы яшьтәге ир-ат, калган бөтен балалары һәм оныклары аңа карап торган зур гаилә башлыгы, нечкә күңелле шагыйрь, моңа кадәр җәмгыятьтә зур хөрмәткә һәм дәрәҗәгә ия булган шәхес нишләргә тиеш иде соң? Балаларын, ятим онукларын төяп, дутовчыларга һәм Колчак гаскәренә ияреп, урыс арбасына утырып, дөнья буйлап сукбайлыкка чыгып китәргәме? Анда аны һәм гаиләсен, нәселен нәрсә көтә?

Дәрдемәнд бу сорауларга нәкъ шул канлы, болганчык елларда язган шигыре белән үзе җавап бирә:

Куанды ил, канат какты мәләкләр,
Шашып, аң-таң булып шайтан төкерде!..
Җитәр, җилкенмә, йолкынма, күңел, син,
Кияү булсаң да, ул туйга түгел син!
Җиһан тормыш туен иткән чагында,
Синең урның – үлекләр аймагында

[Дәрдмәнд, 2003; 219 б.].

Дәрдемәнд турындагы гыйльмияттә шагыйрьнең бу чор иҗатыннан берничә шигыре генә билгеле. Ә. Рәхмәтуллина-Ибраһимова шагыйрьнең басылмыйча калган язмаларын Җәгъфәр хатынының вокзалда чемоданы белән бергә урлатуын яза. Күңеле төшенке, тормышы кайгылы, киләчәге шомлы булса да, Дәрдемәнд шушы шартларда да

җәмгыятьтә үз урынын табарга омтылып карый. Л. Хәмидуллин мәгълүматларына караганда, бу вакытта ул Казанда булып китә: «Орскида яшәү дәверендә бер мәртәбә Казанда булганлыгы да мәгълүм. 1919 елның гыйнварында татар язуын камилләштерүгә багышланган конференция оештырыла. Унынчы елларда ук имля алыштыруга карата үз фикерен матбугатта белдергән Дәрдмәнд тә аңа чакырылган була» [Дәрдмәнд, 2003; 217 б.].

Бу елларда Орск шәһәре туктаусыз сугышлардан, тифтән, соңрак инде ачлыктан газап чиксә дә, тормыш барыбер дәвам итә. 1918 елның башында ук биредә мөселман Шурасы төзелә, 1919 елны икенче мөселман китапханәсе ачыла, татар клубы эшли башлый, әлеге вакыйгаларда Дәрдемәнднең дә катнашы булган, дип уйлыйсы килә. Шәһәрне кызыллар алгач, большевиклар татарларны, милли зыялыларны төрле оештыру эшләренә тарталар, аларның кайберләрен җаваплы урыннарга да сайлап куялар. «На I Орском уездном съезде Советов 28 июня 1918 г. был избран Уисполком, в состав которого вошли татары Мусин Мухаметсафа Сафич, Даутов Абдулла Мухаметзянович, секретарем был избран башкирин Татлыбаев Зариф. Проводилась работа среди женщин-мусульманок: первое общее собрание с ними было проведено 27 сентября 1919 г. Организатором среди женщин-татарок была избрана Забирова Фатима. Продовольственный отдел города с октября 1919 г. возглавлял А. М. Даутов При Орском РКП (б) в 1920 г. была создана мусульманская секция, потом подотдел нацмен, просуществовавший до 1927 г. Первым председателем ее избран Амиров» [Черкас, 2010, с. 196].

Болар арасында Дәрдемәнд юк. Рухы белән дә, тәрбиясе белән дә бөтенләй башка халәттә булган Дәрдемәнд большевик татарлар арасына барып керә алмый. Алай да, аның нацменнар комиссары Абдулла Дәүләтшин белән аралашканлыгы билгеле, чөнки бу егет Орскида «Шәрыкъ клубы» бинасында татарча газета чыгара башлый.

«Дәрдмәнд ара-тирә шул бинага килеп, төбәктәге милли азчылык арасында эшләргә тиешле яшь комиссар Абдулла Дәүләтшин белән дә аралашкалый, – дип яза Л. Хәмидуллин. – Дәүләтшин Орскида 1920 елдан беренче милли газета – „Ирек йолдызы“н чыгара башлый. Атна саен нәшер ителгән ике битле бу газетада әдәбият-сәнгать почмагы: шигырь, әдәби парча, мәдәният яңалыклары урнаштырыла. Комиссар бүлмәсендә үзәктән алынган газеталар белән дә танышып була» [Дәрдмәнд, 2003: 218 б.].

Тарихи чыганаклардан күренгәнчә, «Ирек йолдызы» газетасы Орск шәһәрендә 1919–1921 елларда чыга, аның берничә саны гына кайбер китапханәләрдә сакланып калган: Казанда Татарстан Республикасының Тарихи-сәяси документлар үзәк дәүләт архивында – 1921 елның 12нче саны; Мәскәүдә Россия Федерациясенең Дәүләт китапханәсендә – 1921 елның 11нче саны; Петербургта Россия Федерациясенең Милли китапханәсендә – 1921 елның 11нче саны [Гайнанов, Мәрданов, Шәкүров, 1999; б. 71–72]. Л. Хәмидуллин «Ирек йолдызы» газетасының бер саны Орск музеенда саклануын хәбәр итә. Әлеге матбугат битләрендә Дәрдемәнд турында хәбәр, я булмаса шигырьләренең басылып чыгуы хакында, кызганычка каршы, мәгълүматлар юк. Димәк, киләчәктә бу юнәлештә дә эзләнүләрне активлаштырасы бар.

Шулай итеп, Дәрдемәнд Орскида өч елдан артык яши, тормыш алып барырга ярдәмгә улы Искәндәр дә кайта, чит илләрдә укыган бу әзерлекле белгеч советлар өчен дә бик кирәкле кеше була, аңа алтын табу приискаларына эш тәкъдим ителә. (Әмма соңыннан аны «халык дошманы» дип кулга алалар һәм ул сөргендә үлә). Бәлки шушы чордадыр, Рәмиевләр үзләренең бөтен алтын запасларын (ә алар тонналап була) советларга тапшыралар; тарихчылар «үз теләкләре белән» дигән фикердә тора. Минем карашымча, анда теләкне сорап тормаганнар, күпчелек байларны, йортларыннан өстерәп чыгарып, терәп атканны, алтынны тартып алалар да алалар. Дәрдемәнд яңадан Ырынбурга кайтырга ашыкмый, югыйсә, 1920–1925 елларда биредә казах автономиясенең башкаласы була, казахлар исә байларга алай ук каныкмыйлар. Бу вакытта әле Рәмиевләрнең Ырынбурдагы йорт-җирләренә дә кагылучы булмый. Гомеренең соңгы елларында Дәрдемәнд Орскида кала, биредә яши, биредә үлә, биредә күмелә... Димәк, тәкъдирендә шулай язылган була...

Л. Хәмидуллин Дәрдемәнднең ачлык вакытында халыкка ярдәм итүе турында хәбәрләр ишетүен дә әйтә: «Мәсәлән, 1960–70 елларда Орск шәһәрендә очрашулар вакытында берничә кеше, шул исәптән 1920 елларда шунда „Кулланучылар җәмгыяте“ндә эшләгән Габдулла Дәүләтшин дигән бер ветеран-коммунист Дәрдмәнднең 1921 елда шушы төбәктә ачлыкка

каршы чаралар күрү комиссиясендәме, хәйрия оешмасындамы үз теләге белән эшләвен сөйләделәр. Мондый хәбәрнераслардай рәсми документ әле табылмаган» [Бертуган Рәмиевләр, 2002; 36 б.]. Бу факт дөреслеккә туры килергә дә мөмкин, чөнки Дәрдемәнд халыкның фаҗигасенә читтән карап тора торган шәхес түгел, аягында йөргәндә, сүзе үткәндә, ул ачлык афәтенә каршы да көрәшеп карагандыр, әмма адәм баласы гына җиңәрлек фаҗига булмаган шул ул... Ачлык Орскины да кырып сала, кешеләр берәмләп түгел, меңәрләп үләләр. «Новым испытанием стал голод 1921–1922 годов. В 1920 г. население города составляло более 16 тысяч человек, а к 1923 году оно сократилось до десяти с половиной тысяч» [Орск. Фотоальбом. С. 22.]. Һәм шушы меңнәр арасында милләтнең бердәнбере, татар шагыйре Дәрдемәнд – алтынчы Закир Рәмиев тә була...

Дәрдемәнднең үлем сәбәпләренә һәм вакытына карата төрле фикерләр яши. Рәсми чыганаклардан күренгәнчә, 1921 елның көзендә шагыйрь Ырынбурга авыру кызының хәлен белергә бара. Аны күмеп, Орскига кайтканда, юлда бик туңа һәм тиз арада үлә. «Олы кайгы кичерү, озын юлның мәшәкате, көзге суык аны тәмам хәлсез итәләр, – дип яза Л. Хәмидуллин. – Кайтып, бер атна чамасы авырып яткач, 1921 елның 9 октябрендә Закир Рәмиев-Дәрдмәнд вафат була. Шәһәр янәшәсендәге Ильяс авылы зиратына җирләнә» [Дәрдмәнд, 2003; 218 б.].

Чыганактагы фактлар барысы да диярлек дөрес, әмма «бер атна чамасы авырып яткач» дигән сүзләр күңелдә шик уята. Шикләнү өчен сәбәп тә бар, чөнки Дәрдемәнднең балдызы Ә. Рәхмәтуллина-Ибраһимова Гөлсемнең, ягъни, шагыйрьнең олы кызы Өммегөлсемнең Ырынбурда яз көне үлүен хәбәр итә: «Оренбургта Гөлсем апалар ачыгып кыш чыгалар, яз җиткәч, Гариф езни базардан, белмим, бозлы карбызмы алып кайта. Гөлсем апа ач килеш ашый, эче үтеп, холера микән, үлеп китә» [Рәмиевләр, 1999; 185 б.].

Бу хатирәдә безнең өчен Өммегөлсемнең Ырынбурда яз көне үлүе хакында мөһим яңа факт бар: Дәрдемәнд анда яз көне барган булып чыга. Ә. Рәхмәтуллина-Ибраһимовага ышанмаска безнең хакыбыз юк, чөнки аңа бу вакытта 16 яшь булып, ул барысын да яхшы хәтерли. Шулай ук Өммегөлсемнәрнең Ырынбурда ачлы-туклы яшәгәннәре ачыклана. Дәрдемәнд, аларга үз авызыннан өзеп бераз булса да, азык илтә бара. Истәлекләрдә Орскида Дәрдемәндләрнең боткага калулары хакында да языла, ягъни, элеккеге мул тормыш та юк, хезмәтчеләр дә юк, ашарга да үзләре пешергән боткадан кала берни юк. Әлбәттә, ботка булу ул әле ачлык түгел, әмма өйдә барлык ризык запасларының беткәнлеген күрсәтә.

Шулай итеп, Дәрдемәнд Ырынбурга олы кызы янына 1921 елның язында барып, аннан ятим оныкларын алып, юлда авырып кайткан булса, ул әле үлеменә кадәр ярты ел буе урын өстендә яткан, дигән сүз. З. Рәмиев авырып ятканда, аның янына Р. Фәхреддиннең килеп киткәнлеге билгеле. Бу очрашуның, бигрәк тә Уфада яшәүче Риза хәзрәт өчен бер атна эчендә булуы мөмкин түгел. Дәрдемәнд белән соңгы очрашуы турында Р.Фәхреддин болай дип яза: “Оренбургдан Уфага сәфәремдә янына кереп видаг иттем (саубуллаштым. – *Ф. Б.*). Авыру вә түшәк өстендә иде. “Хәлем яхшыланадыр” дигәненә һәм дә үзенең беркадәр сөйләшәсе килүне белүемә күрә, янында беркадәр утырдым. Шул вакыт: “Хәзрәт! Бу көнге хәлләр беркадәр төзәлсә, без “Вакыт” берлә “Шура”ны тәкрар чыгарырмыз, шул вакытта Оренбургка кайтып, әүвәлге хезмәтләреңездә дәвам итүеңезне өмидләнәмез вә үтенәмез, сезнең берлә берлектә Хиҗаз (Хаҗ кылу күздә тотыла. – *Ф. Б.*) сәфәренә бару фикеремдә камил, моны үзеңез берлә сөйләшкән дә идек”, – диде. “Аллаһ нәсыйб итсә, безнең тарафымыздан эш калмас”, – дип видаг кылып чыгып киттем. Ахыргы күрешүем шушы булды [Фәхреддин, 2010; 354 б.)].

Бу очрашу кайчан, кайда булган – безгә төгәл билгеле түгел, әмма мантыйк буенча, бу Дәрдемәнд үлем түшәгендә ятканда булган хәл, дип фаразларга була. Билгеле булганча, 1918 елның февраль азагында Ырынбурдан берсе – Уфага, берсе – Орскига киткәндә, шагыйрь үлем түшәгендә ятмый, аннан соң да әле өч елдан артык яши. Димәк, бу соңгы очрашу 1921 елда булган, әмма ае һәм көне билгесез. Бу – ике бөек шәхеснең, милләтнең ике газиз улының соңгы очрашуы, бәхилләшүе булган. Дәрдемәнд гомеренең сонгы мизгелләрендә дә милли матбага турында кайгырткан, «Вакыт» газетасы белән «Шура» журналын яңадан чыгару турында хыялланган. Ризаэддин хәзрәт белән берлектә Хаҗ кылырга ниятләгән, әңгәмәдән күренгәнчә, бу турыда алар элегрәк тә сөйләшкән булалар. Димәк, моңа хәтле Дәрдемәнд тә, Ризаэддин Фәхреддин хәзрәтләре дә Хаҗ кылмаган булалар? Һәрхәлдә, андый мәгълүмат табылмады.

Л. Хәмидуллинның «Дәрдмәнд олы кызы янына Ырынбурга көзен барган» дигән сүзләренраслый торган башка дәлил бар. З. Рәмиевне бик якыннан белгән, «Вакыт» газетасында баш мөхәррир булып эшләгән Фатыйх Кәрими 1927 елда аның үлеме турында болай дип яза: «1921 елның октябрь аенда Оренбургтан кайткан вакытта тимер юлда суык тигереп, 9 октябрьдә Орски шәһәрендә вафат булган һәм шунда дәфен ителгән. Үлгәндә яше 62 дә булган» [Кәрими, 1928; 17 б.].

Зәки Вәлидинең дә Орскига авыру Дәрдемәнднең хәлен белергә килүе мәгълүм: ул шулай ук шагыйрьнең үзе турында түгел, ә милләте хакында кайгыртуына игътибар биргән. З. Вәлидинең Дәрдемәнд белән соңгы очрашуының кайчан, кайсы айда булуын белү мәсьәләгә бераз ачыклык кертер иде.

Татар шагыйре Дәрдемәнд вафатының төп сәбәбе аеруча зур сораулар уята: ул ачтан үлгәнме, әллә тифтәнме? Гадәттә, бу ике афәт, бер-берсенә тагылып, янәшә йөриләр. Ә. Рәхмәтулллина-Ибраһимова истәлекләреннән күренгәнчә, Орскида бу нәселдә ачтан үлүчеләр булмаган, булса – язар иде. Аның үзенең 18 яшьлек Сара апасы 1921 елда тифтән үлә: «Езни күмәргә акчалар әниемә бирә, өч куй да китерә». «Үлем хәсрәтеннән айный алмый торганда тагын да хәсрәт килә: езни иң олы кызы Гөлсем апаның хәлен белергә, азыклар илтергә Оренбургка бара» [Рәмиевләр, 1999; 185 б.], – дип дәвам итә Әсма Рәхмәтуллина-Ибраһимова.

Дәрдемәнднең Ырынбурга азыклар илтү факты гаиләнең бу вакытта әле ачлык газапларына дучар ителмәве хакында сөйли. Әмма ачлык бу нәселгә көзен ишек шакырга мөмкин. Өммегөлсемнең вафат булу көнен ачыклау бу сорауга бераз төгәллек кертер иде. «Аннан кайткан вакытта поездлар ягылмаган булганга езни бик өшеп кайта, – дип яза хатирәләр авторы. – Бронхит белән авырып, терелә алмый үлеп китә. Врач, йөрәге бик начар, ди...» [Рәмиевләр, 1999; 185 б.]. Әйе, йөрәк авыруы да булырга, бронхиттан үпкә чиренә әйләнергә дә мөмкин. Тиф белән ачлык та үз корбаннарын чүпләп торган.

Шагыйранә тәхәллүсе-псевдонимы сагышлы-моңлы булган Дәрдемәнд, гүя алда тагы да шомлырак, куркынычрак заманнар киләсен сизенеп, бу гаделсез дөньяны ташлап китә. Үз җирендә, үз гаиләсендә, иң якыннары арасында тынычлап җан бирә, мөселманча җеназа намазы укылып, җиргә тапшырыла. Дөрес, ул күмелгән татар зираты өстенә сугыш елларында хәрби завод китереп салалар, аның кабере өстендә ракеталар җитештерә башлыйлар, әмма шагыйрь җаны инде күптән бу тар каберне ташлап, Аллаһ хозурына очкан була... Татар халкының затлы шагыйре Дәрдемәнднең милләткә, мәңгелек васыяте булып, үләр алдыннан язган шигырь юллары кала: «Кала торган нәрсә – биредә туган һәм яши торган кешеләр, алар ата-бабаларының дан шөһрәтләрен истә тоталар, шуларны буыннан-буынга тапшырып киләләр. Бу шигырендә Дәрдемәнд үзе һәм „халкына“ булган мөнәсәбәте турында сөйли» [Фридерих, 2014; 99 б.].

| | |
|---|---|
| Гөрләгән сулар башында,<br>Тыңлагыз, шунда үтәр –<br>Йөрсә сыктап таң-сәхәрләр<br>Моң-сагышлардан хыял.<br>И туган илнең һавасы,<br>Рәнҗемим, зинһар күтәр!<br>Рәнҗемим, зинһар күтәр! | Ни газизрәк – бу ватанмы?<br>Аһ, туган каүмем газиз!<br>Ул мөкаддәс кан белән ул<br>Изге сөткә ни җитәр!..<br>Сөт калыр, ватан китәр!<br>Сөт калыр, ватан китәр!<br>[Дәрдмәнд, 2003; 61 б.] |

Димәк, татар халкының иҗтимагый-рухи күтәрелешенә, милли сүз сәнгатенең яңарышына зур өлеш керткән олы фикер иясе, абруйлы җәмәгать эшлеклесе Дәрдемәнднең фәнни биографиясендә Орск төбәге мәгълүм урын алып тора. Бу шәһәрдә шагыйрь тормышына һәм язмышына сизелерлек йогынты ясаган вакыйгалар була. Ул, биредә шәхес буларак формалашып, үсеш кичерә, гаилә корып җибәрә, Россиянең алтын санагатендә эре алтынчы булып җитешә, милләтпәрвәр, милләт хадиме төсендә үзен реальләштерә. Алга таба төбәкнең мәдәни һәм сәяси тормышында актив катнашып, татар милләтенең алгарыш һәм үсеш кыйбласын билгели. 1917 елдан соң дөньялар үзгәреп китеп, авыр һәм болгавыр заманнар башлангач, Орск аңа, гаиләсенә сыену почмагы була. Дәрдемәнднең фани дөньяда соңгы сәгатьләре биредә үтеп, ул мәңгелеккә – теге дөньяга күчә.

**Әдәбият**[2]

*Әбелгазый Баһадир хан*. Шәҗәрәи төрек. Казан: Татар.кит.нәшр., 2007. 134 б.

*Батталов Г. А.* Казан төркиләре. Тарихи язмалар / тәрҗ. А. Рәхимова; нәшр. ред. Л Хәмидуллин. Казан: Татар. кит. нәшр., 1996. 192 б.

*Бертуган Рәмиевләр*: Фәнни-биографик җыентык. Казан: Рухият, 2002. 368 б.

*Валетдинов Р.* Татары в Орске // Орск татарлары. 2010. Май. № 5.

*Гайнанов Р. Р., Мәрданов Р. Ф., Шәкүров Ф. Н.* Татар вакытлы матбугаты (1905–1924). Казан, 1999.

*Гыйлаҗев Т. Ш.* Мирхәйдәр Фәйзи драматургиясе // Фәйзи М. М. Пьесалар / төз., кереш мәкалә һәм иск. авт. Т. Ш. Гыйлаҗев. Казан: Татар. кит. нәшр., 2017. Б. 5–48.

*Даутов Р. Н., Нуруллина Н. Б.* Дәрдемәнд // Совет Татарстаны язучылары: Биобиблиографик белешмә. Казан: Татар. кит. нәшр., 1986. Б. 165–166.

Дәрдмәнд / кереш сүз авт. Л. Хәмидуллин; төз., фоторәсемнәр һәм макет авт. З. Бәширов. Казан: Татар. кит. нәшр., 2003. 239 б.

*Дәрдмәнд.* Исә җилләр: Шигырьләр. Истәлек-парчалар. Вак хикәяләр / төз. һәм иск. язучы Р. Даутов. Казан: Татар. кит. нәшр, 1980. 254 б.

*Заһидуллина Д. Ф.* Дөнья сурәте үзгәрү: XX йөз башы татар әдәбиятында фәлсәфи әсәрләр: Монография. Казан: Мәгариф, 2006. 191 б.

Искәндәр һәм Бәшир Рәмиевләр / төз. М. Рәхимкулова. Оренбург: Яңа вакыт, 1995.

*Кәримев Ф.* Дәрдмәнд (1859–1921) // Дәрдмәнд әсәрләре / Төз. И. Рәми. Казан: Яңалиф, 1928. Б. 8–18.

Рәмиевләр / төз. М. Рәхимкулова. Ырынбур: Яңа Вакыт, 1995. 96 б.

Рәмиевләр / төз. һәм нәшир М. Рәхимкулова. Оренбург: Яңа Вакыт, 1999.

*Халит Г.* Дәрдемәнд // Татар әдәбияты тарихы. Алты томда: XX гасыр башы. Казан: Татар. кит. нәшр., 1986. Б. 194–214.

*Хисамов Н.* Дәрдемәнд: тормышы һәм иҗаты турында очерк // Казан утлары. 1989. 312. Б. 165–175.

*Хәмидуллин Л.* Кичке шәфәкъ: документаль повесть, эссе, очерклар. Казан: Татар. кит. нәшр., 2009. 255 б.

*Гилазов Т. Ш.* Поэзия Дердеменда в контексте Запада и Востока // Вестник ЧелГУ. Филология. Искусствоведение. 2014. № 10 (399). С. 46–51.

*Фридерих М.* Дөнья әдәбияты контекстында Дәрдемәнд иҗаты // TATARICA. 2014. № 2 (3). С. 85–105.

*Фәхреддин Р.* Асар. Беренче том. Казан: Рухият, 2006. 359 б.

*Фәхреддин* Р. Асар. Икенче том. Казан: Рухият, 2009. 303 б.

*Фәхреддин Р.* Асар. Өченче һәм дүртенче томнар. Казан: Рухият, 2010. 646 б.

*Игнатьев Р. П.* Древние здания в Троцком уезде Оренбургской губернии // Оренбургские губернские ведомости. 1868. № 21.

*Искандаров Р. Ш.* Оренбургские татары: историко–энциклопедический очерк. Казань: Татар. кн. изд-во, 2009. 271 с.

Оренбургская губерния. Список населенных мест по сведениям 1866 года / сост. и изд. Центр. стат. ком. М-ва внутр. дел; обраб. В. Зверинским. С.Пб: Изд-во Центр. стат. ком. Мин. внутр. дел, 1871, 108 с.

Оренбургский листок. Оренбург 1887. 18 сентября.

Орск // Википедия. 2019–2019. URL: https://ru.wikipedia.org/?oldid=103782319 (дата обращения: 05.09.2019).

Орск: Фотоальбом / Лит. текст: В.Лаврик; Фото, ил.: В. Тихомиров, В. Щербаков; Под. общ. ред. В. Щербакова. Москва, 1995. 107 с.; ил.; 24 см.

*Попов С. А.* Рукопись. ОИКМ, инв. № 29/115а.

*Попов С. А.* Тайны пятимаров**:** очерки по древней и средневековой истории Оренбургских степей / ред. Н. Т. Струздюмов, Е. В. Новский. 2-е изд., испр. и доп. Челябинск: Юж.-Урал. кн. изд-во, 1982. 246 с.

Ризаэтдин бин Фәхретдин. Оренбург, 1998. 250 б.

*Рычков П. И.* История Оренбургская. Уфа: ЦЭИ УНЦ РАН, 2001. 201 с.

*Рычков П. И.* Топография Оренбургской губернии / коммент. И. В. Кучумова, Ф. А. Шакуровой. Уфа, 1999. 439 с.

*Саяпова А. М.* Поэзия Дардменда и символизм. Казань: Казанский пед. ун-т, 1997. 210 с.

*Саяпова А. М.* Дэрдеменд и философия экзистенциализма // TATARICA. 2014. № 2 (3). С. 68–84.

*Смирнов К. Ф.* Сарматы на Илеке Сарматы на Илеке. Москва: Наука, 1975. 176 с.

*Соболевская О. В.* Биография // Литертаурная энциклопедия терминов и понятий / гл. ред. и сост. А. Н. Николюкин. Москва НПК «Интелвак», 2003. С. 90–91.

Татары в Оренбургском крае. Оренбург: изд-во «Димур», 1997. 228 с.

*Хабутдинова М. М.* Клад Дэрдменда // Идел. 2005. № 9. С. 57–59.

*Хабутдинова М. М.* Творчество Дэрдменда в аспекте диалога культур (на примере анализа стихотворения «Кораб» («Корабль») (1908)) // Диалог культур: русско-татарские взаимосвязи // Материалы историко-филологического семинара Всероссийской научно-практической конференции «Славянская культура: истоки, традиции, взаимодействие» 7 Кирилло-Мефодиевских чтений. Выпуск 2. Москва-Ярославль: Ремдер, 2006. С. 86–92.

[2] «Әдәбият» исемлегендә күрсәтелгән хезмәтләрдән тыш шулай ук Орск шәһәрендә 2009–2013 елларда басылып чыккан «Орск татарлары» бюллетене язмалары, интернетта бу төбәк тарихы белән бәйле мәкаләләр файдаланылды.

*Черкас Т. Г.* Хронограф города. Орск: Орский историко-краеведческий музей, 2005. 67 с.

*Черкас Т. Г.* Мусульмане Орска в XIX – начале XX века // Орские известия (вкладыш «Туган тел»). 2003. 28 января.

*Черкас Т. Г.* Орск: от крепости до города: монография / Т.Г. Черкас. Орск: ОГТИ, 2010. 263 с.

*Шакуров Ф.* Развитие исторических знаний у татар до февраля 1917 года. Казань: изд-во Казан. ун-та, 2002. 128 с.

---

# ВЕЛИКИЙ ДЭРДМЕНД: НОВЫЕ ФАКТЫ ПО ОРСКОМУ ПЕРИОДУ ЖИЗНИ ПОЭТА (К 160-ЛЕТИЮ СО ДНЯ РОЖДЕНИЯ)

**Фаузия Авхадиевна Байрамова,**
Союз писателей Республики Татарстана,
Россия, 420015, г. Казань, ул. Муштари, д. 14,
ittifak@yandex.ru.

Объектом изучения выступает Орский период жизни известного татарского поэта, национального деятеля, золотопромышленника Дэрдменда (Закира Рамиева). Научная биография писателя основательно изучена Ф. Карими, Р. Фахретдином, М. Гайнуллиным, М. Рахимкуловой, Л. Хамидуллиным, краеведом из г. Орска Т. Г. Черкас. В статье вводятся в оборот новые факты, рассматриваются в новом ракурсе ранее изученные проблемы. В этом городе прошли детство и юность З. Рамиева. В работе выявлена роль Орска в формировании личности писателя. Доказано, что социальная и культурная жизнь города оказала благотворное влияние на формирование его как писателя, золотопромышленника, общественного деятеля, известного как в татарском мире, так и в России. Раскрыты обстоятельства жизни писателя после Октябрьской революции 1917 г., связь с г. Орском в последние годы жизни.

**Ключевые слова:** татарская поэзия, поэт, золотопромышленник, биография, г. Орск, Дэрдменд.

History and society
Тарих һәм җәмгыять
История и общество

DOI: 10.26907/2311-2042-2019-13-2-70-88

# ESTABLISHING THE NETWORK OF RUSSIAN-TATAR SPECIALIZED SCHOOLS IN THE LATE 19$^{TH}$ – EARLY 20$^{TH}$ CENTURIES: THE SARATOV PROVINCE

**Frid Ainievich Rashitov**,
Sh. Marjani Institute of History, Tatarstan Academy of Sciences (Saratov branch),
75 Moskovskaya Str., Saratov, 410042, Russian Federation,
rashfa@mail.ru.

**Rezeda Ilgizovna Ishmukhamedova**,
State Archive of the Saratov Region,
15 Kutyakova Str., Saratov, 410012, Russian Federation,
reseda-@mail.ru.

Based on a large array of documents and materials first introduced into academic circulation, the article considers the emergence and distribution of Russian-Tatar specialized schools in the Saratov province at the beginning of the 20$^{th}$ century. Stipulated by the governmental “Rules on Measures for Educating Foreigners Inhabiting Russia” (1870), Russian-Tatar specialized schools, having undergone a number of changes in the early 20$^{th}$ century, became a real alternative to traditional Muslim mektebs.

The Tatar community of the Saratov province was involved in this process with some delay. Moreover, the World War, which began in 1914, strongly interfered with the implementation of these plans. Nevertheless, the accumulated experience significantly influenced the formation of the state school system after 1917.

**Key words**: Russian-Tatar specialized schools, mekteb, the Saratov province, zemstvo, revolution, general education.

The theme of Russian-Tatar specialized schools is one of the understudied areas in historiography. In the Soviet era, this was obviously due to the general negative attitude to the tsarism policy in the sphere of education and enlightenment of Russian foreigners. In the post-Soviet period, the researchers were mainly focused on the problems of modernization of the Tatar traditional school system.

Only recently Russian-Tatar specialized schools have become an object of increasing attention [Azamatova], [Gainetdinova], [Kamalieva], [N. Naganava]. The researchers consider the latter as an important link in the process of moderniza-

tion of the Tatar school system at the turn of the 19th–20th centuries.

Despite its time-limited parameters, the historical experience of Russian-Tatar specialized school functioning is of current importance. This experience was widely used during the formation of a new Soviet system of Tatar school education after the formation of TASSR in 1920. It can be useful in modern conditions, when the Tatar society strains its forces in the struggle for the preservation of the native language and ethno-cultural identity. This may include cooperation between Tatar communities and local self-government bodies in opening and organizing Tatar cultural and educational centres, Sunday schools, etc.

It should be recognized that there are still many ambiguities and unresolved questions in the study of the topic. This is largely due to the limited amount of specific historical material related to individual regions. In a number of the regions densely inhabited by Tatars the factual background of the issue remains unclear: opening dates of specialized schools, teaching staff, etc. This can be also applied to the Saratov province, which, in 1897, numbered almost 95 thousand people of Tatar nationality [Pervaia Vseobshchaia perepis naseleniia]. At the same time, the absolute majority of Tatars, up to 95 percent, lived in 63 villages located in four counties: Volsk, Kuznetsk, Petrovsk, and Khvalynsk [Rashitov, p. 16]

The issues, concerning the relationships between confessional Tatar schools and Russian-Tatar specialized schools and the place of the latter in the system of Tatar education, require careful study.

With all this in mind, we have decided to turn to the topic of the emergence and spread of Russian-Tatar specialized schools in the Saratov province. The aim of our study is to identify the scale of the spread and influence of Russian-Tatar specialized schools in the Saratov region in the context of the modern school system among Russian Tatars. We are to find out when, in which localities, on whose initiative Russian-Tatar specialized schools were opened, who were the teachers, how they changed the attitude of Tatar population to these educational institutions.

In our research, we relied on the works on historical and pedagogical issues both by the researchers of the Soviet period [Gorokhov], [Makhmutova], [Khanbikov], [Efirov] and our contemporaries [Amirkhanov], [Zagidullin], [Farkhshatov]. This problem is widely reflected in the seven-volume academic work “History of Tatars since Ancient Times” [Tom VI: Formirovanie tatarskoi natsii. XIX – nachalo XXv. Kazan, 2013. – 1172 p.] [Tom VII: Tatary i Tatarstan v XX – early XXI v. Kazan, 2013. – 1008 p.]. Unfortunately, in the 7th volume of this work, the author of the paragraph “The State of National Education among Tatars”, R. Mukhametshin, completely bypasses the topic of Russian-Tatar specialized schools [Istoria, T. 7, pp. 149–158].

The theoretical foundation of our research is mainly the documents kept in the funds of the state archive of the Saratov region, as well as the collections of reference and statistical data published in different years.

In the first decade of the 20th century, the main institute of literacy for Tatar children of the Saratov province was the school – the mekteb at the Muslim mosque. In 1901, 112 mektebs and madrassas operated in the province, in 1909, their number reached 124. They trained 5962 people and 6410 respectively [Obzor nachalnogo obrazovaniia v Saratovskoi gubernii za 1900-1901 uchebnyi god; Materialy o sostoianii narodnogo obrazovaniia v Saratovskoi gubernii za 1910–1911 gg.]

As we can see, the system of Muslim education in the studied period was in a state of stagnation. The number of specialized schools and their students increased only by 10 percent over 8 years. School enrolment did not exceed 5-6 per cent of the Tatar population of the province. To fully cover the number of children aged 8–14 at least 15 per cent should be reached.

In the subsection "Nouns" from the second chapter, G. Burbiel describes in detail the features of nouns, their endings, the parts of speech used to create new nouns, singular and plural noun forms, cases, declension and the way they affect each other. The author points to the absence of the category of gender in the Tatar language, but indicates what gender can be assigned to a person, based on the semantics of some words, for example, 'әби' (grandmother), 'бабай' (grandfather), 'хуҗабикә' (housewife), 'ханбикә' (wife of the khan), etc. This subsection provides a comprehensive table of noun declension with corresponding examples from the English language.

When analyzing adjectives alongside the explanations of adjectival formative endings, declension of adjectives and degrees of comparison, the author describes the conversion of nouns to adjectives and vice versa; he also notes the adjectives denoting colors. In the English language, such adjectives as *English*, *Russian* are used both in relation to the nation and to the language. In this connection, G. Burbiel shows how these words function in the Tatar language. In Tatar, unlike English, the names of languages and nationalities are written with a lowercase letter.

In the subsection of numerals, besides indicating the function of numerals, the author notes that such words as 'күп' (many, much), 'аз' (little, few) denote number, or quantity. Therefore, the concept of volume is included.

Pronouns are fully presented by the author, who gives a detailed description of their types.

It is not surprising that the largest part of this work is devoted to verbs. G. Burbiel describes such characteristics of verbs as aspect, person, gender or number, mood, voice, forms. It is commonly known that English has many tenses. Tatars, as well as English people, perceive time with all the delicacy. It can be demonstrated by analyzing the aspect forms of the verbs (for example, 'килә' (comes), 'килгәли' (sometimes comes), 'килештергәли' (rarely comes)). English tense-aspect forms cannot be equivalently translated into Russian, but in most cases, they coincide with the aspect forms of the verbs in the Tatar language. It is noticeable that G. Burbiel was competent enough to understand such corresponding features when translating the material into English.

The work gives a full description of other parts of speech, each of them accompanied by relevant source materials.

In contrast to "Grammar of the Tatar Language" (volume II, Kazan, 2003), composed by M. Zakiev, D. Tumashev and F. Khisamov, G. Burbiel's grammar provides examples of word-building and syntax in the subsection of morphology alongside with the analysis of the parts of speech. In other words, G Burbiel's book includes information, which is almost comparable to the three-volume "Grammar of the Tatar Language" published by G. Ibragimov Institute of Language, Literature and Art. We believe that this is a distinguishing feature of this work. The material, collected in a single book, gives a whole perspective on the form of a certain part of speech, its grammatical features, and its use in a sentence. Moreover, the work covers a certain amount of linguistic and cultural material: for example, the use of Tatar numerals in their sacral meaning, speech patterns used only in the Tatar language, etc. To a certain extent, this work can be called comparative grammar, since the author constantly compares grammatical features of the Tatar language to the English language.

In conclusion, “Tatar Grammar” by the German Turkologist G. Burbiel leaves a positive impression. This work makes a great contribution to the world recognition and dissemination of the Tatar language. It would be advisable to see more editions published in the future.

**References**

Burbiel, G. (2018). *Tatar Grammar.* 901 p. Stockholm – Moscow, Institute for Bible Translation. (In English, in Tatar)

---

# ГУСТАВ БУРБИЕЛНЕҢ «ТАТАР ГРАММАТИКАСЫ» (BURBIEL G. TATAR GRAMMAR. STOCKHOLM – MOSCOW: INSTITUTE FOR BIBLE TRANSLATION, 2018. 901 P.) ХЕЗМӘТЕНӘ БӘЯЛӘМӘ

**Рәдиф Рифкать улы Җамалетдинов,**
Казан федераль университеты,
Россия, 420008, Казан ш., Кремль ур., 18 нче йорт,
director@ifi.kpfu.ru.

**Раушания Сәгъдәтҗан кызы Нурмөхәммәтова,**
Казан федераль университеты,
Россия, 420008, Казан ш., Кремль ур., 18 нче йорт,
rsagadat@yandex.ru.

**Фәнүзә Хәйдәр кызы Габдрахманова,**
Казан федераль университеты,
Россия, 420008, Казан ш., Кремль ур., 18 нче йорт,
fanuza_mayak@list.ru.

Әлеге мәкаләдә алман тюркологы Густав Бурбиелнең «Татар грамматикасы» (Gustav Burbiel Tatar grammar. Stockholm – Moscow, 2018) китабына бәяләмә бирелә. Бу хезмәт – татар әдәби теленең инглизчә язылган грамматикасы. Аның авторы 1970–1980 нче елларда Швециядә Библияне тәрҗемә итү институты белән хезмәттәшлек иткән, Библиянең төрки телләргә тәрҗемәләрен редакцияләгән. Шулай ук ул Татарстан Республикасы Фәннәр академиясе Г. Ибраһимов исемендәге Тел, әдәбият һәм сәнгать институтының әйдәп баручы фәнни хезмәткәре Х. Р. Курбатов белән дә якыннан таныш булган, грамматиканы төзегәндә аның өлеше дә кергән. Густав Бурбиел тел белеме өлкәсендәге әлеге саллы хезмәтен 1994 нче елда тәмамлый һәм вафат була. Швециянең Библияне тәрҗемә итү институты 2001 нче елда гына аны берничә нөсхәдә китап итеп бастырып чыгара. Хезмәтнең әһәмияте тагын бер тапкыр барланып, 2018 нче елда ул яңадан нәшер ителә. Шәрык фәннәре белгече, лингвист Николай Николаевич Поппенең (Nicholos Poppe) 1963 нче елда басылып чыккан «Tatar Manual» китабыннан кала, Г. Бурбиелнең бу хезмәте татар грамматикасын инглиз теле аша киң җәмәгатьчелеккә таныткан иң күләмле һәм кыйммәтле хезмәт булып санала.

**Төп төшенчәләр:** татар тел белеме, татар грамматикасы, Густав Бурбиел, татар теле, инглиз теле.

Төрки телләр төркеменә кергән татар теле – бик бай тарихлы тел. Бу телдә сөйләшүчеләр Татарстанда гына түгел, дөньяның төрле почмакларында яши. Татар теле белән кызыксыну бүгенге көндә сизелерлек арта бара. Шул нисбәттән Густав Бурбиелнең дөньякүләм киң таралган телләрнең берсе булган инглиз телендә язылган «Татар теле грамматикасы» гаҗәеп кыйммәткә ия. 1994 нче елда язылуына карамастан, татар телен өйрәнергә теләгән инглиз телле галимнәр, тел белгечләре һәм, гомумән, тел белән кызыксынучылар өчен әлеге хезмәт бүгенге көндә дә бик әһәмияле һәм актуаль.

Хезмәттә татар теле тарихы, фонетикасы, сүз ясалышы, морфологиясе буенча тулы

мәгълүмат бирелә, күпмедер күләмдә синтаксис буенча да үрнәкләр китерелә, теоретик материал әдәби әсәрләрдән, вакытлы матбугаттан җыелган мисаллар белән баетылып барыла. Хезмәтнең тагын бер мөһим һәм үзенчәлекле ягы: материаллар комплексды рәвештә бирелә. Мәсәлән, морфология бүлегендә сүз ясалышы, төрле сүз төркемнәренең бер-берсе белән ярашуы, җөмләдә кулланылышы буенча мәгълүмат алырга була.

Г. Бурвиел татар телен тасвирлауга багышланган әлеге хезмәтен дүрт өлешкә бүлә: 1) фонетика һәм орфография; 2) морфология; 3) китапта телгә алынган атамаларның алфавитлы күрсәткече; 4) хезмәттә әсәрләре чыганак буларак кулланылган авторларның исемлегеннән һәм татарча кеше исемнәреннән гыйбарәт булган кушымта. Ләкин хезмәтне биш өлештән тора дип әйтергә мөмкин, чөнки кереш өлешендә татар теленең төрки телләр арасында тоткан урыны, аның диалектлары, татар теле тарихы турында шактый күләмле материал бирелә.

Фонетика һәм орфография бүлегендә татар телендәге сузык һәм тартык авазларның классификациясе, ирен һәм рәт гармониясе турында мәгълүмат китерелә, латин графикасы, кириллицага нигезләнгән алфавит һәм сүз ясалышы үрнәкләре тәкъдим ителә.

Татар телендәге сузык авазлар, нигездә, инглиз телендәге сузыкларга охшаш. Автор да моны бик яхшы аңлый һәм, инглиз телендәге авазлар белән чагыштырып, шул аваз кергән сүзләрне биреп бара:

i – it sounds approximately like English 'i' in 'police', 'machine': il 'country', min 'I' [Burbiel 2018: 3] (и – бу аваз якынча инглиз телендәге 'i' авазына охшаш, мәсәлән, 'police', 'machine' сүзләре).

Алай гына да түгел, кайбер авазларның алман телендә аваздаш булган вариантларын да китерә:

ө – it is a sound between German 'ö' and 'ü' [Burbiel 2018: 3] (ө авазы алман телендәге 'ö' һәм 'ü' авазларына охшаш).

Шунысы игътибарга лаек: татар телендәге сүзләрне ул транскрипция һәм транслитерация алымнарын файдаланып тәкъдим итә һәм, татар телендә кайбер авазларның әйтелешенә басым ясар өчен, инглиз телендә булмаган 'ş', 'ç', 'ƣ' кебек хәрефләрне дә куллана, мәсәлән, *ашый – aşi*. Инглиз телендә 'ш' авазы 'sh' кушылмасы белән белдерелә, ләкин Г. Бурвиел хезмәтендә яңалиф графикасында кулланылган 'ş' тамгасын файдалануны кулайрак күрә.

Автор алынма сүзләрдә авазларның икенче төрле әйтелешенә дә игътибар итә, һәр авазга бәяләмә биргәндә бу хакта искәртеп бара. Шулай ук әлеге авазларны белдерер өчен татар алфавитында аерым хәреф булмаганлыгына да басым ясый.

Грамматиканың иң зур өлешен икенче бүлек – морфология тәшкил итә. Әлеге бүлектә исем, сыйфат, сан, алмашлык, рәвеш, фигыль, аваз ияртемнәре, бәйлек, теркәгеч, кисәкчә, модаль һәм кереш сүзләр, ымлыкларга тулы характеристика бирелә, теоретик материал бик бай фактик мисаллар белән ныгытылып барыла.

Исем сүз төркеме дигән бүлекчәдә Г. Бурвиел исемнәрнең нинди ысуллар, кушымчалар белән, кайсы сүз төркемнәреннән ясалышына, сан, килеш, тартым кебек грамматик категорияләренә, изафә бәйләнешенә җентекләп туктала. Автор татар телендә род категориясе булмавын күрсәтә, ләкин, кайбер сүзләрнең семантикасыннан чыгып, затның нинди җенестән булуын билгеләргә мөмкинлеген әйтеп китә, мәсәлән, *әби, бабай, хуҗабикә, ханбикә* һ. б. Бу бүлекчәдә тартымлы исемнәрнең килеш белән төрләнүе, инглиз телендә туры килгән формалары белән рәттән куелып, бик унайлы рәвештә, таблицага салып бирелә.

Сыйфат сүз төркемен тикшергәндә, сыйфат ясагыч кушымчаларга, сыйфат төркемчәләренә, дәрәҗәләренә тукталу белән беррәттән, автор исем сүз төркеменнән конверсия юлы белән ясалган сыйфатларны һәм, киресенчә, әлеге юл белән сыйфатлардан исем ясалган очракларны, төсне белдергән сыйфатларны ассызыклап үтә. Инглиз телендә English, Russian кебек сыйфатлар милләтне һәм телләрне дә белдереп киләләр. Шуңа бәйле рәвештә Г. Бурвиел татар телендә милләтләрне һәм телләрне белдерү юлларын бу бүлекчәдә урнаштыруны кулай күрә. Автор, инглиз теленнән аермалы буларак, татар телендә тел һәм милләт атамалары юл хәрефеннән язылуына да игътибар итә.

Сан сүз төркемен биргәндә аның төркемчәләрен санап, аларны аңлатканнан соң, автор *күп, аз* кебек сүзләрнең санны белдереп килүләрен әйтеп үтә. Шуңа бәйләп, бу бүлекчәдә күләм хәле турында да мәгълүмат китерә.

Алмашлык сүз төркемен дә автор тулы итеп ачып бирә, мәгънә ягыннан төрләренә җентекләп туктала.

Күләме ягыннан иң зур урынны, әлбәттә, фигыль сүз төркеме ала. Г. Бурвиел хезмәттә наклонение, зат-сан, юнәлеш, дәрәҗә, барлык-юклык категорияләрен җентекләп, аңлап бәян итә. Белгәнебезчә, инглиз теле заман формаларының күп төрле булуы белән аерылып тора. Татарлар да вакытны барлык нечкәлекләре белән тоемлыйлар, моның шулай икәнлеген фигыль дәрәҗәләреннән төшенергә була (мәсәлән, *килә, килгәли, килештергәли*). Инглиз телендә кулланылган, рус теленә төгәл тәрҗемә итеп булмаган вакыт формалары күпчелек очракта татар телендәге фигыль дәрәҗәләре белән тәңгәл килә. Г. Бурвиелнең дә, материалны инглиз теленә тәрҗемә иткәндә, бу тәңгәллекне тоеп эшләгәнлеге күренә.

Хезмәттә башка сүз төркемнәренә дә тулы характеристика бирелә, һәр күренеш фактик чыганаклар белән үрелеп барыла.

Гомумән алганда, М. З. Зәкиев, Д. Г. Тумашева, Ф. М. Хисамова редакциялегендә чыккан «Татар грамматикасы»ннан (II том, Казан, 2003) аермалы буларак, Г. Бурвиел китабының морфология бүлегендә сүз төркемнәренә характеристика биргәндә сүз ясалышы һәм синтаксистан да мисаллар китерелә, ягъни Г. Бурвиел грамматикасында Г. Ибрагимов исемендәге тел, әдәбият һәм сәнгать институты чыгарган «Татар грамматикасы»ның өч томында тупланган мәгълүмат күпмедер дәрәҗәдә берләштереп бирелә, дияргә була. Без моны хезмәтнең үзенчәлекле ягы дип саныйбыз, чөнки материал бер җирдә тупланып, билгеле бер сүз төркеменең ясалышы, грамматик формалары һәм җөмләдә кулланылышын яктырткан тулы бер күзаллау барлыкка килә. Хезмәттә билгеле бер күләмдә лингвомәдәни материал да биреп барыла. Мәсәлән, татар телендә саннарның сакраль мәгънәдә кулланылган очраклары, татар теленә генә хас сөйләм калыплары һ. б. Г. Бурвиелнең әлеге хезмәтен, билгеле бер дәрәҗәдә, чагыштырма грамматика дип тә атарга мөмкин, чөнки автор татар телендәге грамматик күренешләргә һәрдаим инглиз телендәге вариантларны тәкъдим итеп, чагыштырып бара.

Нәтиҗә ясап, шуны әйтергә була: алман тюркологы Г. Бурбиелнең зур күләмле «Татар грамматикасы» китабы уңай тәэсир калдыра. Әлеге хезмәт татар телен дөньякүләм танытуга, киң даирәгә таратуга зур өлеш кертә. Киләчәктә аның тагын да күбрәк тираж белән нәшер ителүен теләп каласы килә.

**Әдәбият**

Burbiel G. Tatar grammar. Stockholm – Moscow: Institute for Bible Translation, 2018. 901 p.

---

# РЕЦЕНЗИЯ НА ТРУД ГУСТАВА БУРБИЕЛА «ТАТАРСКАЯ ГРАММАТИКА» (GUSTAV BURBIEL «TATAR GRAMMAR», STOCKHOLM, 2018)

**Радиф Рифкатович Замалетдинов,**
Казанский федеральный университет,
Россия, 420008, г. Казань, ул. Кремлевская, д. 18,
director@ifi.kpfu.ru.

**Раушания Сагдатжановна Нурмухамметова,**
Казанский федеральный университет,
Россия, 420008, г. Казань, ул. Кремлевская, д. 18,
rsagadat@yandex.ru.

**Фануза Хайдаровна Габдрахманова,**
Казанский федеральный университет,
Россия, 420008, г. Казань, ул. Кремлевская, д. 18,
fanuza_mayak@list.ru.

В данной статье дается оценка книге немецкого тюрколога Густава Бурбиеля «Татарская грамматика» (Gustav Burbiel. Tatar grammar. Stockholm – Moscow, 2018). Данное издание представляет собой англоязычную грамматику татарского (по автору – казанско-татарского)

литературного языка. Густав Бурбиел сотрудничал с Институтом перевода Библии в Швеции в 1970-х и 1980-х гг., где редактировал новые переводы Библии на тюркские языки. Непосредственное участие в составлении этого труда также принял Х. Р. Курбатов, ведущий научный сотрудник отдела языкознания ИЯЛИ им. Г. Ибрагимова АН РТ. Густав Бурбиел закончил данный обьемный труд в 1994 году и в скором времени ушел из жизни. В январе 2001 года Институт перевода Библии в Швеции напечатал несколько экземпляров пробного издания. Несмотря на десятилетия, которые прошли между написанием этой грамматики, сотрудники Института сочли его труд все еще востребованным и актульным и переиздали в 2018 году. Грамматика Бурвиеля, за исключением грамматики «Tatar Manual» лингвиста и востоковеда Николая Николаевича Поппе (Nicholos Poppe), опубликованной в 1963 году, считается масштабной и бесценной работой в области татарского языкознания, написанной на английском языке.

**Ключевые слова:** татарское языкознание, татарская грамматика, Густав Бурбиел, татарский язык, английский.

Scientific Chronicles of the Turkic World
Төрки дөнья фәнни хроникасы
Научная хроника тюркского мира

DOI: 10.26907/2311-2042-2019-13-2-175-186

# LATEST EVENTS IN THE SECOND HALF OF 2019

On June 3–4, the Department of Ural-Altai Languages at the Institute of Linguistics, the Russian Academy of Sciences, held a conference dedicated to the 98$^{th}$ birthday of the famous Turkologist E. R. Tenisheva. The conference topics included research on the Ural and Altai languages and cultures, as well as on comparative-historical linguistics. The conference was held as part of the RSF 18-18-00501 research project “Creating an electronic dialectological atlas of Turkic languages in Russia”. The sessions discussed the following topics: “Vocabulary and Phraseology of Turkic Languages”, “Written Monuments of Turkic Languages”, “Phonetics and Grammar of Turkic Languages”, “Altai Languages”, “Uralic Languages”, “Comparative Studies, Typology”. (More details on the official website of the Institute of Linguistics, the Russian Academy of Sciences: http://iling-ran.ru/main/conferences/2019_tenishev).

---

On June 6–7, Azerbaijan State Pedagogical University (Baku) held the International Scientific Conference dedicated to the 90th anniversary of the outstanding linguist, Turkologist and public figure Afat Kurbanov. The conference was attended by researchers from Azerbaijan, Turkey, Kazakhstan, Georgia, Serbia, and from various cities of Russia. The participants discussed a wide range of topical issues on general, Turkic and practical linguistics, onomasiology, the literary Azerbaijani language and the modern Azerbaijani alphabet. Prof. A. Yusupova, Doctor of Philology in the Department of General Linguistics and Turkology, Kazan Federal University, presented her report “Features of Expressing Aggression in the Tatar Language” at the Turkic linguistics session. (More details on the official website of Azerbaijan State Pedagogical University: http://www.adpu.edu.az/index.php/az/adpu-da-afad-gurbanovun-90-illik-yubileyinae-haesr-olunmush-muasir-dilchiliyin-aktual-problemlaeri-beynaelkhalg-elmi-konfrans-kechirilib)

---

On August 19– 23, the International Seminar “Central Asia at the Crossroads of European and Asian Political Interests: The 18$^{th}$ – 19$^{th}$ Centuries” was held at Al-Farabi Kazakh National University. The seminar was attended by Kazakh and foreign scholars, historians, and experts from Poland, the USA, and the Republic of Kazakhstan. In their speeches, the speakers discussed the ideas of Eurasianism, the factors of socio-economic modernization in the Central Asian region of the Russian Empire, and the modern historiography of the Oirats’ role in the Central Asian system of international relations in the 18$^{th}$ century. The

organizer of the seminar was Kazakh National University named after al-Farabi. (More details on the official website of *the* seminar: http://foreignasia.ru/).

---

On September 10–14, G. Ibragimov Institute of Language, Literature and Art, the Academy of Sciences of the Republic of Tatarstan, held events dedicated to the 80th anniversary of the Institute: 1) the International Research Conference "Turkic Linguistics in the 21st Century: Lexicology and Lexicography"; 2) round table discussions of the topic "National Literatures at the Current Stage: Scientific Concepts and Hypotheses"; 3) the ceremonial meeting to mark the 80th anniversary of the Institute of Language, Literature and Art named after G. Ibragimov, the Academy of Sciences of the Republic of Tatarstan; 4) the 31st International Autumn Scientific School "The Linguistic Picture of the World". The participants in the International Scientific Conference "Turkic Linguistics of the 21st Century: Lexicology and Lexicography" discussed a wide range of topical issues devoted to the lexicology of Turkic languages: Turkic historical lexicology and etymology, dialect lexicology and lexicography, comparative and contrastive lexicology and terminology of Turkic languages, and other topics. (More details on the official website of the IJAL AN RT: http://www.antat.ru/ru/iyli/news/9313/).

---

On September 12–14, the First International Altai Forum "Turkic-Mongolian World of Big Altai: Historical-Cultural Heritage and Modernity" was held in the Altai Territory and the Republic of Altai. The main organizers of the forum were Altai State University (Barnaul) and Gorno-Altai State University (Gorno-Altaisk) with the support of the Standing International Altai Conference (PIAC) Secretariat. The forum was supported by the Office for Interregional and Cultural Relations with Foreign Countries of the Presidential Administration, the Ministry of Science and Higher Education of the Russian Federation, the Federal Agency Rossotrudnichestvo, and the Council of the Interparliamentary Assembly of the CIS Member States. (More details on the official forum website: http://konf.asu.ru/altai/).

---

On September 26–28, Ankara hosted the International Congress "Kutadgu Bilig", organized by the Turkish Linguistic Society and dedicated to the 950th anniversary of the literary monument "Kutadgu Bilig". The congress was attended by prominent Turkologists from Turkey, Kazakhstan, Azerbaijan, Russia, Iran, Kyrgyzstan and other countries of the world. The speakers focused attention on the studies related to the written heritage of Yusuf Balasaguni, a Turkic thinker, poet and statesman of the Karakhanid era, and the genre, metric and artistic features of Kutadgu Bilig, the oldest and largest Turkic literature written monument of the 11th century. G. Mugtasimova, an Associate Professor in the Department of General Linguistics and Turkology IFMK KFU, took part in the Congress. She presented her report "The Work of Yusuf Khas Hadzhib Balasaguni 'Kutadgu bilig' and Tatar Folk Proverbs". (More information on the official website of the congress: http://kurultay.tdk.gov.tr/).

---

On October 3–5, the 7th International Conference on Computer Processing of Turkic Languages "TurkLang 2019" was held in Simferopol (Crimea, RF). The forum participants discussed current issues in the field of information technology, linguistics, and computer linguistics. The organizers of the event were: Crimean Federal University named after V. Vernadsky, Crimean Engineering and Pedagogical University, the Academy of Sciences of the Republic of Tatarstan, Eurasian National University named after L. Gumilyov, Istanbul Technical University, and the Russian Association of Artificial Intelligence. (More information on the official website of TurkLang: www.turklang.tatar).

---

The Days of Tatar Education were held in the Kyrgyz Republic from October 14 to October 16. The participants of the event discussed the development of ethnocultural education, international cooperation, and presented awards of the Ministry of Education and Science of the Republic of Tatarstan. On October 16, participants of the meeting at the Ministry of Education and Science of the Kyrgyz Republic discussed

the issues of bilateral cooperation in the field of education and science. They emphasized that the Days of Tatar Education in Kyrgyzstan have become an effective platform for preserving and developing education, and strengthening educational, cultural and interethnic relations between the representatives of executive authorities, teachers, and public leaders. The organizer of the event was the Ministry of Education and Science of the Republic of Tatarstan. (More details on the official website of the RT Academy of Sciences www.antat.ru).

---

On October 23–25, the International Research and Practice Conference "The Bashkir Language and Literature in the Context of Globalization and Multi-ethnic Environment: Experience and Prospects" was held in Ufa. The Institute of Philology and Intercultural Communication of KFU was represented by Prof. A. Yusupova, the Department of General Linguistics and Turkology, Prof. F. Nurieva, the Department of Tatar Linguistics, Associate Professors in the Department of General Linguistics and Turkology R. Nurmukhametova, G. Mugtasimova, F. Sibgaeva, G. Nabiullina and R. Salahova.

The Conference was attended by the representatives of state authorities at the federal and regional levels, philologists and university professors from different cities of Russia: Moscow, St. Petersburg, Yekaterinburg, Kazan, Izhevsk, Samara, Orenburg, and Yakutsk, as well as from neighboring countries: Kazakhstan, Kyrgyzstan, Turkey, Turkmenistan, and Uzbekistan.

The conference highlighted the issues of the preservation, development and popularization of the Bashkir language, as well as the languages of the peoples of Russia in the era of globalization, the issues of teaching the mother tongue and the state language, the implementation of scientific research results, and the topical problems of developing electronic databases of national languages.

The conference provided a platform for the exchange of experience, for the establishment of new scientific contacts, it became a place for heated debates and important decisions. (More details on the official site of the conference bashkconference.ru).

---

On October 28, at the Institute of Archeology named after A. Khalikov, "Archaeological Woodwork", the International Research Conference of unique organization was held in the two states of Russia and Belarus. This event was organized with the support of the Ministry of Culture of the Republic of Tatarstan within the framework of an agreement on international cooperation with the Brest Regional Museum of Local Lore and the National Academy of Sciences of the Republic of Belarus. The conference was attended by scientists from the Russian Federation and the Republic of Belarus. From October 29 to November 01, 2019, this international research forum continued its work in Sviyazhsk on the basis of the Ostrov-Grad Sviyazhsk State Historical and Architectural Art Museum-Reserve. Within the framework of the international conference, a round table discussion "Problems and Prospects for the Development of Scientific and Museum Cooperation between Russia and Belarus" was held. The conference completed its work on October 31, 2019, in Brest (the Republic of Belarus) in the branches of the Brest Regional Museum of Local Lore: the Art Museum and the Berestye Archaeological Museum . The speeches emphasized the importance and prospects of cooperation between the researchers of the Republic of Tatarstan and Belarus. (More details on the official website of the A. Halikov Institute of Archeology, the Academy of Sciences of the Republic of Tatarstan: www.arhtat.ru).

---

On November 8, the International Research and Practice Conference "Ethnic Culture in the Modern World" was held at the Chuvash State Institute of Culture and Arts as part of the Golden Cradle International Ethnocultural Forum, dedicated to the centenary of the Chuvash Autonomous Region. During the conference, reports were made on the generalization of the experience gained in the sphere of popularization, preservation and development of ethnocultures in Russia, in teaching spiritual, moral and cultural-patriotic values to young people. In their speeches, conference participants emphasized the importance of ethnic culture as a factor in preserving people's identity. (More details on the official website of the Chuvash State Institute of Humanities: www.chgign.ru).

---

On November 21–24, the 9th International Research and Practice Forum "Preservation and Development of Languages and Cultures" was held at the Lev Tolstoy Institute of Philology and Intercultural Communication of Kazan Federal University. Within the framework of the forum, five conferences were held: the 10th International Research and Practice Conference "Preservation and Development of Mother Tongues in a Multinational State: Problems and Prospects"; the 2nd International Research and Practice Conference "Tatar Linguistics in the Context of the Eurasian Humanities"; the 4th International Research and Practice Conference "Preservation of the Artistic and Historical Environment of the Modern City as a Spiritual Factor of Culture"; the 8th International Research and Practice Conference "Art and Art Education in the Context of Intercultural Interactions"; International Research and Practice Conference for young scientists "Khakov Readings". The conference was attended by well-known scientists from the CIS countries and abroad: Turkey, Kazakhstan, Turkmenistan, Uzbekistan, Kyrgyzstan, as well as from Moscow, St. Petersburg, Maykop, Kazan, Ufa, Makhachkala, Sterlitamak, Tobolsk and other cities. In their speeches at plenary and breakout sessions, the forum participants emphasized the need for coordinated work with various regions of Russia on the development of Turkic languages and culture to solve the existing problems, to popularize the teaching and learning of native, Russian and foreign languages among the younger generation. More details on the official website of the Institute of Philology and Intercultural Communication of Kazan Federal University: https://kpfu.ru/philology-culture/vii-mezhdunarodnyj-nauchno-prakticheskij-forum.html).

*The information was submitted by G. A. Nabiullina and G. R. Mugtasimova, Associate Professors of the Institute of Philology and Intercultural Communication, Kazan Federal University.*

# 2019 ЕЛНЫҢ II ЯРТЫСЫНДА БУЛГАН ВАКЫЙГАЛАР

3-4 нче июнь көннәрендә Россия Фәннәр академиясенең Урал-Алтай телләре бүлеге, танылган тюрколог Э.Р. Тенишевның тууына 98 ел тулу уңаеннан, конференция үткәрде. Конференция тематикасына Урал, Алтай телләре һәм мәдәниятләре, шулай ук чагыштырма-тарихи тел белеме буенча тикшеренүләр кертелгән. Конференция «Россия төрки телләренең электрон диалектологик атласын булдыру» РНФ проекты буенча тикшеренүләр кысаларында үткәрелде. Секцияләрнең эше түбәндәге темаларга багышланган иде: «Төрки телләрнең лексикасы һәм фразеологиясе», «Төрки телләрнең язма истәлекләре», «Төрки телләрнең фонетикасы һәм грамматикасы», «Алтай телләре», «Урал телләре», «Компаративистика, типология». (Тулырак РФА Тел белеме институтының рәсми сайтында: http://iling-ran.ru/main/conferences/2019_tenishev)

---

6-7 нче июньдә Әзербайҗан дәүләт педагогика университетында (Баку шәһәре) күренекле тел галиме, тюрколог һәм җәмәгать эшлеклесе Афат Корбановның тууына 90 ел тулуга багышланган Халыкара фәнни конференция узды. Конференция эшендә Әзербайҗан, Төркия, Казахстан, Грузия, Сербия, шулай ук Россиянең төрле шәһәрләреннән галимнәр катнашты. Конференциядә катнашучылар гомум, төрки һәм гамәли тел белеменә, ономасиологиягә, әдәби әзербайҗан теленә һәм хәзерге әзербайҗан алфавитына багышланган актуаль мәсьәләләр хакында фикер алыштылар. Төрки тел белеме секциясе эшендә КФУның гомуми тел белеме һәм тюркология кафедрасы профессоры, филология фәннәре докторы А.Ш. Юсупова катнашты. Ул «Татар телендә агрессия белдерүнең кайбер үзенчәлекләре» дигән темага доклад белән чыгыш ясады. (Тулырак Әзербайҗан дәүләт педагогика университетының рәсми сайтында: http://www.adpu.edu.az/index.php/az/adpu-da-afad-gurbanovun-90-illik-yubileyinae-haesr-olun).

---

19-23 нче август көннәрендә Әл-Фәраби исемендәге Казах милли университетында «Үзәк Азия Европа һәм Азия сәяси мәнфәгатьләре чатында: XVIII – XIX гасырлар» Халыкара семинары узды. Семинарда илебез һәм чит ил галимнәре, тарихчылар һәм экспертлар, Польша, АКШ, Казахстан Республикасы галимнәре катнашты. Докладчылар үз чыгышларында Евразия идеяләрен, Россия империясенең Үзәк-Азия төбәген социаль-икътисадый модернизацияләү факторларын, Үзәк Азиянең халыкара мөнәсәбәтләр системасында ойратларның хәзерге тарихын чагылдырдылар. Семинарны Әл-Фәраби исемендәге Казах милли университеты оештырды. (Тулырак семинарның рәсми сайтында: http://foreignasia.ru/).

---

10-14 нче сентябрь көннәрендә Татарстан Республикасы Фәннәр академиясенең Г. Ибраһимов исемендәге Тел, әдәбият һәм сәнгать институтында Институт оештырылуның 80 еллыгына багышланган түбәндәге чаралар үткәрелде: 1) «XXI гасыр төрки тел белеме: лексикология һәм лексикография» Халыкара фәнни конференциясе; 2) «Хәзерге этапта милли әдәбиятлар: фәнни концепцияләр һәм гипотезалар» темасына түгәрәк өстәл; 3) ТР Фәннәр академиясенең Г. Ибраһимов исемендәге Тел, әдәбият һәм сәнгать институтының 80 еллык юбилеена багышланган тантаналы утырыш; 4) XXXI Халыкара көзге «Дөньяның тел картинасы» фәнни мәктәбе.

«XXI йөз төрки тел белеме: лексикология һәм лексикография» Халыкара фәнни конференциясендә катнашучылар төрки телләрнең лексикологиясенә: төрки тарихи лексикологиягә һәм этимологиягә, диалекталь лексикологиягә һәм лексикографиягә, төрки телләрнең чагыштырма лексикологиясенә һәм терминологиясенә һәм башка темаларга багышланган актуаль мәсьәләләр хакында фикер алыштылар. (Тулырак ТР Фәннәр академиясенең рәсми сайтында: http://www.antat.ru/ru/iyli/news/9313/).

---

12-14 нче сентябрьдә Алтай краенда һәм Алтай Республикасында «Зур Алтай төрки-монгол дөньясы: тарихи-мәдәни мирас һәм хәзерге заман» Беренче халыкара алтаистик форум узды. Алтай дәүләт университеты (Барнаул шәһәре) һәм Таулы Алтай дәүләт университеты (Таулы Алтай шәһәре) форумның төп оештыручылары булып тора. Форумны уздыру инициативасы белән РФ Президенты администрациясенең Чит илләр белән төбәкара һәм мәдәни элемтәләр идарәсе, РФ Фән һәм югары белем министрлыгы, «Россотрудничество» федераль агентлыгы, БДБ дә катнашучы дәүләтләрнең парламентара ассамблеясе советы чыкты. (Тулырак форумның рәсми сайтында: http://konf.asu.ru/altai/).

---

26-28 нче сентябрь көннәрендә Анкарада Төркия лингвистик җәмгыяте оештырган һәм «Котадгу белек» әсәренең 950 еллыгына багышланган «Кутадгу белег» Халыкара конгрессы булды. Конгресс эшендә Төркия, Казахстан, Әзербайҗан, Россия, Иран, Кыргызстан һәм дөньяның башка илләреннән күренекле галимнәр-тюркологлар катнашты. Чыгыш ясаучыларның төп темалары булып төрки акыл иясе, шагыйрь һәм Караханилар чорының дәүләт эшлеклесе Йосыф Баласагуниның язма мирасына, шул исәптән XI йөз төрки телле әдәбиятның иң борынгы һәм иң күләмле язма истәлеге «Котадгу белег» нең жанр, метрик һәм сәнгати үзенчәлекләренә кагылышлы тикшеренүләр торды.

Конгресс эшендә КФУның гомуми тел белеме һәм тюркология кафедрасы доценты Г. Р. Мөгътәсимова катнашты. Ул «Йосыф Хас Хаҗиб Баласагуниның «Котадгу белег» әсәре һәм татар халык мәкальләре» дигән докладын тәкъдим итте. (Тулырак мәгълүмат конгресснең рәсми сайтында: http://kurultay.tdk.gov.tr/).

---

3-5 нче октябрьдә Симферопольдә (Кырым, РФ) төрки телләрне компьютер эшкәртү буенча «TurkLang 2019» VII Халыкара конференциясе булды. Форумда катнашучылар мәгълүмати технологияләр, тел белеме һәм компьютер лингвистикасы өлкәсендә актуаль проблемалар турында фикер алыштылар. Чараны оештыручылар: В.И. Вернадский исемендәге Кырым федераль университеты, Кырым инженер-педагогика университеты, Татарстан Республикасы Фәннәр академиясе, Л.Н. Гумилёв исемендәге Евразия милли университеты, Истанбул техник университеты, Россия ясалма интеллект ассоциациясе. (Тулырак мәгълүмат TurkLang рәсми сайтында: www.turklang.tatar).

---

14 октябрьдән 16 октябрьгә кадәр Кыргызстан Республикасында Татар мәгарифе көннәре узды. Чарада катнашучылар этномәдәни белем бирүне һәм халыкара хезмәттәшлекне үстерү мәсьәләләре турында фикер алыштылар, Татарстан Республикасы Мәгариф һәм фән министрлыгының тармак бүләкләре тапшырылды. 16 нчы октябрьдә Кыргызстан Республикасының Мәгариф һәм фән министрлыгында узган очрашуда мәгариф һәм фән өлкәсендә икеяклы хезмәттәшлек мәсьәләләре турында фикер алыштылар. Чарада катнашучылар ассызыклаганча, Кыргызстанда татар мәгарифе көннәрен үткәрү, башкарма хакимият органнары вәкилләре, педагоглар һәм җәмәгатьчелек лидерлары арасында мәгарифне саклау һәм үстерү мәсьәләләрендә мәгариф, мәдәни һәм милләтара элемтәләрне ныгыту өчен, нәтиҗәле мәйданчык булды. Чараны ТР Мәгариф һәм фән министрлыгы оештырды. (Тулырак мәгълүмат Татарстан Республикасы Фәннәр академиясенең рәсми сайтында www.antat.ru).

---

23-25 октябрь көннәрендә Уфада глобальләшү һәм полиэтник мохит шартларында «Башкорт теле һәм әдәбияты: тәҗрибә һәм перспективалар» Халыкара фәнни-гамәли конференциясе узды. КФУның филология һәм мәдәниятара багланышлар институтын гомуми тел белеме һәм тюркология кафедрасы профессоры А.Ш. Юсупова, татар тел белеме кафедрасы профессоры Ф.Ш. Нуриева һәм гомуми тел белеме һәм тюркология кафедрасы доцентлары Р.С. Нурмөхәммәтова, Г.Р. Мөгътәсимова, Ф.Р. Сибгаева, Г.Ә. Нәбиуллина һәм Р.Р. Сәлахова тәкъдим итте.

Конференциядә катнашу өчен, федераль һәм региональ дәрәҗәдәге дәүләт хакимияте оешмалары вәкилләре, Россиянең Мәскәү, Санкт-Петербург, Екатеринбург, Казан, Ижевск, Самара, Оренбург, Якутск шәһәрләреннән, шулай ук якын чит илләрдән – Казахстан, Кыргызстан, Төркия, Төрекмәнстан, Үзбәкстаннан – югары уку йортлары галимнәре һәм укытучылары чакырылган иде.

Конференция эше барышында башкорт телен, шулай ук глобальләшү чорында Россия халыклары телләрен саклау, үстерү һәм популярлаштыру юнәлешләре яктыртылды, туган телләргә һәм дәүләт телләренә өйрәтү һәм фәнни тикшеренүләр нәтиҗәләрен куллану практикасы мәсьәләләре, милли телләрнең электрон базаларын эшләүнең актуаль проблемалары каралды.

Конференция тәҗрибә алмашу, яңа фәнни элемтәләр урнаштыру, дискуссияләр һәм мөһим карарлар кабул итү мәйданына әверелде. (Тулырак конференциянең bashkconference.ru рәсми сайтында).

---

28 нче октябрьдә А.Х. Халиков исемендәге Археология институтында ике дәүләттә – Россия һәм Беларусь дәүләтләрендә оештырылуы белән уникаль булган «Археологик агач» Халыкара фәнни конференциясе ачылды. Әлеге чара Брест өлкәсе музее һәм Беларусь Республикасы Милли Фәннәр академиясе белән халыкара хезмәттәшлек турындагы килешү кысаларында, ТР Мәдәният министрлыгы ярдәмендә оештырылды. Конференциядә Россия Федерациясе һәм Беларусь Республикасы галимнәре катнашты.

Халыкара фәнни форум эше 29 нчы октябрьдән 1 нче ноябрьгә кадәр Зөядә «Зөя утрау-шәһәрчеге» дәүләт тарих-архитектура һәм сәнгать музей-тыюлыгы базасында дәвам итте. Халыкара конференция кысаларында «Россия һәм Белоруссиянең фәнни һәм музей хезмәттәшлеге проблемалары һәм перспективалары» дигән түгәрәк өстәл узды. Конференция үз эшен 31 нче октябрьдә Беларусь Республикасы Брест шәһәрендә Брест өлкә туган якны өйрәнү музее филиалларында - сәнгать музее һәм «Берестье» археология агачы музеенда тәмамлый. Чыгышларда Татарстан Республикасы һәм Беларусь галимнәре арасындагы хезмәттәшлекнең мөһимлеге һәм киләчәге ассызыкланды. (Тулырак мәгълүмат ТР ФАнең А.Х. Халиков исемендәге Археология институтының рәсми сайтында: www.arhtat.ru).

---

8 нче ноябрьдә Чуваш дәүләт мәдәният һәм сәнгать институты базасында «Алтын бишек» Халыкара этномәдәни форумы кысаларында Чуваш автоном өлкәсе төзелүнең 100 еллыгына багышланган «Хәзерге дөньяда этник культура» Халыкара фәнни-гамәли конференциясе узды. Конференция эше барышында Россиянең этнокультураларын популярлаштыру, саклау һәм үстерү тәҗрибәсен гомумиләштерүгә, яшьләрдә рухи-әхлакый һәм мәдәни-патриотик кыйммәтләр тәрбияләүгә багышланган докладлар яңгырады. Конференциядә катнашучылар үз чыгышларында этник мәдәниятнең халык тәңгәллеген саклау факторы буларак әһәмиятен ассызыклады. (Тулырак Чуваш дәүләт гуманитар фәннәр институтының рәсми сайтында: www.chgign.ru).

---

21-24 нче ноябрь көннәрендә Казан федераль университетының Филология һәм мәдәниятара коммуникацияләр институты базасында «Телләрне һәм мәдәниятләрне саклау һәм үстерү» IX Халыкара фәнни-гамәли форумы узды. Форум кысаларында 5 конференция үткәрелде: «Күпмилләтле дәүләт шартларында туган телләрне саклау һәм үстерү: проблемалар һәм перспективалар» X Халыкара фәнни-гамәли конференциясе; «Евразия гуманитар фәннәре контекстында татар теле белеме» II Халыкара фәнни-гамәли конференциясе; «Мәдәниятнең рухи факторы буларак хәзерге шәһәрнең сәнгати-тарихи тирәлеген саклау» IV Халыкара фәнни-гамәли конференциясе; «Мәдәниятара хезмәттәшлек контекстында сәнгать һәм сәнгати белем» VIII Халыкара фәнни-гамәли конференция; яшь галимнәр өчен «Хаков укулары» Халыкара фәнни-гамәли конференциясе.

Конференция эшендә Төркия, Казахстан, Төрекмәнстан, Үзбәкстан, Кыргызстан илләреннән, шулай ук Мәскәү, Санкт-Петербург, Майкоп, Казан, Уфа, Махачкала, Стәрлетамак, Тубыл шәһәрләреннән күренекле галимнәр катнашты. Форумда катнашучылар үзләренең пленар һәм

секция утырышларындагы чыгышларында төрки телләрне һәм мәдәниятләрен үстерүдә, туган, рус һәм чит телләрне укытуны һәм яшь буын тарафыннан аларны өйрәнүне популярлаштыру буенча булган проблемаларны хәл итүдә, Россиянең төрле төбәкләре белән координацияле эш алып бару зарурлыгын ассызыкладылар. (Тулырак Казан федераль университетының Филология һәм мәдәниятара бағланышлар институтының рәсми сайтында: https://kpfu.ru/philology-culture/vii-mezhdunarodnyj-nauchno-prakticheskij-forum.html).

*Материаллар филология фәннәре кандидаты, Казан федераль университетының Филология һәм мәдәниятара бағланышлар институты доценты Г.Ә. Нәбиуллина һәм филология фәннәре кандидаты, Казан федераль университетының Филология һәм мәдәниятара бағланышлар институты доценты Г.Р. Мөгътәсимовалар тарафыннан тупланды һәм әзерләнде.*

# ПРОШЕДШИЕ СОБЫТИЯ II ПОЛОВИНЫ 2019 ГОДА

3–4 июня Отделом урало-алтайских языков Института языкознания Российской академии наук была проведена конференция, посвященная 98-летию со дня рождения известного тюрколога Э. Р. Тенишева. В тематику конференции вошли исследования по уральским, алтайским языкам и культурам, а также по сравнительно-историческому языкознанию. Конференция проводилась в рамках исследований по проекту РНФ 18-18-00501 «Создание электронного диалектологического атласа тюркских языков России». Работа секций была посвящена следующим темам: «Лексика и фразеология тюркских языков», «Письменные памятники тюркских языков», «Фонетика и грамматика тюркских языков», «Алтайские языки», «Уральские языки», «Компаративистика, типология» (см. подробнее на официальном сайте Института языкознания РАН: http://iling-ran.ru/main/conferences/2019_tenishev).

---

6–7 июня в Азербайджанском государственном педагогическом университете (г. Баку) состоялась Международная научная конференция, посвященная 90-летнему юбилею выдающегося ученого-языковеда, тюрколога и общественного деятеля Афата Курбанова. В работе конференции приняли участие ученые из Азербайджана, Турции, Казахстана, Грузии, Сербии, а также из различных городов России. Участники конференции обсудили широкий круг актуальных вопросов, посвященных общему, тюркскому и практическому языкознанию, ономасиологии, литературному азербайджанскому языку и современному азербайджанскому алфавиту. В работе секции тюркского языкознания приняла участие профессор кафедры общего языкознания и тюркологии КФУ, доктор филологических наук А. Ш. Юсупова, выступив с докладом «Некоторые особенности выражения агрессии в татарском языке» (см. подробнее на официальном сайте Азербайджанского государственного педагогического университета: http://www.adpu.edu.az/index.php/az/adpu-da-afad-gurbanovun-90-illik-yubileyinae-haesr-olunmush-muasir-dilchiliyin-aktual-problemlaeri-beynaelkhalg-elmi-konfrans-kechirilib).

---

19–23 августа в КазНУ имени аль-Фараби прошел международный семинар «Центральная Азия на перекрестке европейских и азиатских политических интересов: XVIII–XIX вв.». В семинаре приняли участие отечественные и зарубежные ученые, историки и эксперты, из Польши, США, Республики Казахстан. Выступления докладчиков были посвящены идеям евразийства, факторам социально-экономической модернизации Центрально-Азиатского региона Российской империи, роли ойратов в системе международных отношений Центральной Азии в XVIII веке с точки зрения современной историографии. Организатором семинира выступил Казахский национальный университет имени аль-Фараби (см. подробнее на официальном сайте семинара: http://foreignasia.ru/).

---

10–14 сентября в Институте языка, литературы и искусства им. Г. Ибрагимова Академии наук Республики Татарстан были проведены мероприятия, посвященные 80-летию создания Института: 1) Международная научная конференция «Тюркское языкознание XXI века: лексикология и лексикография»; 2) Круглый стол на тему «Национальные литературы на современном этапе: научные концепции и гипотезы»; 3) Торжественное заседание, посвященное 80-летнему юбилею Института языка, литературы и искусства им. Г. Ибрагимова АН РТ; 4) XXXI Международная Осенняя научная Школа «Языковая картина мира».

Участники Международной научной конференции «Тюркское языкознание XXI века: лексикология и лексикография» обсудили широкий круг актуальных вопросов, посвященных лексикологии тюркских языков: тюркской исторической лексикологии и этимологии, диалектной лексикологии и лексикографии, сравнительно-сопоставительной лексикологии и терминологии тюркских языков и другим темам (см. подробнее на официальном сайте ИЯЛИ АН РТ: http://www.antat.ru/ru/iyli/news/9313/).

12–14 сентября в Алтайском крае и Республике Алтай состоялся Первый международный алтаистический форум «Тюрко-монгольский мир Большого Алтая: историко-культурное наследие и современность». Основными организаторами форума являются Алтайский государственный университет (г. Барнаул) и Горно-Алтайский государственный университет (г. Горно-Алтайск) при поддержке секретариата Постоянной международной алтаистической конференции (PIAC). Инициатива проведения форума поддержана Управлением по межрегиональным и культурным связям с зарубежными странами Администрации Президента РФ, Министерством науки и высшего образования РФ, Федеральным агентством «Россотрудничество», Советом межпарламентской ассамблеи государств – участников СНГ (см. подробнее на официальном сайте форума: http://konf.asu.ru/altai/).

26–28 сентября в Анкаре состоялся Международный конгресс «Кутадгу билиг», который был организован Турецким лингвистическим обществом и посвящен 950-летию произведения «Кутадгу билиг». В работе конгресса приняли участие видные ученые-тюркологи из Турции, Казахстана, Азербайджана, России, Ирана, Кыргызстана и других стран мира. Основными темами выступающих были исследования, касающиеся письменного наследия тюркского мыслителя, поэта и государственного деятеля эпохи Караханидов Юсуфа Баласагуни, в том числе «Кутадгу билиг» – жанровым, метрическим и художественным особенностям самого древнего и крупного письменного памятника тюркоязычной литературы XI века.

В работе конгресса приняла участие доцент кафедры общего языкознания и тюркологии ИФМК КФУ Г. Р. Мугтасимова, выступив с докладом «Произведение Юсуфа Хас Хаджиба Баласагуни „Кутадгу билиг“ и татарские народные пословицы» (см. подробнее на официальном сайте конгресса: http://kurultay.tdk.gov.tr/ ).

